Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 10 (1375) 18 март 2022 ел

1995 елның июленнән башлап чыга

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:
madani_zhomga
madanizhomga
madanizhomga
madanizhomga

8

Матросов батырлыгын беренче булып чынлыкта Александр Матросов кылганмы? Матросовчы якташларыбыз һәм милләттәшләребезне беләбезме?

12

Казан һәм Татарстанның символына әйләнгән Кол Шәриф мәчете имам-хатыйбы Илфар хәзрәт Хәсәнов – гыйбадәтханәнең хәзергесе һәм киләчәге турында.

24

Г. Тукай бүләге иясе, рәссам Абрек Абзгильдиннның “Хәзинә” милли сәнгать галереясында ачылган күргәзмәсен март аенда түләүсез тамаша кылырга мөмкин.

Безнең яшәүләрнең хакы һәрчак Исәпләнер икмәк бәясеннән!..

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Теләче районы Балыклы авылында күренекле журналист, күптән түгел вафат булган Зимфира Гыйльметдинованы искә алу кичәсе үтте.

- Опера җырчысы, Казан кызы Аида Гарифуллина Мәскәүнең Зур театрында «Травиата» операсында чыгыш ясый.

- Аяз Гыйләҗев белән тоткынлыкта булган һәм татар язучысының «Йә-гез, бер дога!» китабын венгр теленә тәрҗемә иткән Арпад Галгоци 93 яшендә вафат булды.

- Мәскәүдәге Кино йортының Зур залында Илдар Ягъфәровның «Исәнмесез?!» фильмы тәкъдим ителде.

- 22 мартта Татарстан Язучылар берлеге рәисе, халык шагыйре Ркаил Зәйдулланың 60 яшьлеге уңаеннан Камал театрында «Чын шигырьгә әверелә шагыйрь» әдәби-музыкаль кичә узачак.

- «Татмедиа» бинасында урнашкан «Әдәби кафе»да мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен «Күңелле әлифба» интерактив китабы тәкъдим ителде.

- Бөтендөнья татар конгрессы «Виртуаль татар теле кабинеты» бәйгесе игълан итте.

- Татарстанның Халыклар дуслыгы йортында рәссам, Аксубай Туган якны өйрәнү музее директоры Әлфия Нурхәммәтованың «Язгы вернисаж» дип аталган шәхси күргәзмәсе ачылды.

- Татарстанда 1 сентябрьгә кадәр татар телендәге элмә һәм мәгълүмат такталарындагы хаталарны ачыклау буенча конкурс уза.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Рөстәм МИҢНЕХАНОВ, Татарстан Республикасы Президенты:

«Һәр хатын-кыз икешәр, өчешәр бала тапсын иде. Элек һәр гаиләдә өчәр бала табу гадәткә әйләнгән. Шартлар бөтенләй башка булса да, аңа карап кына өйдә балалар саны кимрәк булмаган. Кешеләр яхшырак шартларда яши башласа, күбрәк үзләре турында уйлый, киләчәк өчен борчылмый».

СЫНАМЫШЛАР

22 марттан 30 апрельгә кадәр кырык иртәдә суык булса, җылы җәй көтелә● 22 мартта 40 төрле күчмә кош кайтырга тиеш; тургай килсә – җылыта, акчарлак килсә – язгы ташу башлана● Карны кояш эретсә – игеннәр уңа, яңгырдан эресә – җәен корылык була.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **5 сәгать 51 минутта** чыкты, һәм ул **17 сәгать 52 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **12 сәгать 01 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **33 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **25 мартта 12 сәгать 34 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

19 март – китап басу остасы, рәссам Мөхәммәд Ибраһим улы Идрисинең тууына 140 ел (1882–1948).

20 март – композитор Эльмира Мөнир кызы Галимовага 40 яшь (1982).

21 март – актер, Татарстанның халык артисты Булат Нуретдин улы Сәләховка 70 яшь (1952).

23 март – дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, педагогика фәннәре докторы Васил Габдулла улы Гайфуллинга 85 яшь (1937).

24 март – филология фәннәре докторы, профессор, Халыкара төрки академиянең хакыйкый әгъзасы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Нурмөхәммәт Шәһвәли улы Хисамовка 85 яшь (1937);

– композитор, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Риф Вәҗетдин улы Ильясовның тууына 80 ел (1942–2017).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Мартның магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 19 март.**

* * *

Гадәттә, тулы айдан айның соңгы чирегенә кадәр **(18-25 март)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: 1**8 февральдән 29 апрельгә кадәр** бавыр һәм үт куыгы актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны чистарту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1443 ЕЛ

Бүген шәгъбән аеның 15 нче көне

ҖАН АВАЗЫ



Рүзәл ЮСУПОВ

Педагогика университеты кирәк!

Соңгы 20-30 елда мәктәп һәм югары уку йортларында укучыларның белем дәрәҗәсе коточкыч түбәнәя бара. Бу зыянлы чирдән котылуны, һичшиксез, укытучылар әзерләүне камилләштерүдән башлау зарур.

Татарстанда 140 ел буена педагогларны, мәгариф эшен оештыручылар һәм мәдәният хезмәткәрләрен әзерләүче төп югары уку йорты - Казан педагогика институты (университеты) булды. XXI гасыр башында Россиянең бу зур тарихлы югары уку йортын юкка чыгару башланды: әүвәл Татар гуманитар-педагогика университеты итеп үзгәрттеләр, аннары Федераль университетка кушып куйдылар. Нәтиҗәдә Казан педагогика университеты юкка чыкты.

Хәзер Татарстан мәктәпләрендә укытучылар җитмәү, педагогларның белем сыйфатын күтәрү ихтыяҗы, мәгарифтә проблемалар хөкем сөрүнең төп нигезе – республикада югары педагогик уку йорты булмау. Бу очракны хәл түгелдер: Казаннан башка бер генә шәһәрдә дә педагогика институты яки университеты юк итełмәгән. Хәлбуки, падишаһлар 150 ел элек Казанда укытучылар институтын тиктомалдан ачып куймагандыр.

Әйе, 1876 елда Россиядә, Санкт-Петербург һәм Мәскәү укытучылар институтларыннан кала өченче уку йорты буларак ачылып, 140 елга якын Идел буендагы һәм Себер киңлекләрендәге мәктәп, гимназия, лицейларны укытучылар, күп регионнарның мәгърифәт һәм мәдәният хезмәткәрләре белән тәэмин итеп торган, бар дөньяга мәгълүм академик-галимнәр Н.С.Державин, С.П.Обнорский, Б.Д.Греков, Е.Косминский, В.Мосолов, Е.Тарле, А.Е.Арбузов, К.Ә.Вәлиевләр эшләгән, герой-шагыйрь М.Җәлил, Социалистик Хезмәт геройлары С.Габдрахманова, Г.Гыйматдинов, академик В.Хвостов, СССРның халык укытучысы Ә.Сәләхов, СССР халык артисты Г.Шамуков, генерал-адмираллар Г.Антонов, В.Сәлимов, Л.Оняնов, Г.Уткин, язучылар Абдулла Алиш, Гадел Кутуй, Сибгат Хәким, Петер Хузангай, Мөхәммәт Мәһдиев, Илдар Юзеев, Ренат Харислар,шөһрәтле спортчылар – дөнья, Европа һәм Россия чемпионнары белем алган Хезмәт Кызыл байрагы орденлы Казан дәүләт педагогика университеты кылган бәрәкәтле гамәлләр татар халкы өчен әйтеп бетерә алмас дәрәҗәдә бик кадерле иде.

1990 елның 30 августында парламент тарафыннан Татарстанның дәүләт суверенлыгы турында декларация кабул ителгәч, Казан дәүләт педагогика институты коллективы укыту һәм тәрбия эшен камилләштерү чараларын башлады. Республикада татар һәм рус телләре дәүләт телләре дип игълан ителеп, мәктәпләрдә татар телен рус теле белән бер күләмдә укыту, тормышның барлык өлкәләрендә дә – мәгърифәттә, фәндә, сәнгатьтә, мәгълүмат чараларында, дәүләт идарәсендә һәм башка тармакларда татар теленең кулланылышын нык киңәйтү тәртибе кертелгәнлектән, Казан педагогика уку йортына татар һәм рус телләрен яхшы үзләштергән белгечләр әзерләү бурычы куелды. Тиздән институтта барлык белгечлекләрдән дә студентларның рус группалары белән параллель рәвештә татар группалары да барлыкка килде. Татар мәктәпләрен тәмамлаган абитуриентлардан кабул итү имтиханнары татар телендә алынды, татар бүлекләре оештырылды, предметлар, нигездә, татарча укытыла башлады. Шул ук вакытта татар бүлекләрендәге студентлар, вузны тәмамлагач, рус мәктәпләрендә дә эшли алсын өчен, югары курсларда русча да укытылды. Нәтиҗәдә институт ике дәүләт телен дә яхшы үзләштергән һәм татар, рус мәктәпләрендә уңышлы эшли алырлык белгечләр әзерләп килде.

Укытучыларга да, укучыларга да сыйфатлы белемгә ирешү өчен таләпләр катгыйланды. Уку планнарына мәктәптә балаларга лаеклы белем һәм тәрбия бирү өчен кирәкле өстәмә курслар (предметлар) кертелде һәм шуңа бәйле рәвештә яңа кафедралар, факультетлар ачылды. Мәсәлән, яшь буынны культуралы, әдәпле, әхлаклы итеп тәрбияләү өчен әһәмиятле педагогик осталык, үз-үзеңне тоту әдәбе, сөйләм культурасы, риторика, эстетика нигезләре һәм тагын кайбер предметлар укытыла башлады.

80-90 нчы еллардагы Казан педагогика университетының бүгенге укытучылар әзерли торган уку йортлары өчен үрнәк булырлык гамәлләренең бик әһәмиятлесе ул – педагогика вузына һәм урта махсус уку йортына студентларны укырга катгый рәвештә педагогик һөнәренә теләкләре һәм сәләтләре булганнарын сайлап алу. Хәзергечә, мәктәпне тәмамлаганда алган билгеләр буенча теләсә кайсы вузга, шул исәптән педагогика уку йортына да, укырга керү тәртибе үзен акламый. Педагог ул – бик үзенчәлекле, үзенә бертөрле, нәзакәтле, югары кешелеклелек сыйфатлары таләп итүче һөнәр. Бу белгечлек буенча теләсә кем уңышлы эшли алмый. Ул - балаларны яраткан, аларның күңелен аңлый белгән игелекле кешеләр һөнәре.

Казан педуниверситетында профориентация эше бик җитди куелган иде. Ул, мәктәпләр, район, шәһәр мәгариф бүлекләре белән берләшеп, Мәгариф министрлыгы белән килештерелеп, планлы рәвештә башкарылды. Телләр турындагы законны гамәлгә ашыру йөзеннән Казан педуниверситетында чуаш теле һәм әдәбияты бүлеге ачылды. Бу вузның республикадагы демократик үзгәрешләрдән калышмавын күрсәтә.

90 нчы еллар азагында университетта өч факультет оештырыла, Яр Чаллы шәһәрендә КДПУның 1000 кешелек филиалы ачылды. Аның республиканың көнчыгыш районнарын югары белемле укытучылар белән тәэмин итүдә әһәмияте зур була. Докторлык диссертацияләре яклата торган өч совет ачыла. Аларның һәркайсында ел саен дистәләрчә диссертацияләр яклана. Университетта эшләүче докторлар һәм профессорлар саны күпкә арта.

Казан педагогика университетында уңышлы укытылып килә торган инглиз, француз, немец, испан, гарәп, төрек, фарсы, һинди, кытай, япон телләреннән тыш, итальян, швед, грек, норвегия, корея телләре өйрәтә башлау планлаштырыла.

Университет җитәкчелеге карары белән КДПУда педагогика һәм башлангыч белем методикасы, педагогика һәм мәктәпкәчә белем методикасы, психология, педагогик юнәлешле юриспруденция белгечлекләре ачылу дөрес уйланылган һәм тормыш таләп иткән эш була, һәм алар тиз арада республикада да, башка өлкәләрдә дә популяр булып китә.

Инглиз телен һәм башка чит телләрне белә торган белгечләр әзерләү – ул педагогик уку йорты өчен перспективалы гамәл. Шушы хакыйкатьне истә тотып, Казан педуниверситеты өстәмә инглиз теле белән берничә белгечлек кертүгә әзерлек башлый (инглиз теле белән математика, физика, география, биология, тарих һ.б.).

Югары квалификацияле, эрудицияле, культуралы, әхлаклы педагоглар әзерләү һәрвакытта да Казан педуниверситеты җитәкчеләренең һәм бөтен укытучылар коллективының игътибар үзәгендә торды. Казан педагогика университеты коллективының мәктәпләр өчен югары сыйфатлы укытучы-тәрбиячеләр әзерләү өлкәсендәге күркәм гамәлләре күп булды...

Казан дәүләт педагогика университетын юкка чыгару татар милләте каршында җинаятькә тиң гамәл иде. Бу еллар эчендә ачыкланды: Казан федераль университеты хәзерге заманның югары таләпләренә җавап бирә алырлык педагогик кадрлар әзерләү бурычын башкара алмый. Соңгы елларда укытучыларның тәрбия бирү вазифалары шактый йомшарды. Укучылар белемнәренең сыйфатында да, педагоглар эшләренең нәтиҗәлелегендә дә җитди проблемалар бар.

Укучыларга белем һәм тәрбия бирүдәге хәлне анализлау Казан педагогика университетын яңадан ачарга (торгызырга) кирәк дигән фикергә китерә. Бу хыялны гамәлгә ашыру бик катлаулы булса, һич югында, Лондон университетындагы кебек, Казан педагогика институтын Казан федераль университеты составында оештыру турында уйларга кирәк. Безнең фикеребезчә, тиешле җитәкчеләр бу бик кирәкле эш дип тырышса, Казан педагогика университетын торгызу булдырмаслык эш түгел.

КЕШЕНЕ ЫШАНЫЧ ЯШӘТӘ

[illegible] Адәм баласы уңай хәбәрләргә сусаган чорда яшибез. Шуңа күрә атналык язмаларда кешегә күңел тынычлыгы бирә торган, ул гына түгел, инсаннарда (сүз аек акыл йөртергә сәләтле кешеләр турында бара) өмет чаткылары да уята торган темаларны күтәрәсе килә. Тик, ни кызганыч, көндәлек тормышта һәм мәгълүмат чараларында алар бүген күп түгел. Ә бит кешене иң элек ышаныч вә өмет яшәтә. Хәер, ышанычтан башка гына, өмет тә була алмыйдыр. Тик ул ышанычны каян табарга соң? Җәмгыятьтә рухи таркалу хәттин ашкан, хәтта гаиләләрдә дә еш кына ата – улны, ана кызны белмәгән заманда кемгә ышанырга? Коррупциягә баткан түрәгә, яисә «җиңүләрдән җиңүләргә» илтә торган чираттагы партия яки «юлбашчы»гамы? Аллам сакласын! Ә җавап гади: рухи кыйммәтләр генә түгел, әдәп вә әхлак та җимерелгән бүгенге җаһил чорда эшне, мөгаен, үз-үзеңә ышанудан башларга кирәктер. Ә аңа юл инану аша ята. Әлбәттә, иң әүвәл – Хак Тәгаләнең барлыгына һәм берлегенә инану. Тик сорау туа. Соңгы 30 елда илгә вөҗдан иреге килде, меңнәрчә мәчет манаралары калыкты, күп кенә мәдрәсәләр һәм хәтта ислам университетлары да ачылды. Дин юлына баскан яшьләребез дә, шөкер, артты кебек. Шуны ук башка конфессияләрдә дә күрәбез. Ә илдә нигәдер рухи деградация күзәтелә. Хикмәт нәрсәдә?

Эш, күрәсең, дини вә рухи тәрбиянең заман таләпләре һәм ихтыяҗларыннан артта калуында. XXI гасыр кешесен урта гасырларда кертелгән шәригать кануннары буенча тәрбияләп булмый (сүз бирегә Коръән турында түгел, ә мөселманнар өчен хәлифәләр керткән законнар җыентыгы хакында). Чөнки бүген кешенең белем дәрәҗәсе һәм дөньяга карашы гына түгел, җәмгыять һәм кешелек дөньясы үзе дә үзгәрде. Әйе, җәмгыяви институт буларак, дин халыкны илаһи кануннар кысаларында тоту (кавем Аллаһтан аерылмасын, эволюцион сәяхәтендә адашмасын) өчен кертелгән. Шуның белән бергә, ул һәрчак адәми-сәяси ихтыяҗга да хезмәт иткән һәм бу әле дә шулай. Белгечләр әйтүенчә, кешенең рухи үсеше (Аллаһка кайтуы) җәмгыяви тәрбия аркылы тәкъдирләнгән. Аллаһ аны яралтылышта бертөрлелекне күптөрлелеккә җибәрү (инволюция) һәм яңадан элекке хәленә (бертөрлелеккә) кайту (эволюция) шәкелендә ниятләгән. Китү-кайту циклында кешегә, авырын да, җиңелен дә кичереп, фанилыктагы яшәү шартларының төрлесен үтеп, акылын үстерергә, дөнья төзелешен вә илаһи кануннарны (табигать законнарын да кертеп) өйрәнергә һәм, шуларның нәтиҗәсе буларак, аңын камилләштерергә тәкъдир кылынган.

Ә бүген хәлләр ничек соң? Җирдә мәҗбүри глобальләштерү сәясәте үткәрелүе, ә дини вә рухи тәрбия яңа чор таләпләренә җавап бирмәве сәбәпле, җәмгыять тирән рухи кризис кичерә. Урта гасырларда гавамны исламга күбрәк дини йолалар (ә алар бүген дә мөһим) аша җәлеп иткән шәригать законнары бүгенге чор таләпләренә инде җавап бирми. Икенчедән, ул чорда кешеләр илаһи рухка күбрәк йөрәк белән (иррациональ) инанса, бүген инде Аллаһның барлыгын вә берлеген акылга таянып (рациональ) тануга да ихтыяҗ зур. Шуңа күрә илаһи исламның тәүхиди асылын бүген ислам метафизикасы (мәңгелек һәм тәҗрибә ителә алмый торган илаһи башлангычларның даимилеген таный торган фәлсәфи тәгълимат) югарылыгында аңлау таләп ителә. Ә бу инде исламның иҗтиһади (үз язмышын корыда кешенең дә ирегең, җаваплылыгын һәм тырышлыгын таныган) асылын да ачу мөмкинлеге бирә. Үз-үзеңә ышану нәкъ менә шуннан башлана да инде. Өченчедән, илаһият кануннары барлык кешеләр өчен дә уртак, ә схоластикага корылган шәригать законнары мөселманнар өчен генә гамәлдә. Әле анда да ул рухи тәрбия юлында еш кына киртә булып тора, илаһи исламның дөнья үсешендәге ролен һәм мөмкинлекләрен чикли.

Димәк, кайчандыр татар халкының бөек ислахчылары (Г.Курсави, Ш.Мәрҗани, Р.Фәхретдин һ.б.) мәдрәсәләрне чор таләпләренә җавап бирерлек итеп үзгәрткән кебек, бүгенге дин галимнәре алдында да гаять катлаулы һәм җаваплы бурыч тора: шәригать кануннарын илаһи исламның тәүхиди-иҗтиһади асылына һәм яңа чор таләпләренә җавап бирерлек итеп ислах кылу. Бүген ил-көндә бара торган фаҗигале вакыйгалар фонында һәм ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына әзерлек барган көннәрдә әлеге проблема аеруча актуаль яңгырый. Юкса, Җирдә яңа дөньяви тәртипне кабаттан да Иблис урнаштырачак.

Фоат УРАЗАЙ.

«Ярдәм» игелекләре

«Ярдәм-Помощь» илкүләм хәйрия фонды 2021 елда ковид шартларында да игелекле эшләрен туктатмады. Әйтик, сукыр яки начар күрүче, ишетмәүче, колясказда йөрүче 435 инвалид тернәкләндерү курсларында саулыгын ныгыткан. «Тормышка юл» акциясе кысаларында 100-250 кеше (рамазан аенда 39000) ашатылган, Казан шәһәренең 6000 мохтаҗ гаиләсенә азык-төлек җыелмалары тапшырылган. «Ярдәм» мәчете биләмәсендә начар тәэмин ителгән, яки яшәр почмагы да булмаган 250 кеше көн саен кайнар төшке аш белән тәэмин ителгән. Моннан тыш «Минем ярдәм» акциясе кысаларында узган елның октябреннән 1200 гаиләгә ит, сөт, кондитер ризыклары, киптерелгән җиләк-җимеш, ярма, токмач, чәй, консервлар һ.б. азык-төлек кергән җыелмалар илтеп бирелгән. Бу хакта «Ярдәм» мәчетендә үткән матбугат очрашуында хәбәр иттеләр.

Быел «Ярдәм-Помощь» илкүләм хәйрия фонды 15 еллык юбилеен билгеләп үтә. Шушы уңайдан күңелле вакыйгалар да көтелә. Татарстан мөфтиенең социаль мәсьәләләр буенча киңәшчесе, хәйрия фонды советы рәисе Илдар хәзрәт Баязитов сәламәтлеге чикле кешеләр өчен күп функцияле спорт комплексы төзелеп бетүен, аның ислам динен рәсми кабул итүнең 1100 еллыгын билгеләп үткән көннәрдә - май аенда ачылачагы турында әйтте. Хәзер заманча уникаль комплекста соңгы эшләр башкарыла. Комплексны планлаштырганда инвалидларга уңайлы мохитне тәэмин итүдә барлык таләпләр дә исәпкә алынган. Киләчәктә анда инвалидларның төрле төркемнәре өчен футбол, волейбол, баскетбол кебек түгәрәкләр эшләячәк. Аларның эшкә керүен сәламәтлеге чикле булган йөзләрчә спорт сөюче көтә, берише түгәрәкләргә язылып та куйган. Илдар хәзрәт Баязитов паралимпия уеннарында катнашучылар өчен дә махсус тренажерлар булачагын хәбәр итте. Аларны, санкцияләр кертелгәнче, Америкадан Россиягә кайтартырга өлгергәннәр.

Левченко бистәсендәге «Сөләйман» мәчете соңгы елларда җимерелү хәленә килгән иде. Хәзерге вакытта аның бинасын сүтеп, яңадан төзү эшләре тулы көченә алып барыла. Ул элекке Аллаһ йортыннан шактый аерылып торачак. Әйтик, яңа бина элекке мәчеттән биш тапкыр зуррак булачак. Намаз бүлмәсеннән тыш мәдрәсә дә эшләячәк. Мәчет киләсе ел ахырына төзелеп бетәр, дип уйланыла.

«Күңел белән Коръән укыйм» акциясе кысаларында Изге Китабыбызның брайль шрифтында 400 комплекты нәшер ителгән. Алар Россиянең төрле төбәкләрендә яшәүче күрмәүчеләргә таратылган, шактые Төньяк Кавказ республикаларына җибәрелгән.

Әлбәттә, еллар уза, инвалид ул-кызларын тәрбияләп яшәгән аналар да бу дөньядан үтә. Ярдәмгә мохтаҗ балалары исә ялгызы кала. Хәзерге вакытта «Ярдәм» фонды нәкъ менә шундый кешеләр турында кайгыртуны үз бурычы иткән. Фондның сәламәтлеге чикле булган өлкәннәр һәм балалар өчен махсус пансионатлары бар. Балтач районы Бөрбаш авылындагысында күп балалы гаиләләрдән килгән малайлар тәрбия ала. Шундый пансионатларның тагын берсе «Сөләйман» комплексында булыр, дип уйланыла. Казан шәһәр Думасы депутаты, «Ярдәм» фонды вице-президенты Мәликә ханым Гыйльметдинова Луганск шәһәреннән начар ишетә торган 10-15 яшьлек тагын алты баланы тәрбиягә алырга ниятләгән. Алар хәзер Ростов-на-Дону шәһәрендә. Бүгенге көндә килештерү эшләре алып барыла.

Рамазан аена санаулы көннәр калды. Бу көннәрдә һәркайсыбызның мәрхәмәтле гамәлләр кылып калу өчен тырышуы мәслихәт, чөнки кечкенә генә изгелек тә күп тапкырлар арттырып язылачак. «Ярдәм - Помощь» фонды биләмәсендә гадәттәгечә, ифтар мәҗлесләре уздыру планлаштырыла. Көн саен 500 кешенең чатырда һәм мәчетнең банкет залында ифтарда катнашуы көтелә, ә волонтерлар ярдәме белән ланч-бокслар 1000 кешегә өйләренә китереп биреләчәк.

Сөембикә КАШАПОВА.

Ханымнар Коръән өйрәнә

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте Казанның Галиев мәчетендә теләге булган мөслимәләр өчен Коръән уку дәрес-очрашулары башлап җибәрде. Әлеге чара рамазан-шәриф аена әзерләнү максатыннан, Коръән укый белүчеләр өчен атна саен уздырыла. Төп максат – Коръән укуда камилләшү, хаталарны төзәтү, куркуны җиңү.

Очрашулар гарәп хәрефләрен һәм тәҗвид кагыйдәләрен белүчеләр, әмма әйтелешне (мәхраҗ) төзәтергә теләүчеләр өчен махсус оештырыла. Беренче очрашуга 30дан артык ханым катнашты. Җыелучылар остаз Лилия Ильясова белән бергәлектә практик күнегүләр ярдәмендә кагыйдәләрне кабатлый, катлаулы урыннарны өйрәнә, ятлаган аять-сүрәләрнең укылышын тикшерәчәк.

Тиләвәт дәресләренә (Коръән укуны тикшерү) теләгән һәр кеше, шул исәптән мәчет каршындагы курсларны, мәдрәсәләрне тәмамлаучылар да һ.б. чакырыла. Мөслимә хатын-кызлар Коръән укуны кабатлап, белемнәрен ныгытачак һәм рамазан аена Коръәнне яхшылап укырга өйрәнеп аяк басачак. Очрашу, күпләгән хатын-кызларның тәкъдимнәрен исәпкә алып, дүшәмбе саен 17.00-19.00 сәгать аралыгында Галиев мәчетендә (Габдулла Тукай ур., 40) үткәрелә. Барлык дәресләр дә түләүсез.

Эльмира ӘХМӘДУЛЛИНА.

Хаҗ кылу кагыйдәләре үзгәрә

Татарстанның рәсми хаҗ операторы «ДУМ РТ Хаҗ» Согыд Гарәбстанына бару, Мәккәдә һәм Мәдинәдә изге урыннарны зиярат итү кагыйдәләренә кертелгән соңгы үзгәрешләр турында хәбәр итә. Согыд Гарәбстаны 2022 елның 5 мартыннан гомрә кылырга ниятләүчеләр өчен кайбер чикләүләрне бетерде.

Аерым алганда, ПЦР-тестларны тапшыру таләбе гамәлдән чыгарыла, ләкин вакцина ясату мәҗбүри булып кала. Согыд Гарәбстаны ПЦР-тест нәтиҗәләрен таләп итмәсә дә, гражданнарның үзләре өчен ПЦР-тестлар тапшыру мәҗбүри: тест нәтиҗәләрен аэропортларда очып китү һәм транзит вакытында сорарга мөмкиннәр, бу хактагы мәгълүматны үзең оча торган авиакомпания операторларыннан ачыклап бетерергә кирәк булачак.

Шулай ук Согыд Гарәбстанына килеп җитү белән кертелә торган карантин һәм мәчетләрдәге социаль дистанция бетерелә. Биш тапкыр намаз өчен мәҗбүри рөхсәт (тасрих) гамәлдән чыгарыла. Ике яшьтән зуррак балаларга «Харам» мәчетенә һәм Пәйгамбәребез мәчетенә керү рөхсәт ителә. Моның өчен баланың Согыд Гарәбстанында элемтәләрне күзәтү өчен Tawakkalna (Covid-19 KSA) рәсми кушымтасы һәм аның яшел статуслы (Immune) булуы кирәк. Моннан тыш, «омикрон» барлыкка килгәннән соң элемтә өзелгән илләр белән һава юллары торгызылды.

Эльмира СИРАҖИ.

1 нче биттә – Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Казанның Кумәч-кондитер комбинаты эше белән танышты. Фото: president.tatarstan.ru

Галимҗан Ибраһимов айлыгы

Язучы, галим һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның тууына 135 ел тулу уңаеннан Татарстан Язучылар берлеге катнашында Казан шәһәренең Мәскәү районында урнашкан Г.Ибраһимов исемендәге 17 нче номерлы татар гимназиясе каршында бөек язучы бюстына чәчәкләр куелды.

Мәдәният эшлеклеләре Галимҗан Ибраһимовның илебезнең татар һәм төрки халыкларының милли прозасын камилләштерүдә, ТАССР формалашкан чорда татар әдәбиятын, фольклорын һәм мәдәниятен системалы тикшеренүләр алып баруда зур роль уйнавын билгеләп үтте. Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рифат Җамал Г. Ибраһимов әсәрләренең тирән мәгънәгә ия булуын һәм бай сюжетка нигезләнүен, төрле яштәге укучыларның игътибарын яулаган әдәби әсәрләр булуын искә алды.

Тантанада танылган язучылар һәм публицистлар, Татарстан Мәдәният министрлыгы, Мәгариф министрлыгы, Казан шәһәренең Башкарма комитеты вәкилләре катнашты. Тарихи вакыйга кысаларында кунакларга Г.Ибраһимовка багышланган мәктәп музеендагы экспозиция күрсәтелде. Язучының иҗади эшчәнлеге һәм тормыш юлы турында сөйләүче уникаль экспонатлар белән мәктәп укучылары таныштырды.

ТАССР Мәдәният һәм Мәгариф министрлыгы, Язучылар берлеге һәм Театр әһелләре берлеге тарафыннан 89 нчы номерлы мәктәп (хәзерге 17 нче номерлы татар гимназиясе) каршында Галимҗан Ибраһимовның бюстын ачуга 55 ел. Музей фондларында әлеге чарада төшерелгән уникаль фотосурәтләр саклана.

Мәктәп укучылары бу музейда актив тикшеренү эшчәнлеге алып бара, биредә ел саен педагогик коллектив инициативасы белән ТР Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел һәм әдәбият институты һәм киң җәмәгатьчелек катнашында язучыга багышланган әдәби конференция үткәрелә. Быел мәктәп музеена экспозицияне яңарту максаты белән грант бирелә.

27 мартка кадәр «Республика балалар китапханәсе» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесендә Г.Ибраһимовның 135 еллыгына багышланган китап күргәзмәсе эшләячәк. 31 мартка кадәр Татарстан Милли китапханәсендә «Галимҗан Ибраһимов – язучы, галим, җәмәгать эшлеклесе» дип аталган китап күргәзмәсе оештырыла. Г.Ибраһимовның тормышы һәм иҗатына багышланган күргәзмәләр республиканың муниципаль китапханәләрендә дә уза. Шулай ук Татарстан мәктәпләрендә Г.Ибраһимов истәлегенә багышлап әдәби сәгатьләр үткәрелә.

23 март 16.00 сәгатьтә Татар китабы йортында «Гасырлар киселешендә Г.Ибраһимов шәхесе һәм иҗаты» дип исемләнгән искә алу кичәсе узачак. 25 мартта «Әкият» курчак театрында «Адәмнәр» спектакле куелачак. 28 мартта Язучылар берлегенең Тукай клубында Г.Ибраһимовның 135 еллык юбилеена багышланган әдәби-музыкаль кичә уздыру планлаштырыла.

КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында «Галимҗан Ибраһимов: язучы, тәнкыйтьче, методист, җәмәгать эшлеклесе» дип исемләнгән Халыкара фәнни-гамәли конференция үтте. Гыйльми җыенда аспирантлар, югары уку йортлары студентлары, көллиятләр һәм гомуми һәм урта белем бирү оешмалары укучылары катнашты. Конференциядә Төркия, Әзәрбайҗан, Үзбәкстан, Башкортстан, Татарстанның яшь галимнәре белән беррәттән, республиканың 8-11 класс укучылары да чыгыш ясады.

Комикслар татарча да була

Журналист, музыкант Рәдиф Кашапов һәм Регина Гаязова улары Шәүкәткә багышлап комикслар җыентыгы бастырып чыгарган. Яңа китапның презентациясе Милли китапханәдә үтте.

«2021 елда балабыз тугач безнең балаларга кызыклы булган һәм татар теленә багышланган проект ясыйсыбыз килде. Китапханәдә комикслар киштәләренең һәрвакыт буш булуын күреп без комикслар китабы ясарга булдык», – дип тәкъдим итте «Татарча комикслар. Казан хикәяләре» җыентыгын Регина Гаязова.

«Җыентыкка Казаннан, Ульяновск өлкәсеннән, Чаллыдан һәм Мәскәүдән унтугыз авторның иҗаты керде. Аларга иң зур рәхмәтебез. Рәсемнәренә карап авторларның да ниндилеген тоя аласыз», – диде ул.



«Проектта катнашырга теләк белдергән авторларга Казан тарихы буенча лекция һәм Иске татар бистәсе буенча экскурсия оештырылды», – диде проектның кураторы Рәдиф Кашапов.

Җыентыкка Радик Мусин белән Илшат Сәетовның «Замансу чорларда Тәңре белән Умай», Зәлия Галимованың «Казан мәчесе», Азат Ибәтуллинның «Шаһиәхмәт» һәм башкаларның Казан тарихына һәм шәхесләренә багышланган хикәяләре кергән. 1000 данә тираж белән чыккан басма Казан мэриясенең «Үз телем» гранты хисабына эшләнгән.

Рузилә МӨХӘММӘТОВА.

Тукай бүләген дәгъвалаучылар

Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә быелгы кандидатлар исеме билгеле. Комиссиягә барлыгы 25 гариза килгән. Шулардан 19 кандидат рәсми рәвештә премиягә дәгъва итә.

Флера Гыйззәтуллина – «Яну дәверләрендә», «Вөҗдан үре – йөрәк түре» китаплары өчен;

Ләбиб Лерон – «Җил көймәсе», «Әкиятче малай» китаплары өчен;

Николай Алешков – тәрҗемәләре һәм «Жизнь моя», избранное: стихотворения, поэмы», «Дальние луга», избранная лирика, «Мои поэмы», «Причастие» әсәрләр циклы өчен;

Марат Кәбиров – «Китап», «Бердәнбер һәм кабатланмас» китаплары өчен;

Рашат Низамиев – «Уч төбендә яшен», «Татар моңының өч йолдызы» китаплары өчен;

Йолдыз Шәрапова – «Китаплы кич», «Каен алмасы», «Колаклы коймаклар» китаплары өчен;

А.Гыйләҗев исемендәге Чаллы драма театры – «Абага алмасы ачы була» спектакле өчен – режиссер Фаил Ибраһимов, төп рольне башкаручы Рафил Сәгъдуллин, пьеса авторы Равил Сабыр;

А.Гыйләҗев исемендәге Чаллы драма театрының **«Шәһәр.Нокта. Брежнев» спектакле** – әсәр авторы Шамил Идиатуллин, режиссер Олег Кинҗәгулов, тәрҗемәче Гүзәл Әхмәтгәрәева – хәзерге Россия прозасына мөрәҗәгать итү юлы белән республика милли театр сәнгатен үстерүгә керткән өлеше өчен;

Әлмәт татар дәүләт драма театры – «Кибет» спектакле өчен – актрисалар Мәдинә Гайнуллина, Диләрә Ибәтуллина, драматург Олжас Жанайдаров, режиссер Эдуард Шахов;

«Әлиф» берләшмәсе – «Әллүки», «Дәрдемәнд», «ОТУКАН», «hava», «Sak-sok», «Әлиф» спектакльләре өчен – режиссер Туфан Имаметдинов, актер, хореограф Нурбәк Батулла, композитор Эльмир Низамов, хореограф Марсель Нуриев;

Анатолий Егоров – «Над Казанью луна» гобеленнар циклы өчен;

Кадим Җәмитов – татар мәдәниятенең күренекле шәхесләренә багышланган скульптур портретлар һәм сыннар; «Хөррият» һәйкәле өчен;

Илһам Байтирәк – «Весенний Кырлай», «В ожидании утра», «Тулпар», «Зилант» симфоник поэмалары театралогиясе өчен;

Риф Гатауллин – «Балачакның җырлы мизгелләре» балалар өчен музыкаль җыентыгы, «Әйттең миңа...» җырлар һәм романслар җыентыгы өчен;

Фаяз Хуҗин – Татарстан һәм татар халкының тарихи-мәдәни мирасын өйрәнү һәм популярлаштыруга багышланган фәнни хезмәтләре өчен;

Раилә Гарипова – татар милли хореографиясен саклаган, үстергән һәм пропагандалаган өчен;

Рифхәт Якупов – милли фото сәнгатенә керткән өлеше, иҗатында татар халкының рухи-мәдәни тормышын чагылдырган өчен;

Елена Алексеева – «Казань. Кинематограф. Из века в век (1897–2014 гг. г.)» китабы өчен;

Фирдәвес Ханов – архитектура һәм шәһәр төзелешендә татар милли мәдәниятен үстерүгә керткән өлеше өчен (Түбән Камадагы архитектура проектлары: Җәмигъ мәчете, «Тукай» паркы, Кама Аланындагы «Оазис» экопаркы һ.б.)

Лауреатлар 26 апрель көнне игълан ителәчәк.

● Швейцариядәге Barry Callebaut компаниясе кызыл якут төсендәге, үзенә бер төрле тәмле шоколад җитештерә. Ул Бремендагы Якобс университеты,Франция һәм Бельгиядәге тикшеренү үзәкләре белгечләре уйлап тапкан технология буенча Ruby какао орлыгыннан ясала, буяуларсыз һәм бернинди җиләк өстәмичә дә шундый төстә булып чыга. Бу шоколад компаниясенең еллык саф табышы уртача 219 миллион Швейцария франкы тәшкил итә.

● Зәңгәр китның теле уртача зурлыктагы фил авырлыгына тәңгәл.

● Акула беркайчан да бернәрсә белән дә чирләми.

● Дөньяда иң зур Attacus Atlas төнге күбәләгенең канат арасы киңлеге 30 сантиметрга җитә.

● Кытайда панда үтергән кешегә үлем җәзасы бирелә.

● Нутрикула медузасы – планетада бердәнбер үлемсез җан иясе.

Коръәннең Казан басмасы

Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә Идел Болгарстанында рәсми рәвештә ислам дине кабул ителүгә 1100 ел тулу уңаеннан Ачык ишекләр көне булып узды. Аның кысаларында Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте белгечләре һәм Казанның танылган хәзрәтләре катнашында «Татар рухани мирасы: җыю, саклау һәм актуальләштерү мәсьәләләре» дигән темага түгәрәк өстәл утырышы да үткәрелде. Кунакларны мирасханә эшчәнлеге һәм күргәзмә белән үзәкнең мөдире Илһам Гомәров һәм өлкән фәнни хезмәткәр Азат Ахунов таныштырды.

Мирасханә хезмәткәрләре 1939 елдан бирле татарлар яши торган төбәкләрдән халыкта саклана торган язма ядкәрләрне җыю ниятеннән ел саен экспедицияләргә чыга. Хәзер биредә илле меңнән артык архив берәмлеге бар. Аларның ун меңләбе – гарәп, фарсы, борынгы татар телләрендә язылган кульязмалар. Зур өлешне галимнәребезнең, классик язучыларыбызның шәхси фондлары тәшкил итә. Алар арасында Ш.Мәрҗанинең, Г.Тукайның, Г.Ибраһимов, Р.Фәхретдин, Ф.Әмирханның һ.б. кульязмалары, шәхси фондлары саклана. Тукаебызның үз кулы белән язган шигырьләрен дә бары тик биредә генә күрергә мөмкин.

Мирасханәгә сигез меңгә якын кульязма истәлек тупланган. Алар – төрле телләрдә. Шулай ук мирас үзәгендәге шәҗәрәләр тупланмасы да бик кызыклы.

Күргәзмәдә нигездә кулдан күчереп язылган Коръәннәр коллекциясе тәкъдим ителгән иде. Мирасханәдә 200 данә кульязма Коръән нөсхәләре саклана. Аларның өчтән бер өлеше – «һәфтияк»ләр. Бу – Россиядәге шушы профильдәге оешмалар арасында иң зур тупланмаларның берсе. Алар археографик экспедицияләр нәтиҗәсендә җыелган.

Күргәзмәгә куелган Коръәннәрнең тышлыклары төсле каләм белән матур итеп кулдан бизәлгән. Соңрак аларга нигезләнеп басмаханәләрдә гарәп имлясындагы хәрефләр булдырылган. Иң борынгы кульязмалардан исә имам Әл-Бохари Сахихның 1203 елда кулдан күчерелеп язылган хәдисләр җыентыгы исәпләнә. Ул 40 тан артык том рәвешендә бөтен дөньяга таралган. Шуның бер томы институтның музыкаль һәм язма мирас үзәгендә саклана. Аны 1987 елда озак еллар институт мирасханәсендә эшләгән һәм коллекцияләрне тулыландыруда үзеннән зур өлеш керткән Марсель ага Ибраһимов алып кайткан. Коръәннең Җәләлетдин шәрхенә игътибар итәбез. Аның кырыена «1830 елның сентябрь өченче көне шимбә көн Казан кальгасе ябылды. Әдәмиләр күп үлгән сәбәпле. Янә ноябрьнең сигезенче көнендә ачылды» дигән язу бар.

Күргәзмәдә рәсемнәр белән матурлап ясалган гарәпчә «Дәлаил Хәйрат» китабына да күз төшә. Пәйгамбәребезне (с.г.в) тасвирлый торган, аңа багышланган догалар да бик матур каллиграфик почерк белән күчерелгән, Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләренең сурәтләре белән бизәлгән, анда шулай ук пәйгамбәребезнең кабере күрсәтелгән. Кульязмалар арасында 5х4 сантиметрлы кечкенә китапчык та бар. Анда касыйдәләрдән бер өзек язылган. Арада татарлар яшәгән җирлекләрдә күчерелгән, Чистайда, Әстерханда табылган кульязмалар бар. Берсе – мәмлүк стилендәге Коръән күчермәсе. Ул заманында Коръән күчерү сәнгате югары дәрәҗәдә булуы турында да сөйли. Мәрҗани мәчетеннән кайткан, Мәңгәр авылында табылган кульязма, Казан җирлегендә хәттат тарафыннан бизәкләнгән, шулай ук Урта Азиядә күчереп язылган Коръән нөсхәләре дә кунакларның кызыксынуын уята. Сәет Вахиди коллекциясеннән «Һәфтияк-шәриф» тә хәзрәтләребезнең игътибарын җәлеп итә. Күргәзмәдә шулай ук Коръәннәрне тышлау сәнгатенең бер үрнәге дә тәкъдим ителә. Аның төбе һәм кырыйлары күн белән каймалап эшләнгән. Укырга һәм йөртергә җиңел булсын өчен өлешләп-өлешләп тә чыгарылган Коръән белән дә бар.

Мирасханә эшчәнлегенең бер юнәлеше – биредәге рухи кульязма байлыкны электрон форматка күчерү һәм аларны фән мәйданына кую. Күргәзмәгә бу уңайдан, мирасханә хезмәткәрләре тарафыннан әзерләнеп, соңгы елларда басылып чыккан китаплар куелган. Аерым серия булып классикларыбыз һәм күренекле дин әһелләребезнең фоторәсемнәре белән бизәлеп чыккан альбомнар булып дөнья күрә. «Марджани и его эпоха в фотографиях» дигәнендә Шиһабетдин хәзрәтнең мәгълүм булган өч фоторәсеме, ул аралашкан кешеләр, яшәгән мохит сурәтләре урын алган. Аерым серия булып «Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» дигән серия чыгып килә. «Мирасханә коллекциясеннән» сериясендә шәхесләрнең моңа кадәр чыкмый калган, архивларда сакланган аерым документлары, әсәрләре, хезмәтләре нәшер ителә. Бер сериядә Шиһабетдин хәзрәт әсәрләре урын алган. Анда Ш.Мәрҗанинең бүгенге көнгә кадәр гарәп телендә булган ике әсәрен тәрҗемә итеп бастырдылар.

Мирасханәнең өлкән фәнни хезмәткәре Нурия Гәрәева Коръәннең Казан басмасы тарихы белән таныштырды. Ул ислам дине кабул ителүгә 1100 ел тулу уңаеннан Мирасханәдә сакланган кыйммәтле һәм сирәк кульязмаларның тасвирламасын аерым бер китап итеп әзерләү эшен башлап җибәргән. Галимә хәзрәтләребезгә кызыклы мәгълүмат бирде. Әйтик, Казанда тулы текстлы Коръән 165 тапкыр басылган. «Һәфтияк» – 188, Коръәннең аерым сурәләре 108 тапкыр нәшер ителгән. Басма хәрефләр белән нәшер ителгән Изге Китабыбыз киң таралышта булган.

Н.Гәрәева шулай ук Коръәннең Казан басмасы тарихы белән дә таныштырды. 1787 елда Санкт-Петербургта Изге Китап җыелма хәрефләр белән нәшер ителә, ул казна басмасы була. Аны Екатерина патшабикә сәяси максатларны күздә тотып бастыра. Патшабикә фәрманы белән Коръән Санкт-Петербургта аз тиражлар белән биш тапкыр дөнья күрә. Бу вакытта Төркия белән сугыш бара. Екатеринага төрекләргә үз империясендәге мөселманнарга нинди лояль мөнәсәбәттә булуын күрсәтергә кирәк була. Мөселманнарның Изге Китабының алтынчы басмасын Павел хакимлек иткәндә нәшер ителә.

Коръәннең Казан басмасы ни өчен беренче мөселман басмасы исәпләнә соң? Чөнки басма Коръәнне чыгаруны татарлар башлап җибәргән. Алар Санкт-Петербургтагы типографияне арендага алган һәм аның эшчәнлеге өчен үзләре түләгән. Типографияне Казанга кайтару тарихы исә Павелның Казанга килүеннән башлана. Татар голәмасы аның белән күрешә. Алар патшага тагын бер тапкыр үзләренең гаризаларын бирә. Башка халыклар да Казанда шушы типографияне булдыруны сорый. Санкт-Петербургтагы татарлар типографияне күчерү чыгымнарын түләячәкләрен үз капиталлары белән гарантияли. Басмаханә Казанга кайтканда да, татарларга арендада булган кебек кайтартыла. Габделгазиз (кайбер чыганакларда Габделмәҗит) Бурашев шушы типографияне алып кайтуның барлык чыгымнарын үз өстенә ала, бинаны арендалаган өчен дә ул түли. Әлбәттә, хөкүмәт тә ниндидер җиһазлар белән тәэмин итә. 1803 елда Казанда чыккан басма Коръән мөселманнар тарафыннан рецензияләнгән, нәшер ителгән һәм ул татарлар акчасына дөнья күргән һәм барлык ислам дөньясы тарафыннан хупланып каршы алынган. Шуңа өстәп, аның тиражы да зур – 1500 нөсхә булган. Шулай итеп, ул таралган, бик күп тапкыр нәшер ителеп дөнья күргән. Әмма Казан хакимияте типографияне Казанга кайтартуны хуплап каршы алмый. Ул елларда губерна типографиясе дә, университетның да басмаханәләре булмый әле.

Типографиянең эшен дә Казанда хәрби Г.Бурашев башлап җибәрә. Аның белән Казанга ике татар кешесе дә кайта. Коръәнне университет типографиясе бастыра, аннары Изге Китапны шәхси типографияләр актив рәвештә нәшер итә башлый. Казан басмалары барысы да татар халкының акчасына чыгарылган. Татар эшмәкәрләре аның тиражын түләгән. Казанда чыккан Коръәннең безнең өчен әһәмияткә ия сыйфаты бар. Әлбәттә, беренче чыккан Коръән ике томда булып, аның шәрехләре куелмаса да, аларда тәҗвид билгеләре бар. Әмма бу басманың тиражы зур булмый. Казанда Коръән соңгы тапкыр 1919 елда Кәримиләр типографиясендә нәшер ителә. Казан басмасында титул битендә беркайчан да рус сүзе булмаган. Титул бите башта татарча бара, XIX гасырның икенче яртысыннан ул гел гарәпчә генә була.

Хәзрәтләр утырышта татар дини язма мирасын саклау һәм өйрәнүдә үз тәҗрибәләре белән дә уртаклашты.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

Милли яшьләр бәйгесе

Казанда мәктәпләрнең югары сыйныфларында һәм көллиятләрдә белем алучылар арасында "Ак калфак" укучы кызлар бәйгесенең финалы узды.

Быелгы конкурс илдәге вакыйгаларга – Идел Болгарстанында рәсми рәвештә ислам дине кабул ителүгә 1100 ел, Бөтендөнья татар конгрессының булдырылуына 30 ел тулуга багышлап үткәрелде. Быел бишенче тапкыр үтә торган конкурста Россиянең җиде төбәгеннән, Татарстанның 22 районыннан укучы кызлар катнашкан. Сайлап алу турларыннан соң 72 конкурсант дүрт номинациядә иншалар язган. Бу сынаудан соң 37 кыз ярымфиналга тәгаенләнгән. Аннары алар ЗУМ аша алып барылган конкурста осталыкларын һәм сәләтләрен күрсәткән. Финал бәйгесенә 14 кыз сайлап алынган.

Соңгы елларда күп мәктәпләрнең фәннәрне русча укытуга күчүе, рус телендә аралашу арту, әби-бабаларыбыздан буыннан-буынга тапшырылып килгән асыл йолаларыбызның югала баруы кебек вәзгыять килеп туды. Шуңа да Россия төбәкләреннән, Татарстан шәһәр-районнарыннан килгән кызлар үзләре турында татар телендә яки аның диалектында гына сөйләргә тиеш дигән бердәм таләп тә куелган иде. Бәйге сынауларын үтәп чыгу кызлардан халкыбызның, үз гаиләләренең тарихын, милли гореф-гадәтләребезне белүләрен дә сорый. Шул ук вакытта алардан зирәклек, зәвык, уңганлык, өлкәннәргә ихтирам, тәрбиялелек, ихласлык кебек сыйфатлар да таләп ителә.

Конкурста катнашучылар беренче өлештә үзләре, буш вакытларындагы шөгыльләре, гаиләләрендәге күркәм гадәтләр, кул эшләре, шәҗәрәләре, уңышлары турында сөйләде, сорауларга җавап биреп, якташ шәхесләре белән дә таныштырды. Әлбәттә, күп сынаулар аша узып килгән кызлар сәләтле дә, белемле дә, әдәпле дә. Алар милләтебезнең үткәннәрен дә белә, шул ук вакытта заманыбыз рухында да тәрбия алулары тоемлана. Аннары бәйге тотучыларның барысының гаиләләрендә милли гореф-гадәтләребез сакланган, милли бәйрәмнәребез дә әби-бабаларыбыздан калган йолалар буенча үтә. Аларның берише музыка мәктәбендә белем алган, кайберләре сәхнә сәнгате белән шөгыльләнә, биюдә осталык чарлаучылар да бар. Конкурсантларның һәркайсы буш вакытларында әниләреннән күреп кул эшен тотуны гадәт иткән, арада калфак, мендәр тышлары, кулъяулык чигәргә, йон җепләрдән уенчыклар, кием-салым, башмак-бияләйләр бәйләргә яратучылар, алма техникасы, карандашлар белән картиналар иҗат итүчеләр бар. Әйтик, Пенза өлкәсеннән килгән Ания Аликаева алма техникасы белән картиналар ясый, шома һәм тамбур чигүе белән кулъяулыклар, ашъяулыклар бизәкли, гаиләсендә борынгы милли ашыбыз – салма пешерү бер традициягә әверелгән. Әгерже районының Исәнбай авылыннан Энҗе Латыйпова зәвык белән башкарылган кул эшләреннән тыш әдәби иҗатны үз итә икән, шигырьләр яза, кыз бабасыннан калган шәҗәрәне дә тулыландырган. Гаиләдә электән үк гармунда уйнау матур гадәткә әверелгән. Моннан тыш кыз карандаш белән портретлар ясарга да һәвәс, ул аларда һәр героеның үзенчәлекле сыйфатын, холкын чагылдыра алган. Кайбычның Кошман авылыннан Ләйлә Хәйретдинова мәдрәсәдә белем алырга да өлгергән, нәсел агачында җиде буын әби-бабасын барлаган. Минзәләдән Фирүзә Хәбирова чигеп эшләгән бизәнү әйберләре өчен кечкенә сумкалар да хатын-кызларыбызны кызыктырырлык иде. Казан шәһәреннән Айзилә Алимова оста биюе, музыка мәктәбендә белем алуы белән бергә, авылның барча мәшәкатьләрен, гает коймаклары, каз өмәләре турында да әйбәт белүе белән хәйран итте. Лениногорски кызы Сөмбел Хәбибуллина матур сөйләме, фикерләү дәрәҗәсе, үзе ясаган беләзекләре белән истә калды. Чаллыдан Алия Нуриеваның ясаган картиналары да жюри күңеленә аеруча хуш килде. Кыз әнисе ягыннан – алты, әтисе ягыннан биш буын әби-бабасын да барлаган. Ул шахматта уйнарга, пешеренергә дә ярата. Мөслимнән Камилә Миңһаҗева чиккән калфакларның камиллеге дә жюрида утыручыларның күңеленә хуш килерлек иде.

Аннары конкурс аш-су әзерләүдә уңганлыкка сынаулар белән дәвам итте. "Ак калфак" оешмасы җитәкчесе Кадрия Идрисованың бәйгедә катнашучыларга иң әүвәл каз тутырып күрсәтүе алар өчен әйбәт дәрес булды. Аннары кызлар үзләре, камыр басып, чын татарча итеп токмач кисте. Алтын җепләр һәм сәйлән белән калфак бизәкләү остасы Нурзия Сергеева кызларны чигү серләренә өйрәтте. Конкурсантлар тукымага бизәк төшереп, аны сәйлән белән чигәргә тиеш иде. Кызлар бу эштә дә сынатмады. Соңгы имтиханда кызлар җыр-биюдә, сәнгатьле сөйләмдә һ.б. үзләренең сәләтләрен күрсәтте. Удмуртия кызы Гөлназ Гафурова читекләр тотып эчтәлекле бию күрсәтсә, Сарман кызы Айзилә Сәгыйтова, Минзәләдән Фирүзә Хәбирова очып-очып татар халык биюен башкарды. Кайбычтан Динә Хәертдинова, Пензадан Ания Аликаева, Әлмәттән Эльвина Мусина һ.б. моңлы җырларыбызны яңгыратты. Чаллыдан Алия Нуриеваның халкыбызның зирәк фикер-әйтемнәрен катлаулы мозаикалар ярдәмендә күрсәтеп бирүе аеруча үзенчәлекле чыгыш булып истә калды.

"Ак калфак" укучы кызлар бәйгесенең җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы Кариев исемендәге яшь тамашачы театры бинасында "Фикердәшләр җыелган җирдә" дигән җыен кысаларында үтте. Анда катнашучыларны Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров сәламләде һәм җиңүчеләргә бүләкләр тапшырды.

"Ак калфак – 2022" укучы кызлар бәйгесенең җиңүчесе итеп, Чаллы кызы Алия Нуриева аталды. Беренче урынга исә Киров өлкәсеннән Әминә Зыятдинова лаек булды, икенче урынны Әгерҗедән Энҗе Латыйпова һәм Лениногорскидан Сөмбел Хәбибуллина бүлеште. Өченче урынга Чистайдан Алинә Шәйхетдинова ия булды. Җиңүчеләргә Оренбург мамыгыннан бәйләгән палантин, татар хатын-кызларының баш киеме – калфак бүләк ителде.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

КУЛЪЯУЛЫК БИР ӘЛЕ МИҢА, ӘНИ

Кулъяулык бир әле миңа, әни.
Зур кызыңның күңеле тулган мәле.
Суык тигән бугай, диярмен дә...
Син ышанган булып торчы, яме.

Күрмәмешкә салыш керфегемнән
Тәгәрәргә торган әрсез яшем.
Беләсең ич, ни гомерләр инде
Күңелем тулы сагыш белән яшим...

Кулъяулык бир әле миңа, әни, –
Сытык көннәремдә юклык тәме.
Яшьле уем төреп кулъяулыкка,
Ераграк ышереп куйыйм, яме.

* * *

Миннән артист чыкмый инде. Беләм...
Тормыш сәхнәсендә уйный белгән.
Һичбер рольсез генә уйныйм менә
Сәхнә сөймәс үз йөрәгем белән.

Уйный белгән шамакайлар шактый –
Алар даһи булып кыланалар.
Күңел тәрәзәсен тоныкларга
Күзге яңгыр сыман сыланалар.

Артык тыйнак олуглары күрәм –
Рольгә кермәс өчен тартышалар.
Аларның да йөрәк сәхнәсендә,
Һич шигем юк, яшерен орыш бара...

Битлекләләр иллә күбәйделәр!
Матур сөйләп, уяулыкны буган...
Аңлыйм инде (аңлыйм кебек үзе),
Һәр заманда алар һәрчак булган.

Бер нәрсәне генә аңлый алмыйм.
Йөрәк, ахры, шуңа сыкрап тора.
Тормыш сәхнәсендә «уйнар өчен»
Ник кирәкми икән рөхсәт сорау?

Җанның кере – кул пычрагы түгел!
Юылмый ул, була бары йолып.
Уйнамыйча гына яшәгезче! –
Бу – Күкләрнең инрәве дип уйлап...

КАР ТӘКЪДИРЕ

Кар сылана биткә...
Җил – каршыдан.
Җил каршында
көчсез
ап-ак карлар...
Яңаклыйлар гына,
яңаклыйлар –
Бит очыннан үбәр чакларында...
Ә мин аклыйм
ап-ак карларның да
бозлы камчы булуларын,
аклыйм...
Җил тынуга, талгын гына,
тагын,
Җиргә алар
җылы шәлен каплый.
Бер тына җил җирдә,
Бер уяна...
Кар тәкъдире –
җилләр сүрәсендә.
Кем каршында кемнең
көчсезлеген
Ишетерсең җилләр тирәсендә...

Лилия ФӘТТАХОВА

Ә син саклан кабат ялгышудан, Кабаланмый гына ашык, яме...

УЙЛАНУ

Киткәннәр көтәдер дигән уй килгәли...
Көтәдер безнең дә кайтасы көннәрне.
Һәм шулчак, бәгырьне телгәли-телгәли,
Вакыт күк тарала хәятнең өннәре.

Бүләкнең иң зуры – кул белән орынмас,
Кадере беленмәс Вакыт ул...
Иң затлы касәдән татлы сут уртлыйбыз
Һәм... йөзне читабыз: «Ватык ул...»

Һәр җанда бу Җирне яктырак итәрлек
Ут-чыраг булуын оныттык...
Аяныч түгелме: без Җирне никадәр
Аяусыз рәвештә корыттык...

Вакытның үзен дә, камчылый-камчылый,
«Йөгенер ул безгә!» дидекме?!
И адәм затлары! Без соң бу бакыйны
Мәңгелек булыр дип белдекме?
«Вөҗүден күргәнче – гадәме хәерле»**
Дип кемнәр озатыр кемнәрне?..
... Киткәннәр көтәдер дигән уй килгәли.
Көтәдер безнең дә кайтасы көннәрне...

*** Булуыннан булмавы хәерлерәк мәгънәсендә.*

МИЗГЕЛЛӘР СИБЕЛӘ

Күкләрнең учыннан мизгелләр сибелә...
Сизгер җан өчен ул ябалак кар сыман.
Өн салып уздыңмы кардагы эзеңә?
Сизденме: ул эзгә мизгелдә тар сыман...

Эзләрең көтәләр туган як юллары,
Комнары чал диңгез ярының...
Мизгелнең мең төрле шифасын тоярга
Мең төрле сукмагы бар аның.

Мизгелләр сибелә... чәчелә, түгелә,
Йотыла, онтыла... Мизгел лә!
Кем әле гомерне мизгелләп үлчәгән,
Дуамал нәфесен тезгенләп?!

Мизгелләр сибелә Күкләрнең учыннан –
Чылатып Вакытның керфеген...
Кыйраты* кыйбат та, танучы сирәк шул
Кар көрте эченнән бердәнбер бөртеген.

Мизгелләр сибелә..
Тотып кал...

** Кыйрат – карат (үлчәү берәмлеге).*

ТУРЫЛА!

Юлларыңны йөрәгеңә карап
Турыла син... Йөрәк укларына!
Кемнең барлыгына дертләп куяр,
Һәм сискәнер... кемнең юклыгына.

Юклык ешлыгында дөм-караңгы.
Кемнәр адашмаган ул ешлыкта??
Кемнәр хаталардан сукмак түшәп,
Килеп егылмаган шыр бушлыкка?!

Ә син саклан кабат ялгышудан,
Кабаланмый гына ашык, яме.
Икебезгә тик бер сорау хәзер:
«Йөрәк угын миңа төбәлгәнме?»

* * *

Итәк асты уеннарын
Үз иткән бу заманда,
Ак белән караны бутау
Дәвам итәр һаман да.

* * *

Авыр холыклы кешегә –
Дөнья көндәш кебек.
Күркәм холыклы кешегә –
Дөнья тиндәш кебек.

* * *

Һай, Алланың кашка тәкәләре!
Мөһер сезнең кулда диярсең.
Хакның барын онытмагыз әле –
Һәммәбезгә өлеш тиясе.

* * *

Берне ун дип күрсәтеп тә була,
Унны бер дип күрсәтеп тә була.
Ялган белән шыплап тулса дөнья,
Унның унлыгы да онытыла.

* * *

Хыялдан – ният хуплырак,
Нияттән – кылган гамәл.
Уйларың изге булса да,
Эшең күренә әүвәл.

СҮЗ

(Мәсәл)

Бер Сүз, игезәген күреп, куркып киткән:
Бигрәкләр дә төссез, ипсез, өтек икән.
Сүз беркавым өнсез торган, ә аннары
Сорап куйган: «Ник син төптә, мин – югары?»

– Аптыравың урынлы да сыман, юк та, –
Икенче Сүз башын игән бу хурлыктан.
– Синең бәхет – күрде сине бер Зур Исем,
Зур Исемнең Сүзе булгач, ник кер тисен?

Йөрисең син үз дәрәҗәң белеп кенә,
Ә миңа гел карадылар көлеп кенә.
Ишетеп тә ишетмәгән кыландылар,
«Мин дә шул ук Сүз» дигәнгә хурландылар.

– Тик иямә була гына бу кадерем?
– Казый түгел, әйтә алмам ул кадәрен.
Мин бары тик шуны гына төгәл беләм:
Кешене – Сүз, Сүзне кеше күтәрә лә.

RS. Бу мәсәлгә сүз ахырын яза алмыйм,
Мин дә Хакны тик бер яклы гына аңлыйм.
Зур Сүзнең дә кечерәеп калганы бар,
Чүп Сүзнең дә биек урын алганы бар...

УЯУЛЫК КЕМГӘ КИРӘК?

(Мәсәл)

Шулай бер заман уйга калган Елан:
«Зирәклегем – таман, агуым – яман,
Нишләп дөнья хакиме түгелмен һаман?!
Мин шуышкач, башкалар да шуышсын,
Мәрхәмәтем көтеп, койрыгыма елышсын!"

Бар еланны үз янына ул туплаган.
Елдамнарын үсендергән һәм хуплаган:
«Өнсез-тешсез диеп сезне белсеннәр,
Һич курыкмый, гел җай гына йөрсеннәр.
Уяулыкны югалтуы тиз аны –
Шул чагында яуларбыз без дөньяны!

Куяннары өркә-өркә сырышыр,
Аюларга читлек-тозак булышыр,
Сиздермичә генә һөҗүм итәрбез,
Ваемсыз чаклары җитәр! Көтәрбез!»

PS. Елан үрчесә, пошмаслык куркыныч.
Мәкер азса, ничек яшәрсең тыныч?!
Акыллы дошманны җиңәрсең бары
Үткен күзең булса һәм үткер кылыч.

* * *

Сүз көтмәгез миннән...
Мин үзем дә
Көтәм сүзне олпат агайлардан.
Сүзне әйтсен кыю йөрәк белән –
Җилнең исү көчен абайлаган.
Ә минем сүз –
яшьле сүз ул бары...
Яшел сүз ул.
Ул соң кемгә кирәк?!
Авыр чакта сүзнең егәрлесе,
тик зирәге була ала терәк.
Сүз көтмәгез миннән...
Мин үзем дә
тилмерепләр көтәм акыллы сүз.
Инә сыман тишеп,
Сипләсен ул!
Мин җеп сыман
Иярермен сүзсез.

* * *

«Ахырзаман, – дибез. – Һәр сыйфаты
Туры килеп тора. Менә хикмәт!»
Һәм шуннан соң... тәүбә итәбезме?
Китабезме туры юлдан иплап?
Шулай булса кана!
Шулай булса,
Гел кирегә китмәс иде дөнья,
Гөлбостанның гөләпләре чирләп,
Тоташ әнә булып кипмәс иде.
Акны ак дип әйтүдән дә куркып,
Азап чикмәс иде адәм заты,
Чүкмәс иде черек нигезләргә,
Инсан дигән горур атын сатып...
«Ахырзаман...» дибез.
Буп-буш сүзләр
томан кебек тарала да бетә...
Сез дә сизәсезме??
Җир йомгагын,
һич аямый,
Елгыр заман сүтә...
Тәүбә...тәүбә...

Чаллы.

1943 елның февралендә Калинин фронтында актив һөҗүм хәрәкәтләре алып баручы 22 нче армия карамагындагы 91 нче укчы бригаданың 2 нче аерым батальоны рядовое — 20 яшьлек комсомолец Александр Матвеевич Матросов, Калинин өлкәсенең (хәзер Псков өлкәсе) Великие Луки районындагы Чернушки авылы өчен барган сугышта, гранаталары һәм автоматында патроннары беткәч, дошман дзоты амбразурасын күкрәге белән каплый. Үлемсезлеккә адымны Александр 11 сәгать 15 минутта ясый. Ул заманында легендар Зоя Космодемьянскаяны җәзалаган 197 нче немец пехота дивизиясе башкисәрләренә каршы көрәштә батырларча һәлак була... СССР Югары Советы Президиумының 1943 елның 19 июнендә игълан ителгән Указы нигезендә, А.Матросовка Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Ул хезмәт иткән укчы бригада исә 56 нчы гвардияче укчы дивизия карамагындагы А.Матросов исемендәге 254 нче гвардияче укчы полк итеп үзгәртелә. Александрның исеме часть сугышчыларының 1 нче ротасы исемлегенә мәңгелеккә кертелә...

● Александр Матросов.

● Уфада А.Матросовка (Ш.Мөхәммәтҗанов) һәйкәл.

МАТРОСОВЧЫ

МАТРОСОВЧЫЛАР КҮПМЕ?

А.Матросов үрнәгендә фидакярлек күрсәткән батырларны без дистә еллар дәвамында «матросовчы» дип йөрттек. Безгә шундый каһарманнардан 438 кешенең исем-фамилиясе ачыкланды. Шуларның 250гә якыны – утыз яшькә дә җитмәгән. Якташыбыз Филипп Мазилинга исә (Аксубай районыннан) тиңдәшсез фидакярлек күрсәткәндә илле яшь тулган була.

Матросовчылар исемлегенә элекке СССР территориясендә яшәгән барлык милләт вәкилләре дә кергән диярлек. Арада ике хатын-кыз – Николай Гастелло исемендәге партизан отряды разведчигы Римма Шершнёва, медицина хезмәте кече лейтенанты Нина Бобылёва һәм ике яшүсмер – «Октябрь» партизан отряды диверсанты, шартлатучы Миша Белуш, 252 нче укчы дивизиянең 332 нче аерым разведка ротасы рядовое Толя Комар да бар...

Эзләнүләр барышында дулкынландыргыч фактларга тап булдык: Бөек Ватан сугышы елларында А.Матросовка кадәр үк совет сугышчыларыннан 65 кеше (!) күкрәкләре белән дошманның ут ноктаһарын томалаган! Шулардан иң беренчесе – танкист Александр Константинович Панкратов. Ул – Бөек Октябрь социалистик революциясе яшьтәше. Тумышы белән Вологдадан. 1941 елның 24 августында Новгород янындагы Спас-Нередица авылында хәрби машинасы сафтан чыккач, Александр иптәшләрен атакага күтәрә һәм дошманның ут ноктасын күкрәге белән каплый. Бу батырлыгы өчен аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Легендар политрук турында 1941 елның 20 ноябрендә «Правда» газетасы да язып чыга...

Җыеп әйткәндә, 1941 елда ун сугышчы дошманның ут ноктаһарын күкрәге белән каплый. 1942 елда бу сан – 44 кә, 1943 елда 107 кешегә җитә (1943 елдагылар арасыннан 1 гыйнвардан 27 февральгәчә – А. Матросов батырлык күрсәткән көнгәчә – тагын 11 кеше күкрәкләре белән дошман амбразураларын каплап һәлак була). 1944 елда шундый батырлык күрсәтүчеләр саны ике йөздән артып китә. 1945 елда 74 сугышчы үлем уклары сибүче дошман дзотлары амбразураларын күкрәкләре белән каплый (бу исәпкә милитаристик Япониягә каршы көрәштә батырларча һәлак булган 13 матросовчы да керә).

Мондый каһарманнарыбызның йөздән артыгы – коммунистлар, өч йөзгә якыны – ВЛКСМ членнары. Шуларның 169 ына Советлар Союзы Герое дигән исем бирелгән; калганнарның күпчелеге төрле дәрәҗәдәге орденнар белән бүләкләнгән. Араларында бүләксез калганнары да бар...

Мондый фидакярлек үрнәген беренче мәртәбә күп еллар элек Пелёвин фамилияле сугышчы күрсәтә. Ул 1919 елның июнендә «революция бишеге» Петроград янындагы Керестенево авылы тирәсендә генерал Юденичның акгвардиячеләренә каршы барган хәлиткеч көрәштә күкрәге белән дошманның ут өермәсен каплый... Тумышы белән Башкортстанның Нуриман районы Иске Бөреч авылыннан булган ветеран-педагог Габит Хәммәтнуровның безгә җибәргән хатыннан күренгәнчә, Гражданнар сугышы чорында Быков фамилияле солдат та шундый батырлык күрсәткән. Әлеге факт Советлар Союзы Маршалы К.Ворошиловның истәлекләрендә сакланып калган. Тик мондый егетлек үз вакытында тиешенчә бәя алмаган, киң яктыртылмаган...

Инде Бөек Ватан сугышы чоры каһарманнарына килсәк, архивларда җентекле эзләнүләр алып барган саен, Панкратов-Матросов-Гафиятуллин кебек фидакяр җаннарның тагын да күбрәк булачагына шигебез юк. Әлеге фикерне раслау өчен, күренекле эзтабар публицист Эдуард Поляновскийның 1997 елның 29 гыйнварында «Известия» газетасында дөнья күргән гастеллочылар һәм матросовчылар турындагы күләмле язмасыннан бер өзек китерик: «С полковником в отставке Александром Петровичем Коваленко я познакомился в Подольском архиве. Он собирал данные о гастелловцах, талалихинцах, маресьевцах и матросовцах... Работа огромная, факты интересные. Матросовцев за войну набралось 470 человек. Из них 9 человек, закрывших грудью амбразуру, остались живы... 83 человека до подвига Матросова стали матросовцами».

Подольск шәһәрендәге Россия Саклану министрлыгы Үзәк архивында гына да биш миллиард (!) тарихи документ саклана. Илебезнең төрле төбәкләреннән үтенеч-сорау белән бирегә көн саен уртача 2500 хат килә. Әмма архив хезмәткәренең хат авторларына үз вакытында җавап бирергә мөмкинлекләре чикле. Дөрес, бер үтенеч-сорау да җавапсыз калдырылмый. Әмма аны күпчелек очракта айлар буе көтәргә туры килә. Ә инде архивка үзең «казынырга» барсаң, бу мәсьәлә чагыштырмача җиңелрәк хәл ителә.

● Нух Идрисов.

● Әхмәтгали Мөхәммәдиев.

Дошманның ут ноктаһарын күкрәкләре белән пехотачылар да, диңгезчеләр дә, танкистлар да, чик сакчылары да каплаган. Ленинград шәһәрен саклап калу өчен барган сугышларда гына да 54 кеше шушы соңгы чарадан файдаланган. Алар арасында офицерлар да шактый.

Матросовчыларның кайберләре амбразурага берьюлы икәүләп яисә өчәүләп ташланган. Мәсәлән, 1942 елның 29 гыйнварында борынгы Новгород янында сержант Иван Герасименко, рядовойлардан Леонтий Черемнов һәм Александр Красилов, төнге һөҗүм барышында дошманның берьюлы өч дзотын күкрәкләре белән каплап, сугышчан иптәшләренә җиңүгә юл ача... 1942 елның 18 августында Сталинград өчен барган сугышларда политрук Пётр Гутченко белән взвод командиры Александр Покальчук та шундый ук каһарманлык үрнәге күрсәтә.

1944 елның 23 июнендә Витебск өлкәсенең Остров Юрьев (Осинторф) пункты өчен барган сугышларда татар халкының гаярь улы – гвардия кече сержанты Барый Шәвәлиев белән украин егете – гвардия лейтенанты Иван Ильченко, икәүләшеп, дошманның бер үк ут ноктасын күкрәкләре белән каплый. (Бу хакта атаклы эзтабар Шамил ага Рәкыйпов «Чәчәкләр сөйли белә» дигән документаль повесть та язды.)

Инде үзебезнең матросовчыларга килсәк, аларның саны 25 кешегә җитте. Шуларның бишесе – офицер. Каһарманнарыбызның дүртесе – рус, берсе – чуаш, егермесе – татар (милләттәшләребезнең өчесе – Башкортстаннан). Алар күбрәк булырга да мөмкин...

Каһарман якташларыбызның туган җирләре – Аксубай, Арча, Әлки, Әлмәт, Баулы, Балык Бистәсе, Биектау, Бөгелмә, Буа, Кукмара, Лениногорск, Мамадыш, Менделеевск, Тәтеш, Чүпрәле, Югары Ослан районнары. Дүрт батыр – Казаннан. Ватанпәрвәрләрнең каберләре Витебск, Гомель, Кировоград, Курск, Ленинград, Смоленск, Одесса, Орёл, Псков, Ростов өлкәләрендә, Новороссийскида, Карелия-

● Газинур Гафиятуллин.

● Александр Панкратов.

ГЕРОЙЛАР

дә. Дүрт каһарман исә Венгрия, Германия, Польша җирләрендә мәңгелек йокыга талган...

ҖЫРГА КҮЧКӘН КАҺАРМАНЛЫК

Алдыбызда – Татарстан АССРның Бөгелмә районында 1941 елның 15 августында оешкан 352 нче укчы дивизиянең командиры – татар генералы Рәхим Сәхибгали улы Мәксүтов (1899-1949) исеменә язылган политдонесение. Анда 1162 нче укчы полк сугышчысы – сержант Әхмәт Мөхәммәтовның Смоленск өлкәсенең Груздево торак пункты янында 1942 елның 12 июле иртәсендә фашистларның позицияләренә сугышчан разведка ясаганда, күкрәге белән дошман дзоты амбразурасын каплап һәлак булуы бәян ителә (Әлеге полкның партоешма секретаре вазифасын шагыйрь Нур Баян башкара). Архивларда кат-кат эзләнү нәтиҗәсендә 1919 елда туган Әхмәт Мөхәммәтовка кагылышлы байтак документлар табылды.

Аларның беренчесе – Орша исемендәге Кызыл Байрак һәм Суворов орденлы 352 нче укчы дивизия сугышчыларының Татарстан АССР Югары Советы Президиумы Председателе Г.А.Динмөхәммәтовка адресланган хаты. 1943 елның 5 мартында «Правда» газетасында «Татар халкының фронтовик татарларга мөрәҗәгате» басылып чыга. Республикабыз хезмәт ияләре әлеге хатта үз сугышчыларына дошманны аяусыз тукмарга наказ бирә. Шул уңайдан дивизиянең барлык частьларында хатны ныклап өйрәнү оештырыла. Ул сугышчылар күңелендә киң яклау таба. Күңелләрендә кайнаган уй-хисләрен белдереп, алар Татарстанга хат җибәрә:

«...Фронтка киткәндә без фашист-илбасарларга каршы көрәштә сезнең дә, үзебезнең дә йөзгә кызыллык китермәскә сүз биргән идек. Бүген исә без сезгә шатланып рапорт бирәбез: беренче сугышлар алдыннан Татарстан хезмәт ияләре тапшырган Байракларны без мәңгелек данга күмдек.

Илебез йөрәге Мәскәүне – һәркемнең күңеленә үтә якын, сөекле, искиткеч гүзәл башкалабызны саклап калу, дошманга бирмәү өчен, без, Кызыл Армиянең башка частьлары белән берлектә, батырларча көрәштек. 1941 елның салкын декабрь көннәрендә без ләгънәт төшкән фашистларны артка таба кудык. Алар бик нык каршылык күрсәтте. Әмма безнең омтылыш барысыннан да көчлерәк булып чыкты. Без, актив сугыш хәрәкәтләре ярдәмендә, Туган илебезне дошманнан азат итә-итә, алга таба юл алдык. Сержант Әхмәт Мөхәммәтов үзенең гәүдәсе белән дошман дзоты амбразурасын каплады. Герой һәлак булды, ләкин ул үзенең каһарманлыгы белән безнең частька җиңү яуларга ярдәм итте...»

Әнә шулай, әлеге тарихи документта Ә.Мөхәммәтовның исеме беренче итеп зурлап телгә алына. (Бу хат Татарстан Республикасы Милли музееның Бөек Ватан сугышы фондында саклана.)

СССР Саклану министрлыгы Үзәк архивында табылган икенче документ та гаять кызыклы. 352 нче укчы дивизиянең «Вперед, на Запад!» дигән газетасында (1943 ел, 27 июнь саны) капитан Пискуновның «Сержант Мөхәммәтов үзенең хәрби антын ничек үтәде?» дигән материалы басылган.

Тагын шундый бер факт та ачыкланды: ВКП(б) сафларына кандидат итеп кабул ителүенең икенче көнендә Әхмәт Мөхәммәтов батырларча һәлак була! Шул көнне сержант Мөхәммәтов сугышчан иптәшләре алдында чыгыш ясап, илебезне фашист илбасарлардан азат итү өчен соңгы сулышынача, ахыргы тамчы кайнар каны тамганчыга кадәр көрәшәчәге турында белдерә. Әле вафатына берничә атна кала ук Мөхәммәтов, бер төркем иптәшләре белән дошманның алгы сызыгына ясаган разведкалары өчен (алар фашистларның ике тубын, снарядлары белән бергә, кулга төшереп, безнең якка чыгара), 5 нче армия командующие – Советлар Союзы Герое генерал-лейтенант И.И.Федюнинский приказы нигезендә, «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән була... 12 июль иртәсендә дә ул бурычын тулысынча үти. Полк сугышчылары, яраткан командирларына багышлап, «Сержант Мөхәммәтов турында җыр» да иҗат итә. Минск исемендәге Кутузов орденлы 1162 нче укчы полкның сугышчан юлын яктырткан махсус альбомга язылган ул. Җыр частьның политбүлек документлары арасында да, махсус листовкаларда да бар. Менә ул (аны русчадан күренекле шагыйрь Рәниф Шәрипов тәрҗемә итте):

Комсомол үстергән батырның
күңелендә
Иленә, халкына тугрылык –
Сугышта чыныккан
Мөхәммәтов-сержант
Дошманга ташлана ыргылып!

Илбасар тез чүкте, яудашлар үз итте –
Сугышта арыслан кебек ул!
Гел үрнәк күрсәтеп, һәркемне ияртеп,
Җиңүгә юл ярган егет ул!

Йөзләгән һөҗүмдә булдык без гел бергә,
Күзгә-күз очраттык үлемне...
Сигез кат үлде ул, сигез кат терелде:
– Саклыйм, – дип, – яңадан Илемне!

Һөҗүмне туктатып, ут чәчә пулемет,
Чиныйлар ядрәләр очканда.
Тик баса бу шауны сержантның
тавышы:
– Мәрхәмәт күрсәтмә дошманга!

Җиңүгә юл ачып,
Мөхәммәтов-сержант
Дзотны каплады ыргылып...
Киселде яшь гомер,
тик калды җырларда
Мәңгегә бу изге тугрылык!

Җыр белән сугышчан Байрак янәшә йөргән. 23 яшьлек Әхмәт Мөхәммәтов, үлгәннән соң да, сугышчан иптәшләрен гел җиңүләргә рухландырып торган...

Эзләнүләр барышында безгә шундый ук исем-фамилия йөртүче икенче матросовчыга кагылышлы архив документларын табу насыйп булды. Анысы – Мамадыш һәм Кукмара районнарының уртак герое – Харьков исемендәге 299 нчы укчы дивизиянең 960 нчы укчы полкы разведчигы, 20 яшьлек рядовой Әхмәт Мөхәммәтов (аның тулы исем-фамилиясе Әхмәтгали Мөхәммәдиев булган. Әмма хәрби документларда ул «Әхмәт Мөхәммәтов» яисә «Мөхәммәдов» диеп кыскартылып йөртелә).

Еллар үткәч, Мамадыш районының Югары Ушмы урта мәктәбе каршында батыр разведчик Әхмәтгали Мөхәммәдиевкә мәһабәт бюст-һәйкәл ачылды (скульпторы – А.Әбдрәшитов), документаль фильм төшерелде (режиссеры – К.Арифуллов). Шундый ук фильмны Кукмара һәм Мамадыш районнарының уртак каһарманы – 1944 елның 27 июлендә Карелиядә батырларча һәлак булган 26 яшьлек матросовчы-шагыйрь, лейтенант Нух Идрисовка (1918-1944) багышлап та эшләдек. Нух Идрисовка да туган ягында һәйкәл куйдык.

Тагын республикабызның беренче матросовчыларыннан саналган рус егете А.Л. Панарин белән дә таныштырып үтик. Тумышы белән Баулы районының Кырымсарай авылыннан ул.

112 нче укчы дивизиянең взвод командиры, комсомолец лейтенант Афанасий Леонтьевич тиңдәшсез батырлык үрнәген 1943 елның 26 мартында – А.Матросов һәлак булганнан соң бер ай чамасы вакыт үткәч, Курск өлкәсенең Романово, Ефросимово авыллары янында күрсәтә. Дошманның яхшылап ныгытылган терәк пунктын алу өчен бәрелештә А.Панаринның танкка каршы ата торган артиллерия взводы арысланнарча сугыша. Әмма көчләр тигез түгел. Пушкалар да, кешеләр дә берәм-берәм сафтан чыга. Афанасий, яу кырында һәлак булган иптәшләре урынына басып, орудиене үзе кора, үзе ата. Ахырдан пушкасы ватыла, үзе яралана, уң кулы чәрдәкләнеп бетә. Батыр комсомолец югалып калмый, сул кулына граната тотып:

– Ватан өчен, халкым өчен, алга! – дип кычкыра һәм дошман дзотына ташлана.

Көчле ут көлтәсе һәм шартлау безнең сугышчылар өчен һөҗүмгә чакыру булып яңгырый. Исән калганнарның барысы да, бердәм күтәрелеп, соңгы, хәлиткеч һөҗүмгә ташлана. Шулай итеп, терәк пункт кулга төшерелә.

Каһарман якташыбыз А.Панаринга бу вакытта нибары 19 яшь була. Аның гәүдәсен Ефросимово авылы уртасына җирлиләр. Авыл кешеләре 1964 елда үзләре җыйган акчага батыр матросовчыга һәйкәл куя. Авыл Панарино дип рәсмиләштерелә, урта мәктәпкә герой исеме бирелә. Кинорежиссер һәм язучы Александр Очкин полкташ дустына багышлап «Үлемсезлеккә атлаган батыр» дигән китап язды...

Буа районының Әлшәй авылында туып-үскән чуаш егете Арсентий Карташов, Днепр буенда тиңдәшсез фидакярлек үрнәге күрсәтеп, 18 яшь тулган көнендә һәлак була. Аның белән бергә Арча районының Шушмабаш авылы егете Кәрим Исхаков та каһарманлык үрнәген күрсәтә. Әлеге матросовчыларга багышлап күренекле чуаш язучысы Антип Николаев «Ак каеннар мәңге уяу» дигән документаль повесть та иҗат итте.

(Дәвамы киләсе санда).

Шаһинур МОСТАФИН.

Мәдәни җомга
18 март
№10, 2021

ХУШ, АГЫЙДЕЛ

Ягъсуф ШӘФЫЙКОВ

(Дәвамы. Башы 9 нчы санда).

Чыннан да механизаторларның бәрәңгедән кала башка ашамлыклары юк иде инде. Сил башланганнан бирле, балык тотарга да мөмкин түгел. Аннан соң аны күрсәсе дә килми иде инде.

Иске елга буенда киңәшкәннән-сөйләшкәннән соң, Рамил белән Мирсәет буржуйкага ягарга дип, өйләренә кайтып киттеләр.

...Фатих бабай хәрәкәтсез генә Агыйдел ярында утырды һәм кышка әзерләнүче салкын сунның көчле агымы белән тау-тау силларны агызып китүен күзәтеп торды. Нәкъ менә әйтеп бетергесез авыр тормышның чиксез океанындагы аның еллары инде. Югарыда эт кырылдап, сикергәләп куйды. Тычкан тотмакчы иде, ахрысы. Ләкин аның бу сунарчылыгыннан берни дә килеп чыкмады.

Карт һаман шушы туган җирләрендә уздырган еллары турында уйлый иде.

Камада гидроэлектростанция белән бергә Түбән Кама плотинасы төзеләчәге турында мондагы кешеләр беренче тапкыр 1965 елның язында «Социалистик Татарстан» газетасыннан укып белделәр. Аннан соң бу турыда Татарстан радиосы сөйли башлады. Электр станциясе бик күп энергия бирәчәк дип сөйләделәр. Ә аның Чаллыда төзеләчәген берәү дә белмәде. Түбән Кама шәһәре турында да ишеткән юк иде. Түбән Кама ГЭСы Каманың иң түбәнге өлешендә төзелергә тиеш бит иде. Бөтен трагедиянең дә әнә шул «түбән» дигән сүз кысасында булуы берәүнең дә башына килмәде. Актанышлылар Чулманның урта өлешендә диярлек яшәделәр. Чулман белән Агыйдел арасындагы өчпочмакта.

Алтмыш алты, алтмыш җиденче елларда инде яңа ГЭСның гаять зур сусаклагычы Камадагы Боткин ГЭСына һәм Бирск шәһәренә кадәр һәм Агыйделгә таба әллә кайларга барып җитәчәк, кеше кулы белән эшләнгән диңгез меңләгән гектар сөрү җирләрен, Кама һәм Агыйдел буендагы атаклы болыннарны басачак икән дип сөйли башладылар. Актаныш районындагы зур-зур авыллар: Өшәр, Чиялек, Урыс һәм Татар Әҗбие, Агыйдел белән Кама кушылган урындагы үзенең егәрлекле затоны һәм зур бистәсе булган Дербешка пристане һәм тарихи Көләгеш ярындагы кечкенә Урдалы авылы да күчереләсе икән бит.

Шундый сүзләр йөри башлагач, баерак һәм тәвәккәлрәк авылдашлар экренләп хуҗалыкларын сатып, Удмуртиянең Кама буендагы борынгы шәһәре Сарапулга күчеп китә башладылар. Күрше республиканың монпан йөз чакрымнар ераклыкта урнашкан бу шәһәре Актаныш районы кешеләрен элек-электән үзенә тартып тора иде. Мондагы кешеләр көнбатыш юнәлешендә Минзәлә төрмәсеннән кала берни дә белмиләр иде. Җитмешенче еллар ахырына кадәр Минзәләгә, аннан ары Чаллыга кадәр берни юл да юк иде. Түбән Каманы һәм аның комбинатын, аннан соң Чаллы промышленность үзәген төзегәнгә кадәр бу урыннар Алланың ташландык җире иде. Шуңа күрәдер, җирле бай-партократлар власте тарафыннан җәберләнгән күп кенә кешеләр чагыштырмача демократик булган якларга – Удмуртиягә һәм Пермь өлкәсенә күчеп китәләр иде. Ә менә Сарапулны үзләренең икенче Ватаны дип санылар иде. Күпчелегенең бу борынгы матур сәүдәгәрләр шәһәрендә туганнары яши иде. Эшче кулларның да кадерен беләләр иде бу шәһәрдә. Сугыш елларында биреге Мәскәүдән һәм Питердан бик зур оборона заводлары күчерелде. Алар сугыштан соң да шунда калдылар, заманча хәрби техника җитештерделәр, югары үсеш алган социализм чорында да, торгынлык елларында да шуны дәвам иттеләр.

Җәен, Сабан туе көннәрендә, Өшәргә, Татар Әҗбиенә, Чиялеккә, Урдалыга күп кенә элеккеге авыл кешеләре кайта, бәйрәмнәр бик күңелле үтә торган иде. Шәһәрдә яшәүче авылдашлар киткәннән соң авыллар бушап, тынычланып кала. Печән чабу башлана. Аның бер көне кыш буе мал-туарны туендыра, икенче төрле әйтсәк, Актаныш районының экияттәгедәй гүзәл почмагында яшәүче барлык кешеләрне азык-төлекле итә.

КамАЗ автогигантын һәм Яңа шәһәрне төзи башлагач, зур су һәм авылларны күчерү турында сөйләшүләр бераз тынып торды. Зәй ГРЭСы энергоблокларын җибәргәч, Түбән Кама химия комбинатының һәм КамАЗның җылылык энергетикасы комплексларын төзегәч, Камада гидроэлектр станциясе салып энергия арттыруның кирәге калмый икән дип уйлады халык. Түбән Кама ГЭСы төзелеше дәвам иткәнен, бары тик КамАЗ объектлары төзелешен тизләтергә кирәккәнгә финанслауны гына бераз киметкәннәрен гади халык каян белсен, ди. Нәкъ менә шул сәбәпле генә Түбән Кама ГЭСын файдалануга тапшыруны төгәл бер бишьеллыкка – совет кешеләре кырык ел буе шул норма белән яшәргә өйрәнгән чорга кичектерелде.

Өшәр авылы кешеләре, элеккечә үк, җир сөрделәр, чәчтеләр, югары уңыш үстерделәр. Печән җитәрлек иде, шуңа күрә күпләп мал-туар тоттылар. Гомумән, авыл кешеләре яшәделәр, балалар үстерделәр. Турысын гына әйткәндә, торгынлык дигән Брежнев еллары хәзерге демократик дип аталган таланган елларда нинди дер татлы төш кенә булып калды халык күңелендә. Кайгысыз, нужа белмичә унбиш ел яшәделәр.

Колхозның гади механигы Фатих Кәримов та үзенең тормышына шатланып бетә алмады. Еллар ераккарак алып киткән саен, ул кайгыртучан Фәридәсен тагын да яратарак төште, мәхәббәте белән ләззәтләнде. Җитмешенче еллар башына унҗиде яшьлек өлкән кызлары Рәзилә ифрат чибәр булып буйга җитте, бик акыллы һәм тотнаклы булып унбиш яшьлек Зөфәре, унөч яшьлек төпчеге Рәшит үсеп киләләр. Хет мең тапкыр әйт, барыбыр дөрес булыр – бәхетле еллар сизелмичә бик тиз үтеп китә. Бары тик еллар үткәннән соң гына уйлыйсың: бу тормышта булдымы, әллә төш идеме? Фатих Кәримов гаиләсе белән дә, хәер, аларныкы белән генә түгел, кайчандыр чәчәк атып утырган зур-зур авыллар: Өшәр, Чиялек, Урыс һәм Татар Әҗбие, Урдалы, Дербешка елгачыларының шәһәр кадәр бистәсе кешеләре белән дә шулай булды.

Бу авыллар кешеләренә бәхетсезлек күктән төшкән кебек булды. Әйтерсең лә бер зур самолет-бомбардировщик алар өстенә үлем чәчеп китте. Ә камәлдә исә бик гади генә иде. Чаллыда КамАЗның беренче чиратын файдалануга тапшыргач һәм Яңа шәһәрнең байтак өлешен төзегәч, СССР хөкүмәте Түбән Кама ГЭСы төзелешен тизләтергә карар бирде. Әзерлек эшләре өчен, шул исәптән су астында калачак авылларны күчерү өчен дә бик күп акча җибәрде.

Көннәрнең берендә колхозчыларның «бәлки су басмас әле, шушы изге җиребездә яши бирербез» дигән хыяллары минуты белән юкка чыкты. Райком «Волга»сында Өшәргә КПССның Актаныш райкомы беренче секретаре Хәнәф Мирзаевич Низаметдинов җитәкчелегендәге бик мөһим делегация килде. Аның составында беренченең хатыны, район Советы башкарма комитеты рәисе урынбасары Кәримовна (районда аны шулай дип кенә атыйлар иде), ТАССР Министрлар Советының су басу зонасы идарә начальнигы һәм төзелә торган Түбән Кама ГЭСы вәкиле дә бар иде. Делегация колхоз клубы янына Өшәр халкын җыйды. Менә шушында инде Низаметдинов зур күзләрен үгезнеке шикелле акайтып, бу авылның күчәчәге, моның өчен һәр хуҗалыкка бик күп акча биреләчәге турында әйтте. Урын сайлау һәркемнең үз иркендә икән, ләкин райком, автомобиль спидометры белән исәпләгәндә, моннан ун чакрымнар ераклыктагы Ямалы авылы кырыендагы калкулыкны тәкъдим итә.

Әллә инде шушындый хәбәрне җиткерү секретарь өчен бик авыр булды, әллә натурасы шундый идеме, ялкынлы нотыгыннан соң Хәнәфнең юан муенын, битен, күзләрен чиертсәң бәреп чыгардай булып, кан басты. Әллә йөз-кыяфәте шундый булганга, район авылларында аны «Үгез» дип йөртәләр иде. Актаныш халкы бик телчән, кушаматларга, кеше исемнәрен кыскартып әйтүгә бик оста. Низаметдиновка «Үгез» кушаматы бик тәгәл булып бөтен гомеренә ябышты. Актаныш җирендә берничә ел секретарьлык иткәндә бәлки аны үзе белмәгәндер дә, ләкин шул кушаматы белән ул Казанга, чиктән тыш куәтле оешмага – КПСС өлкә комитетына китеп барды. Аның ише «яхшы гамәлләр, исемнәр» бик тиз тарала бит. Хәнәф Мирзаевич Татарстан Республикасының югары дәүләт постында эшләгәндә журналистлар да үзара Низаметдиновны «Үгез» дип йөрделәр. Чыннан да еллар үтү белән ул тагын да тазара төште, тән тиресе шоп-шома булды, шулай итеп ул куәтле чиновниктан испанлылар коррида га чыгара торган үгезгә охшап калды.

Җыелыш бу якларда соңга калып килә торган язның кояшлы көнендә булган иде. Колхозчылар барыбер чәчәсен чәчте. Милли бәйрәмебез – Сабан туйларын да уздырдылар. Халык теләр-теләмәс кенә күңел ачты, әйтерсең ул үзен гаепле сизеп, ниндидер хезмәт йөкләмәсе үти. Ир-ат гомердә булмаганча эчте.

Хезмәткә яраклы халык иске елганың теге ягына печән чабарга киткәч, Өшәр техника белән тулды: чехларның кызыл экскаваторы, артына чүмечен, алдына кырдыргычын таккан «Беларусь», ике «КамАЗ» үзбушаткычы. Бу армаданы «ПАЗ» автобусы озата килде. Бөтен техника авыл читендә туктап калды, ә «ПАЗ» колхоз идарәсе белән авыл Советы янына кадәр үтте. Автобустан өстенә төзүчеләрнең яшел формасын кигән илле яшьләр тирәсендәге бер ир чыкты. Блокнотына карап алганнан соң:

– Миңа авыл Советы рәисе Ильяс Насыйров кирәк иде, – диде.

Контора бинасыннан чыккан кешеләр, очраклы рәвештә шушы тирдә булучылар автобуста килүчеләрне кызыксынып күзәтә башладылар.

– Авыл Советы рәисе Ильяс Насыйровны кайда күреп була дип әйтүем, – дип кабатлады әлеге аксыл чәчле ир-ат. Ул, әлбәттә, татар кешесе түгел иде.

Бер мәл тын гына торганнан соң, җыелып кызыксынып торучылар арасыннан берсенең тавышы ишетелде:

– Әнә монда таба әбәттән килә...

Кешеләр төркеме янына илле яшьләр тирәсендәге кеше килеп басты. Бу Бөек Ватан сугышы ветераны, әллә никадәр орденнар, медальләр алган, авыл Советы председателе постына сайланган бик мөхтәрәм кеше Ильяс Насыйров иде.

– Нәмә булды? – дип сорады ул сагаеп кына һәм автобуска карап алды.

Теге аксыл чәчле ир-ат, бригадирмы, мастермы, шайтан белсен, менә шул килүчеләрнең җитәкчесе булса кирәк, авыл Советы рәисе белән русча исәнләште дә мәсьәләне аңлатты:

– Сезнең авылны күчерү өчен Чаллыдан килдек. Беренчедән, яшәп тору өчен сез безне кая урнаштырырсыз икән?

– Клубка, – диде Насыйров озак уйлап тормыйча. – Гомуми торак, кунакханә ишеләрнең бездә гомердә дә булганы юк.

Ильяс Насыйров урысча менә дигән итеп сөйләшә иде. Дүрт ел фронт тормышы юкка гына узмаган. Тегеләрнең өлкәннәре соравы белән тагын алга чыкты.

– Башта зиратны күчерәчәкбез. Кайсысыннан башлыйк? Искесеннәнме, әллә яңасыннанмы?..

ИСБАТЛАНГАН ТАРИХИ ДӨРЕСЛЕК

Без дөреслеккә туры килмәгән тарих укып, татар-монгол җәберенең Россиягә карата кылынган явызлыклары турындагы язмаларның иге-чиге юклыкка карамастан, нииндигер кабахәтлекләр турында атап әйтелгәннәрен укырга да, ишетергә дә туры килмәде. Чынлыкта, татарлар тарафыннан андый явызлыкларның булмавы турында, Мәскәүнең үзендә, 2004 елда 7 мең тираж белән бастырылган тарихчы-язучы Александр Бушковның «Россия, которой не было. Миражи и призраки» (булмаган хәлләрне бар итеп күрсәтергә тырышу) дип аталган 400 битле китабын укыгач, аңлашылды. Дөреслекне язган бу китапны бастырырга ничек рөхсәт иттеләр икән дип уйланып та калган идем. Соңгы ун елда, Россиядә бастырылган китаплар арасында, иң бәхәсле китап булуы турында әйтәләр.

Бу тарихчы-язучының китабында, Россия тарихындагы уйдырмалы язмаларга карата фаш итеп язылган кайбер җөмләләрен барлап карыйк әле.

Мөселман дөньясының ерткычлыгы турындагы язмалар дөреслеккә туры килми. Төрекләр ерткычлыгы (зверство) христиан хәрбиләренең төрле елларда башкарылган ерткычлыклары кадәр була алмый.

Басурманнар ерткычлыгы турындагы сүзләр, дөреслеккә туры килми.

Татар-монгол һөҗүме Азиядә генә түгел, Европада да зур роль уйнады.

Татар-монгол һөҗүменең христианнарга бәла булуы турында әйтелсә дә, нинди бәла булуы турында бер сүз дә атап әйтелми. Бернинди монголлар да юк. Алтын Урда татарлар һәм кыпчаклардан торган. Татар-монгол Урдасында бернинди дә монголлар булмаган. Басып алынган илләрнең берсендә дә татарлар үзләрен начар яктан күрсәтмәгән. Урда – зур армия, күчмә халык түгел.

Роман Галицкий, Иван Грозный кебек үзенең боярларын тереләй җиргә күмдергән, аларны тураклап, тереләй тиреләрен тунаган.

«Гомумән, Россия тарихында татар агрессорлыгы, явызлыклар булмаган. Дөресен әйткәндә, татарлар данлыклы, хезмәт сөючән, намуслы халык. Аларга карата оештырылган яла-ягулар – ахмаклык билгесе» дигән сүзләр язылган Александр Бушковның китабында. Аны шарлатан, дилетант, даһи тарихчы дип атаучылар табыла. Автор бу китабын язганда, 265 китаптагы язмаларны куллануы турында искә ала. «Әгәр кем дә булса мине гаепләргә тырыша икән, башта мин кулланган китапларны укып чыксыннар», – дигән ул.

Татарлардан Александр Бушковка рәхмәт сүзләре әйтү кирәк иде. Әйтүчеләр булдымы икән, анысын белмим. «Антропологиягә багышланган китап чыгару планда бар», – дип язган иде А.Бушков. Бәлки, Тишковның уйдырмаларын да фаш итәргә теләгәндер. Анысы да безнең файдага булыр, дип өметләник. Безнең халык хакыйкатьне белергә тиеш.

Рәфкать ИБРАҺИМОВ.

Кәгазьләр актарып утырганда, менә шушы «ачык хат»ка юлыктым. Моннан 23 ел элек аны күренекле шагыйребез Рөстәм Мингалим язган. Гәрчә хатның исеме күңелгә бик үк ятышып тормаса да, эчтәлеге шактый ук мавыктыргыч булып чыкты. Шуңа күрә мин аны «Мәдәни җомга» укучылары хөкеменә дә тапшырасы иттем. Берочтан ул Рөстәм абыйның якты рухына бер дога булып та барып ирешер дигән өметтә калам.

Г.М.

Кызганам мин сине, Газинур!

(Шагыйрь Г. Моратка ачык хат)

«Түбә» дип исемләнгән яңа китабыңны укыдым. Аны дөньяга чыгарырга булышканы өчен Кукмара районы хакимияте башлыгының беренче урынбасары Камил Шәймәрдановка минем рәхмәтем дә барып ирешсен иде.

Китабың турында зурдан кубып, күп итеп сөйләшергә була. Татар шигъриятенә үзенчәлекле яңа байлык өсти алгансың. Бу хатымда синең язу алымыңа ныклап керергә, үзенчәлегеңне тәфсилләп сөйләргә җыенмыйм. Әле шунысы да бар, аны кемгә сөйләргә? Укучыгамы? Укучыга ул кирәкми. Тәнкыйтьчеләргәме? Алар юк бит. Булганнары – әллә саф тәнкыйтьче булырга җөрьәт итмичә, әллә поэзиягә тешләре үтмичә – тиз арада әдәби әсәрләр язу эшенә күчәләр, рәхмәт төшкерләре. Шул сәбәпле, «Түбә» авторына мактау сүзе ирештерү дә, авыр сүз әйтү дә миңа кала инде. Артык үпкәләмәссеңдер.

Шигъриятебездә шәхес икәнеңне таныйм, әмма яңа китабың турында уйланам да мин сине кызганам, Газинур... Китабыңны мондый юллар белән ачкансың:

Кабынулар заманы бу,
Кабынулар заманы.
Әмергә түгел,
Хәтергә
Табынулар заманы.

Заман турында дөрес уй бу, яндырырлык итеп әйткәнсең. Ә кемнәр янар?

Халкың турында:

Ярык тагаракта Идел кичеп
Яткан мәле әле халыкның, –

дисең. Бу да дөрес уй. Бигрәк тә соңгы вакытларда бераз канатланып, талпынып йөргән татар турында болай образлы итеп яза белүең бик мәслихәт. Аннан:

Аңлаешсыз булдык, ахры,
Безгә шулай язган...
ТАРлыктан – татар, КАЗАдан
Яралгандыр Казан, –

дигән юлларың белән дә, хәтта «Без – исерек кораб җилкәннәре» кебек бер юлың белән үз буыныңның сурәтен, аның башын тинтерәткән уйларны, ул киерелеп көткән йөкне, шушы буынның бүген татарча ни дәрәҗәдә кирәклеген гаять тирән итеп әйтә алгансың. Ә бу тирәнлек кемгә кирәк?

«Ишелә көннәр... Егылам... Түнә баш... Каный канат... Янчелә чырай... Дөньяга мүкәләп чыгам кабат», – дип тә, башка күп шигырьләрең белән дә син татар халкының хәлен-хәлләтен, аның түземлеген, тырышып-тырмашып яшәргә җыенуын чын сәнгатьчә сурәтлисең. Әмма бу сурәтеңне кем күрә дә кем аңлый? Ярый, моны Ркаил Зәйдулла, Ләбиб Лерон, Ләис Зөлкарнәй кебек фикердәшләрең һәм талантта тиңдәшләрең аңлар. Тагын кем? Дөрес, бик эзләсәң – сине аңлаучылар тагын табылыр. Аларны, әгәр дә бик теләсәң, санап ис китәрлек зур булмаган саннарны барлап була. Шулар өчен генә синдәй акыл һәм көч сарыф итеп шигырь язу дөрес эш микән? Уйлан әле! Миңа бераз үпкәләп: «Киләчәк өчен язам!» – дияргә дә хакың бар. Бу уңайдан шуны искә алыйм, мәрхүмнәрнең рухлары мине кичерсен: әнә, Дәрдемәнд тә, Тукай да, Туфан да киләчәк буын өчен язганнар. Без әле дә аларны аңлап җиткерүчеләр күп түгел икәнне күрәбез. Кешенең уй йөртү радиусы коточкыч әкрен зурая, тиз кечерәя.

Китабыңдагы «Сәрхуш хатын», «Урам кызы» дигән шигырьләреңә «антишигырь» дип куйгансың. Дөрес түгел, алар чын шигырьләр һәм Газинур Морат кына күрә, ул гына әйтә белгән алым белән язылганнар. «Урам кызы»нда яшь хатынны өйдә нәни улы көтә, әнисенең сагыз алып кайтуын көтә. Әнисе төнге урамнарда һәм төнге кочакларда югалып йөри. Бу шигырьне укыган тиле – көләргә, акыллы еларга мөмкин. Шигырьгә фаҗига үзәге оста алынган. Инде «Сәрхуш хатын»дагы яшь ханым сөйләнүендә бирелгән кайбер юлларны да карыйк:

Ә син, алаканат,
Нәрсә каттың карап?
Йә син министр бул,
Йә бул ата карак.
Ә син, зәңгәр, бүген
Нигә кызыл түгел?
Ә син мине, ишәк,
Яратмыйсың нишләп?
Аңламыйсыз хәлне,
Әйдә, җырлыйк әле!
«Ни уңмадым ирдән,
Ни уңмадым мирдән,
Их...»

Әйе, бигрәк тә соңгы елларда тормыш изүеннән иләс-миләс хәлгә төшкән ханым – сыраханәдә. Өен, бер хатынын да карый алмаган алкашлар – сыраханәләрдә, сасы подвалларда. Ә кемнәр өстә бүген, кемнәр яши? Иләс-миләс ханым аны да белә: «Йә син министр бул, йә бул ата карак!» – ди. Сыраханәдәге үзебезнең татарлар ачык таныла, шулай ук анда – башка милләтләр, гомумән алганда, Русиянең «кадерле» кешеләре. Мондый шигырьләрне Русиядәге барлык милләтләр теленә тәрҗемә итәргә кирәк. Ә кем тәрҗемә итә? Аларны республикабызның барлык газета-журналларында бастырып чыгарырга, радиодан көн дә сөйләп торырга була, чын дөньяга кешеләрнең күзен ачу өчен, күңел бозларын эретү өчен... Тик алар кемгә кирәк, кем аларны сөйли? Кайда, кайчан сөйләделәр?

Тыңлый һәм ишетә белгән кешегә шигырьләрең оран сала! Ә кем аларны тыңлый да кем ишетә? Алдарак мин күрсәтеп узган кешеләр һәм вәссәлам. Шуның өчен дә кызганам мин сине, Газинур.

Син иҗатта тормыштагы Газинурга караганда кырысрак телле, кырысрак күңелле. Хәтта «Хәтернең ак дивары», «Ялгыз хатын», «Мәңгелек үкенеч» кебек лирик шигырьләреңдә дә шулай. Мондый үзгәреш шәхеснең үз хәятында җитешмәгән якны әдәбиятта тулыландырырга тырышуыннан килеп чыга: бу синең шигырьгә тулаем һәм эчкерсез бирелгән булуың, аны көрәш, ягъни яшәү мәйданы итеп тануың билгесе. Шушы хәлең сине сәясәткә – публицистикага кирәгеннән ешрак та мөрәҗәгать иттерә. Тик нишлисең? Кеше бәхете өчен көрәшүчеләр сафында торып иҗат итәргә ниятләгән шагыйрь сәясәттән качып яши алмый.

Шактый шигырьләрең һәм поэмаларың кергән бу китап синең нечкә лирик булуыңа да, үткен телле публицист булуыңа да инандыручы дәлил: «Шигърият Сараеңның түбәсе биек!» – диясем килә. Ләкин синең бу Сараең кемгә кирәк? Шуны да, моннан алдарак әйткәннәремне дә искә алып, сиңа иҗат Сараең түбәсен түбәнәйтергә кирәктер. Инде артык яшь булмасаң да, бу эшкә алда әле вакытың бар. Халкыңны яхшы беләсең, аның күпчелеге, сәнгатьне тануы һәм уй-фикер сөреше нисбәтеннән карагандa, балалык дәрәҗәсендәрәк тора. Шул балалар дәрәҗәсендә ярашу кирәктер сиңа. Авыр юл түгел ич ул. Төрле-төрле көйгә калын, йә нечкә авазлар чыгарсаң, мәгънәле һәм мәгънәсез сүзләрне бутап, күп итеп сөйләнә белсәң, кайчакта бала булып, үрмәләп тә үзеңне балага күрсәтсәң, торып сикергәләп тә алсаң, машина булып гүләсәң, бигрәк тә күгәрчен булып гөрләсәң – шул җитә. Шул очракта бөтен Татарстан синең исемне кабатлар, яратыр, иҗатың белән котлар. Үзеңә, бәлки, нииндигер исем, бүләк кебек нәрсәләр дә бирерләр. Шигъри Сараең түбәсе биек булу синең шәхси тормышыңа, көнкүрешеңә дә уңай йогынты ясамас. Кыскасы, кызганам мин сине, Газинур. Уйлан әле.

– Бары да уйланган, абзый. Син картайгансың, тормыш сине сындырган. Миңа да сыну юлын күрсәтәсең, – дисең, ихтыярың. Үзенчә язып, үзенчә яши бир. Үҗәт кешегә мин һәрвакыт хөрмәт белән карадым. Татар шигъриятенә битараф булмаган һәр милләттәшемә:

– «Түбә» китабын табып укы, уйлан, моңлан! – дип әйтергә әзермен.

Рөстәм МИНГАЛИМ.

1998.

Кол Шәриф мәчете – Казанның һәм Татарстанның үзәк гыйбадәт йорты. Ул 1552 елда Казанны саклаганда илбасарларга каршы батырларча сугышып шәһит киткән сәид Кол Шәриф исемен йөртә. Мөселманнар нәсел җепләре Мөхәммәд пәйгамбәргә тоташкан кешеләрне сәид дип атый. Кол Шәриф тә сәид булган. Ханлыкның өстендә болытлар куерган фаҗигале чоры турында ул «Зафәрнамә-и-вилаяти Казан» әсәрен язып калдырган. Мәшһүр каһарман, шагыйрь, дәүләт эшлеклесе Кол Шәриф хәзрәтләре үз шәкертләре белән бергә Казанның бәйсезлеге өчен соң сулышкача көрәшеп, үз мәчете баскычларында һәлак булган. Мәчете дошман тарафыннан җимерелгән. Кол Шәриф мәчетенең 8 манарасы булганы гына билгеле.

Кол Шәриф мәчете

● Илфар хәзрәт Хәсәнов.

1996 елда әлеге тарихи мәчетне торгызу эшләре башланды. Ул архитекторлар Ш.Латыйпов, М.Сафронов, А.Саттаров, И.Сәйфуллиннар проекты буенча төзелде. Казанның таҗы, милләтнең яңарыш символы булган Кол Шәриф мәчете нигездә халыктан җыелган хәйрия акчасына төзелде. Бинаны торгызу өчен 400 миллион сум акча тотыла. Иман йорты 2005 елның 24 июнендә, Казанның 1000 еллыгына ачылды.

Мәчетнең 8 манарасы бар. Гөмбәзе «Казан бүреге» декоратив элементлары, лалә чәчәкләре белән бизәлгән. Беренче катта ирләр өчен намаз залы, имам бүлмәсе, икенче катта туристлар өчен күзәтү балконнары, хатын-кызлар өчен намаз залы урнашкан. Җир асты катында Ислам музее, чишенү, тәһарәт бүлмәләре бар. Мәчет комплексына шулай ук китапханә һәм нәшрият та керә. Тышкы яктан бина мәрмәр, гранит, оникс белән тышланган. Гөмбәзләре зәңгәр төстә. Манаралары белән бергә мәчетнең биеклеге– 57 метр. Бинага мең ярым кеше сыя, каршындагы мәйданга исә ун мең кеше урнаша ала.

Мәчетнең эчке ягы XVI гасыр технологияләрен кулланып эшләнгән. Анда алебастр, агач һәм таш кулланылган, барлык бизәкләр кулдан ясалган. Алтын йөгертелгән нәкышлар интерьерны баета. Мәчет идәнендәге келәмнәр – Иран хөкүмәте бүләге, ә ике тонналы люстра Чехиядә эшләтеп кайтарылган. Мондагы китапханәдә мәчет төзелешенә өлеш керткән һәр кешенең исеме язылган китап саклана.

ИСЛАМНЫҢ МАТУРЛЫГЫ

Татар телен дә, русчаны да, гарәпчәне дә камил белгән, тирән белемле, шул ук вакытта халык белән эшләргә күңелен биргән хәзрәтләребез, имамнарыбыз бар, шөкер. Имамнар һәрвакыт милләтнең алгы сафында булган, аның аң-белемен, үсешен кайгыртып яшәгән. Бу хәзер дә шулай дәвам итәргә тиеш. Кол Шәриф мәчетенең имам-хатыйбы Илфар хәзрәт Хәсәнов – милләткә хезмәт юлындагы шәхесләребезнең берсе. Ул мөфти хәзрәтнең беренче урынбасары, Республика Иҗтимагый палатасы әгъзасы да.

– Илфар хәзрәт, дин әһеле булырга ничек карар иттегез?

– Мин чыгышым белән Кама Тамагыннан. Ул элек Богородицкое дип атала, анда урыс халкы күп яши иде. Бала чагымда ук күп сынаулар аша үттем, ак канлылык (белокровие) белән авырдым. Әни ягыннан дәү әнием бик дини иде. Ул биш бала белән тол кала, бабай сугыштан кайткач, озак яшәми, тегермәндә эшләгәндә бәхетсезлек килеп чыгып, вафат була. Шул авыр чагында дәү әнием иманга килә. Ул гел намазда. Аның үз комганы, аерым намаз киемнәре, китаплары минем өчен бер серле дөнья кебек. Ул китаплардагы сыргаланып язылган хәрефләр гел кызыктырып тора. Язуын танымасам да, шул хәрефләрне күчереп язам. Дингә килүемә шулай итеп дәү әнием сәбәпче булды. Әти-әнием мин чирләгәч нык борчылды, ә дәү әнием: «Бу Аллаһыдан килгән сынау, Аннан гына ярдәм сора», – дип өйрәтә иде. «Әлхәм»не, «Аятел-көрси»не, «Колһуалла»ны ятларга кирәк, дип, миңа акрын гына сүрәләр өйрәтә башлады. «Барысы да яхшы булыр», – дип мине сөеп юата. Ә чираттагы тапкыр анализлар тапшырырга баргач, диагноз расланмады. Мәктәптә укыганда, үз тормышымда беренче тапкыр ураза тоттым. Мин дингә килгәч, мәктәптә укытучыларның да мөнәсәбәте үзгәрде: юкка-барга бәйләнми башладылар. Валентина Тимофеевна үзе үк миннән кирәксез кичке чараларга килмәвемне сорый, сиңа алай бозылып йөрү килешми, ди.

Аннары Буадан бездә мәчет төзергә килделәр. Дингә тартылган бала барлыгын ишеткәннәр дә мине чакырып алдылар: «Әйдә, без сине Коръән укырга өйрәтәбез» – диләр. Атнага өч мәртәбә кичен мәктәптән соң алар яши торган җиргә барып укый башладым. Кичен үзләре мине өйгә кайтарып куялар. Алар миңа «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә керергә киңәш итте. Тугызынчыны бетергәч, минем мәдрәсәгә җыенганны белеп, кайбер укытучыларым: «Үзең аңлап барасыңмы?» – дип сорау да бирде. Укытучыларым имтиханнарны биргәндә дә ярдәм итте. Татар теленнән имтихан вакытында өч укытучы утыра. Кайсыдыр язучының биографиясен сөйләргә чыктым, болар тыңламыйлар да! Әйдә әле, син мулла буласы кеше бугай, укы әле безгә берәр дога, диләр. Сүрәне шулай дога дип әйтүләре. Мин боларга «Әлхәм»не, «Аятел көрси»не, «Ясин»ның беренче бүлеген укып күрсәттем. Рәисә атлысы әйтә, шуның кадәр матур Коръән укучы бу егетне җәфалап булмас, автомат рәвештә куярга кирәк моңа, ди. Биографияне дә сөйләтеп тормыйча, миңа бишле куеп чыгардылар. Укытучыларыма бик рәхмәтле, хәтта рус милләтеннән булганнары да җомга намазларына каршылык күрсәтмичә җибәрә иде.

– Аннары кайларда дини белем алырга насыйп булды?.

– Тугызынчыны тәмамлап, мин Казанга килдем, ләкин «Мөхәммәдия»гә кермәдем. Ерак туган тиешле Камил хәзрәт Бикчәнтәевкә бардым, Солтан мәчетендә аның мәдрәсәсе бар иде. Анда мин бер ел укыдым да, «Мөхәммәдия»гә кердем. Анда биш ел белем алдым, кичке мәктәпне дә тәмамладым. Бишенче курста укыганда үзем дә беренче курсларга дәрес бирә башладым. Минем чит илгә укырга китәсе килә. Мәдрәсәне тәмамларга өч ай кала Мәккәдән чакыру килде. Ул вакытта мөфти Госман хәзрәт Исхакый иде, ул минем укырга омтылышымны аңлап, Мәккәгә китәргә ярдәм итте. Аллаһы Тәгалә ярдәме белән Мәккәдә имамнар һәм дәгъватчылар әзерли торган институтта укый башладым, 2005 елда аны тәмамладым. Кайтырга исәп юк иде, укуны дәвам итәсе килә. Ләкин Госман хәзрәт кайтырга кирәк, дип чакыртты. Кайттым, йөрәк әрни. Госман хәзрәт: «Җитәрлек укыдың, инде эшләргә вакыт», – дип мине нәсихәтләп кабат укырга җибәрмичә алып калды. Ә минем Мәккәдә университетка кереп булмасмы, дигән ният тә бар иде… Кама Тамагына кайтып китәргә булдым. Ләкин мөфти Казан мөхтәсибе Мансур хәзрәт янына җибәрде. Ул исә көне буе үзенең төзелеш мәйданчыкларында йөртте дә үзенә эшкә чакырды. Шулай итеп, мин сигезенче имам булып, Мәрҗани мәчетенә килдем. 2013 елга кадәр ун ел шунда эшләдем. Мансур хәзрәт миңа тормыш дәресен бирде. Сүз дә юк, авыр булды. Җиңел кешеләрдән түгел

ул. Ләкин Аллаһның рәхмәте яусын, ул миңа вәгазьләр сөйләргә дә, телевидениедән чыгышлар ясарга да каршылык күрсәтмәде, киресенчә, юл ачты, яшәргә өйрәтте.

– Кол Шәриф мәчетенә хезмәт итәргә килгәч, ниләр кичердегез?

– 2013 елның апрелендә мине Кол Шәриф мәчетенә хезмәткә билгеләделәр. Беренче көнемне һаман да истә тотам: килдем, берүзем басып торам, берсен дә белмим. Аппараттан килделәр, тиешле кәгазьләргә кул куйдым. янында транспорт куяр урын да юк хәзер, кешеләр еракта ук машиналарын калдырып, барыбер монда җомгага килә. Һәр җомгада аларга рәхмәтемне әйтәм, дога кылам. Максатыбыз – монда гыйбадәт тә кылынсын, килгән кунакларга исламны дөрес мәгънә ягыннан җиткерү эше дә алып барылсын. Кайчакта зур кунаклар белән делегацияләр килеп төшә, кешеләрнең йөзләрендә ниндидер шөбһә, курку күрәсең. Кайберләренең кыяфәтеннән битарафлык, усаллык бөркелеп тора. Чөнки исламның төп принципларын белә һәм кунакларга шуны матур итеп аңлата. Без моны дәгъват йөзеннән кулланабыз. Бер губернатор абзый безгә алтынчы кат килде. Хатыны татар икән, ислам дине белән бик кызыксына. Үзенең ярдәмчеләрен, министрларын да алып килде. Президентыбызга килгән олы кунаклар да монда кермичә китми. Ачык йөз белән каршы алып, динебез турында аңлатып җибәрәбез, бик канәгать булып, китәләр, ислам турындагы фикерләре дә уңайга үзгәрә.

Казан тажы



Гаҗәеп бер җай-рәхәттер
җиһанда бу Казан шәһәре!
Галәмдә юктыр бу
тикле туганлык
вә иминлек шәһәре.
Казандай төзек шәһри
булмас дөньяда һичвакыт,
Казаннан көч алалардыр
ничаклы бу җиһан шәһәре.
Кол Шәриф.

Зилә ханым Рәхимҗан кызы килеп котлады. Дөресен әйтим, башта монда эшләп китү җиңел булмады. Кол Шәриф мәчете башка мәчетләрдән аерылып тора бит ул. Аның статусы да башка. Бу бит безнең Казанны саклап шәһит киткән бабаларыбыз хөрмәтенә салынган һәйкәл. Монда җитәкчеләр дә бик күп: Диния нәзарәте, Казан Кирмәне, аппарат җитәкчелеге… Туристлар да күп килә, намазга йөрүчеләр дә күп. Һәркайсының үз карашы... Башта монда хәтта мәчет эчендә микрофонга азан әйтергә дә ярамый иде! Кремль биләмәсендә чалма-чапан белән йөрмә, дип әйтүчеләр дә булды. Тора-бара җайланды, Зилә Рәхимҗан кызы белән аралашып, аңлашып эшләдек, аның күп ярдәмен тойдым. Яңгыратып азан әйтә башладык. Тәүлек буена Коръән хәтем кылына башлады.

– Кол Шәриф бүген күбрәк музеймы, әллә мәчетме?

– Кол Шәриф мәчете – ул барыбер дә күбрәк гыйбадәт йорты. Җомга намазларына халык күп йөри. Казан Кирмәне бөтен мәгълүмат чараларында ислам динен экстремизм белән параллель итеп куеп, аны куркыныч итеп күрсәтү бара. Ә без аларны елмаеп, «Әссәламегаләйкүм!» дип каршылыйбыз, көлке сүз дә сөйләшеп алабыз. Гайсә галәйһиссәлам, Мәрьям Ана турында Коръәндә ничә кат язылуы, исемнәре зекер ителүе хакында сөйлибез, ислам диненең төп баганаларын аңлатабыз. Кайберәүләр соңыннан: «Без монда куркып кына кергән идек, мөселманнар безнең өчен ниндидер куркыныч сүз кебек иде, ә хәзер безнең моннан китәсе дә килми», – ди. Шунысы да бар, элек экскурсоводлар башларына нәрсә килә, шуны – булганын да, булмаганын да сөйли иде. Ә хәзер алар акредитация уза. Әгәр дә экскурсовод Кремльдә эшләргә, мәчеткә туристларны алып керергә тели икән, укып, акредитация алырга тиеш. Мин аларга үзем лекция укыйм, ислам дине һәм Кол Шәриф мәчете турында сөйлим. Имтиханны бирә ала икән, рөхсәтле була, юк икән, кабат укыйсың. Хәзер монда эшләүче һәр экскурсовод

– Кайбер мәчетләргә кергәч, дин әһелләренең кырыслыгы белән очрашасың. Ә сездә күңелгә ятышлы халәт…

– Кайбер дин әһелләребезнең кырыслыгы – безнең зур гаебебез. Мәчеткә өч төрле кеше килә: туристлар, намаз укучылар, кайгы-хәсрәткә ирешүчеләр. Кемнеңдер баласы төрмәдә утыра, кемдәдер яман чир тапканнар, кемнеңдер гаиләсендә тынычсызлык… Кайчагында без, имамнар һәм мәчет ишек төбендә дога кылып садака кабул итеп утыручы бабайлар да онытып җибәрәбез: алар бит мулла яки дога кылучы бабай янына килми, алар бит өметләрен Аллаһка баглап килә. Пәйгамбәребез мәчеткә кереп йомышын үтәгән надан бәдәвигә дә, сәрхушкә карата да шәфәгать күрсәткән, аларны сүкмәскә кушкан, ул Аллаһны һәм аның рәсүлен ярата, дигән. Без сабыр булырга, кешене кем булуына карамастан, матур итеп каршы алырга тиешбез. Син аңа «Ник кыска итәк киден, ник намаз укымыйсың?» дип бәйләнәсе урынга, җайлап кына утырт та нәсихәтеңне кыл, аңлат. Икенче вакытта ул синең яныңа үзе белеп тиешенчә киенеп киләчәк. Ә шунда кырыслык, караңгы чырай күрсәтсәң, ул мәчеткә мәңге килмәячәк. Без кешеләргә исламның матурлыгын күрсәтергә тиеш. Мәчеткә килеп тә якты караш күрмичә, күпме кеше диннән чыгып китте? Мәчеттән күңеле китеп, чиркәүгә барып керүчеләр күпме?! Миңа мөфтинең беренче урынбасары булгач, төрле җыелышларда катнашырга туры килә. Христиан диненә чыгып киткән татарларның саны шактый. Бу – безнең эшләп җиткермәвебез, исламның матурлыгын, мәгънәсен кешеләргә җиткерә алмавыбыздан. Күңелеңдә ни булса да, килгән кешегә сиздермә, ачык чырай белән каршы ал, тыңла. Кайберәүләр мәчет Кремльдә булгач, монда һәр көн Президент намазга йөри, дип уйлый. «Син миңа ярдәм итәргә тиешсең шушы хатны президентка җиткерергә, фатир алырга, очраштырырга…» – дип аяк тибеп керүчеләр бар. Ә юк дип җавап бирсәң, синнән дә начар кеше юк… Яхшылап аңлатасың, апа җаным, мин аның янында утырмыйм, аны күргәнем дә юк, минем эш урыным мәчеттә, дисең, ышанмый ул. Төрле очраклар була.

– Остазларыгыз сезне нәрсәгә өйрәтте?

– Остазларыбыз искиткеч хикмәтле кешеләр иде. Багладыштан, Сүриядән искиткеч галимнәр бар иде. Казаннан Мәккәгә укырга килдек, һаваланып йөрибез инде. Остазыма сорау бирәм: бездә тәравих намазын 20 рәкәгать укыйлар, һәр дүрт рәкәгать саен зекер әйтеп җырлап утыралар, дим. «Нинди зекер ул?» – ди остазым. Әби-бабаларыбыз белеп җиткермәгәндер инде, дигәнрәк төстә шул зекерне җырлап та бирдем. Шунда остазым бу зекердән соң елап җибәрде. «Онытылган сөннәтне үтисез икән бит сез» – диде ул. Мин шып булдым. Безнең әби-бабаларыбыз хәдис белән дәлил китерә белмәсә дә, алар сөннәтне үтиләр икән бит. Әйтик, бездә ашау алдыннан Коръән мәҗлесләрендә тоз куялар. Әйе, без «Мөхәммәдия»дә укыганда бидгать бу, дип әтәчләнә идек. Ә пәйгамбәребезнең сөннәте буенча ашау алдыннан бисмилләһ әйтеп тоз капканнар икән. Шул хәдисләрне өйрәнгәч, бик күп нәрсәне аңладым. Әби-бабаларыбызның гамәлләреннән бидгать эзләргә кирәкми икән. Ә ни өчен шулай эшлиләр, дип төбенә төшәргә, гыйлем алырга кирәк. Кешенең соравына китаптан карап кырт кисеп җавап бирүгә бик җиңел, ләкин син башта кешегә, аның тормышына, гамәленә, кыяфәтенә-рәвешенә кара. Шуннан соң гына без Аллаһының канунына, пәйгамбәребезнең сөннәтенә туры килгән җавапны кайтарырга тиеш. Бу мәсьәләдә Габделхак хәзрәт Саматтан бик күп үрнәк алдым. Бик хикмәт иясе иде, урыны җәннәттә булсын. Мансур хәзрәттән күп тормыш гыйлеме алдым. Остазларым өчен Аллаһыма бик рәхмәтлемен.

– Хәзрәт, Сез социаль челтәрләрдә күренмисез. Ул өлкәдә дәгъват эшчәнлеген киңәйтергә уйламыйсызмы?

– Тормыш ул шулкадәр кадерле, вакыт шулкадәр тиз уза, мин вакытымны социаль челтәрләргә исраф итәргә теләмим. Миңа караганда да зуррак галимнәр бар, матур телле имамнарыбыз бар, эшли ала икән, эшләсен. Инстаграм сәхифәсен дә мөфти кушканга гына ясап куйдым. Булган очрашуларның фотоларын гына куеп барам. Мин анда кереп батудан куркам. Аның өчен вакытым да юк.

– Гаиләгез белән дә танышасы килә.

– Әнием мәрхүмә инде, дүртенче ел. Бик көчле кеше иде. Әтием белән икесе җигелеп тормышны алып барды. Әтием гади шофер булып эшләде, әнием идән юды, икесе дә гади хезмәт кешеләре иде. Без гаиләдә дүрт бала. Төпчек энекәшебез авыру булды, шушы баланы әти-әнием безнең дә ярдәм белән кадерләп тәрбияләде. Әниебез киткәч тә, ул әтигә яшәр өчен көч биреп тора. Үзем өйләнгән, хатыным Эльмира исемле, башлангыч сыйныфларда укытучы булып эшли. Ислам университетын да тәмамлады. Мине бик хөрмәтләп, кадерләп тора, мин аңа бик рәхмәтле. Бик сабыр. Аллаһы Тәгалә сынауларны да биреп тора, ләкин сабыр итәбез. Тормыш – үзе сынау. Беркемнең дә капчыгы буш түгел.

– Сезнең янга кешеләр киңәшкә еш киләме?

– Күп. Хәзер соңгы арадагы чирләр, сәяси вакыйгалар аркасында кешеләр каушап, кемгә карарга, ничек яшәргә дип аптырап калдылар. Мәчеткә ярдәм сорап киләләр. Аларга рухи ярдәм, җылы сүз, нәсихәт кирәк. Килергә теләүчеләрне Диния нәзарәтендә язып куялар да, һәр сишәмбе көнне тугыздан уникегә кадәр шушында мөфти хәзрәт белән берлектә мәчетебездә кабул итәбез. Рамазан аенда елдагыча тәравих намазлары үткәрәбез.

Сәхифәне
Эльмира СИРАҖИ
әзерләде.

ТИТАН

«Бәхетсез ил син, Россия! Синең Бөек Пётрдан башка бер генә акыллы патшаң да булмады! Бер генә дә! Шулкадәр зур халык булып, син бер генә юньле патша да бирә алмадың! Кайсы ахмак булды, кайсы дивана (Николай II шикелле)»

Гомәр Бәширов



Мин татар матбугатын даими күзәтеп, укып барырга тырышам. Татар әдәбияты тарихында якты эз калдырган мәшһүр, титаник шәхес, Сталин һәм Тукай премияләре лауреаты, Татарстанның халык язучысы, Казан шәһәренең мактаулы гражданы Гомәр Бәшировны (1901-1999), туууына 120 ел тулу уңаеннан, искә алып, былтыр «Мәдәни җомга» газетасында әдипнең якташы, күренекле журналист Әгъзам Фәйзрахманов мәкаләсе генә басылды.

Узган елларга күз салсак та, чыккан язмалар ике-өч кенә: 2020 елда язучының районашы Шәфигулла Гарипов «Казан арты» музее сайтына «Яңа салада Гомәр Бәширов паркы ачылды» дигән материал элде, ә 2019 елда шул ук авторның «Безнең мирас» журналында «Арчалар Гомәр Бәширов мирасын барлый (фотолар)» язмасы дөнья күргән иде. Шагыйрь Ләбиб Леронның 2020 елда «Идел» журналы битләрендә басылган «Гомерле Гомәр Бәширов» мәкаләсен дә телгә алырга кирәк.

Моннан 22 ел элек 99 яшендә вафат булган Г.Бәширов кебек титаныбызны онытырга хакыбыз юк. Нигә алай соң? Чөнки бүген халык капитализм шартларында акчага табынып яши. Супер-, гипер-, мегамаркетлардан өстеөстенә әйбер җыялар, байлык туплыйлар. Дөнья кендеген үз кулларында нык тотучы эшкуар миллиардерлар мөселманнарның дини хисләрен мыскыл итеп, үзләреннән рөхсәт тә сорап тормыйча, аларның ял көне исеме белән атап, «чёрная пятница» («кара җомга») дип, телевизор экраныннан көне-төне лаф оралар. Инде күптән капитал колларына әйләнеп беттек бит без. Шуңа күрә хәзерге заманда бөек әдипләрнең юбилейлары турында уйларга да, язарга һәм сөйләргә дә, матур әдәбият укырга да вакытыбыз юк диярлек. Кешеләрне битарафлык, тар күңеллелек, комсызлык, әрсезлек шикелле ямьсез сыйфатлар сырып алды.

Ә социализм шартларында, ягъни социаль гаделлек җәмгыятендә тәрбияләнеп үскән, Совет илендә эшләгән һәм яшәгән Г.Бәширов бик тыйнак кеше иде. «Гомерем буена берәүдән дә көнләшмәдем, шуңа озак яшәдем», – дип, бик тә дөрес әйткән язучы.

Гомумән, Бәшировлар буыны булганга шөкер итеп, азга канәгать булып гомер кичерде. Йөз миллионлаган совет кешеләре күк, Г.Бәширов та башта «иптәш» Сталинга, аннары «даһи» Ленинга ихластан ышанды, КПССка рәхмәт һәм мәдхия укыды. Әмма бүген бу җөмләләр сәер яңгырый лабаса: «Бөек Ленин! Менә Россиянең иң акыллы, иң даһи җитәкчесе. Әгәр Ленин тагын бер ун гына ел яшәгән булса да, коммунизмның дөрес юлына баскан булыр идек. Ләкин аһ! Андый бәхеткә ирешә алмадык! (1964, 12 апрель)» (184 б.).

Г.Бәширов – Ленин һәм Сталинга, аннары партиягә инанган чын коммунист иде. Ләкин туксанынчы еллар башында дөньяның асты өскә килгәч, совет чорыннан ерагаю, совет мирасына тәнкыйди күзлектән карап бәяләү өстенлек алды.

Бәшировка Казанда һәйкәл кирәк

Казанның Башкарма комитеты карары нигезендә, шәһәрнең Киров районындагы «Волжская гавань» торак комплексында 2015 елда гына Г.Бәширов исемендәге урам барлыкка килде, ләкин башкалабызда бүгенгә кадәр аңа һәйкәл юк. Кирәкме язучыбызга һәйкәл? Иң элек әлеге мәсьәләне киң җәмәгатьчелек, Татарстан Язучылар берлеге h.б. иҗтимагый оешмалар көн тәртибенә куярга тиеш. Ахыр чиктә, бу хакта ТР Мәдәният министрлыгы үз фикерен белдерсә, министр Ирада Әюпова үз сүзен әйтсә, яхшы булыр иде. Әлегә бары тик Арча шәһәрендә Г.Бәшировка бюст куелган килеш.

«Күңел дәфтәре»ндә ниләр бар?

Кулымда Г.Бәшировның «Күңел дәфтәре» исемле матур тышлы китабы (К.: ТКН, 2011, 464 б.). Куе яшел төстәге тышлыкка Гомәр аганың Әхмәт Катаев ясаган портреты куелган. Китапны әдипнең улы Зөфәр Бәширов төзегән, кульязма һәм искәрмәләрне дә ул әзерләгән. «Үз заманының каһарманы» исеме астында басмага кереш сүзне Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин язган.

«Күңел дәфтәре»н уйланып, анализлап укыдым. Көндәлекләрен автор 1937 елда ук яза башлаган икән. Шомлы ел саналса да, көндәлек алып барырга курыкмаган. Китапка биш көндәлек дәфтәр кергән: беренче дәфтәр (1937–1956); икенче дәфтәр (1956–1966); өченче дәфтәр (1966–1980); дүртенче дәфтәр (1982–1991); бишенче дәфтәр (1992–1999).

Г.Бәширов илебездә, Мәскәү белән Казан әдәби тормышында булган мөһим вакыйгаларны теркәп барган, аерым алганда, СССР, РСФСР, ТАССР язучыларының корылтайларында һәм партиянең өлкә комитеты утырышларында, комсомол конференцияләрендә, КПСС съездларында, СССР Югары Советы сессияләрендә катнашып, шулар хакында фикер-мөнәсәбәтен белдергән. Әдип Казан дәүләт университетының актлар залында оештырылган тантаналарга еш чакырылган һәм техникум-училищеларда укучы яшьләр белән даими очрашып торган. «Техническое училищеда очрашуда булдым. Дүрт яшь кеше минем әсәр («Намус» романы) турында чыгып сөйләде. Һәммәсе дә татар, әмма һәммәсе дә русча сөйләде. Бер генә рус та сөйләмәде. Китапны яратмаудан түгел. Соңыннан аңлаттылар. Руслар романдагы исемнәрне дөрес әйтә алмый икән, шунлыктан һәммәсен дә татарларга биргәннәр... Әйе... Ярый, монысына ышандык ди инде. 1958, 31 май» (158-159 б.).

Г.Бәширов көндәлекләрен татар әдипләре, журналистлары, җырчыларының ничәсе укып чыкты икән? Минемчә, аның «Күңел дәфтәре» язучыларның өстәл китабы булырга тиеш.

Руслашуның башы

Г.Бәшировның 1938 елгы язмаларын укып карагач, рус сүзләре татар язма телендә ничек күп кулланылганга тап булдым, моны язучы Бөек Ватан сугышына кадәр үк татарларның урыслаша башлавына ишарә ясый дип аңларга кирәк. Мәсәлән, «Шәмсекамәр» пьесасының авторы М.Әблиев сөйләгәннең яртысы диярлек русчадан тора, утыз сигезенче елларда татар теленә рус сүзләре шулкадәр күп кергән. Менә бер өзек: «Ул: «Как же, ведь монда әйтелгән, ачык әйтелгән, хәтта чоры түгел, елы да бар», – дип, китаптан кайсы ел икән урынны эзли башлады. Мин аңа: «Хикмәт елын язып куюда түгел, ә шул чорны тамашачыга дөрес күрсәтмәүдә...» – дип әйткәч, ул гаҗәп кеше искиткеч тизлек белән: «Соң мин дә шуны әйтәм бит, экономически ситуациядә шулай бирелә, бытовой мәсьәлә татар совет матбугатында «Тукай халык шагыйреме?» дигән сорау тирәсендә зур бәхәс куба. Тәнкыйтьчеләр кызып-кызып бәхәсләшкән.«Бу арада шуның белән баш ваттылар инде. Гаҗәп кызык халык, ә!

– Ай-һай, ялгыш булмагае... а вдруг берәрсе аны халык шагыйре түгеллеген докажет? А есть у него что-нибудь такое, ну вроде...

– Ну ведь народ-то давно уже признал его своим!

– Халык шулаен шулай, ә менә аның әле ышанып бетәсе килми.

● **Гомәр ага хатыны Кәримә апа белән.**

шундагы разрезда күрсәтелә инде, но төп мәсьәлә фәлән бит, шулай да кайбер урыннары зрительгә не доходит, ә ул хәзер, мин күрсәткәнчә, доходить итәргә тиеш», – дип, әллә нәрсәләр сөйли башлады» (16 б.).

Димәк, сугыш алдыннан да рус теленең туган телебезгә йогынтысы бик зур була, Г.Бәширов үзе дә көндәлек дәфтәренең күп кенә битләрендә русча сүзләр кыстырып язган: «Газеталарда көзге чәчүне «ужым чәчү» дип яза башладылар. Кайсы ахмагы уйлап тапты икән аны? Аны, бәлки, берәрсе научно доказать иткәндер әле!» (15 б.)

Көндәлек язмаларның кайберләре безнең чорыбызга да туры килә кебек, гыйбрәт алырлык урыннары бар. Гомумән алганда, көндәлек – ихластан язылган әйбер. Мисал өчен, кешеләр, шул исәптән язучылар арасындагы мөнәсәбәтләр ул заманда ук катлаулы булган, бүген дә четерекле кала бирә. 1938 елның язында

– Ышанмаса, үзе укып карасын инде.

– Хикмәт тә шунда шул менә, укый белү җитенкерәми...

Әй Тукай, Тукай...» (8 б.).

Шул куркыныч елларның караңгы мохите гаять ачык чагыла язучы көндәлегендә. Адәм балалары бер-берсеннән кара еланнан курыккан кебек курыккан, корткыч, контр дип шикләнгән, НКВДның җирле органнарына ялган шикаятьләр язып, гаепсез кешеләр белән совет төрмә-лагерьларын тутырырга ярдәм иткән, «халык дошманнары»ның башларына җиткән. Утыз җиденче елның июнендә Бәширов болай язып куйган: «Мин бервакыт аңа, ИМЛда (Марксизм-ленинизм институтын 1934 елда тәмамлый. – **И.Ф.**) укыганда: «Безгә язучы, шагыйрь дип мактанырга иртәрәк әле», – дигәч, ул миңа: «Сиңа, конечно, шулай, синең бернием дә юк, ә минем инде тугыз китабым бар», – диде. Мин аңа: «Тугыз

ГОМӘР АГАБЫЗ

Милләтнең каймагы

«Инде, ниһаять, синең тәхетенә, рустан кеше булмагач, гөрҗи (грузин) килеп утырды. Ул күп «яхшылыклар» эшләде. Уңнарның кирәген бирде. Сулларны, уңнарны да – берсен дә калдырмыйча төрмәгә утыртты. Бик күбесен асып-кисеп бетерде. Ул бик мәгърур кеше, дөньяда мин генә даһи кеше дип уйлаучы иде. Һәм менә нәтиҗә: миллионнарча кешеләр йә төрмәдә, йә эшафотта үлде. Йә азаплап үтерделәр. Иң аянычы шунда: Сталинның чәһриярлары һәр милләтнең иң актив көчләрен, ягъни революцияне үз кулы белән, үз каны белән ясаган, аны үз кулы белән аякка бастырган иң акыллы, иң булдыклы кешеләрен асып-кисеп бетерде. Татарның иң зур галиме, иң талантлы әдибе Галимҗан Ибраһимов иде. Аның авыру икәнен белә торып, монда кайткач үләсен белә торып (чөнки бер генә үпкә белән сулый һәм Ялтада гына яши ала иде!), аны кулга алдылар һәм монда кайткач ул берничә айдан ук үлде. Коточкыч хәл! Аны кайдадыр үләксәләр зиратына илтеп ташлаганнар. Без аның кабере кайда икәнен дә белмибез.

Ул акланганнан соң, мин әлеге оешмага бардым. Миңа бер папка күрсәттеләр.Ул папкада аның паспорты һәм кайбер кәгазьләреннән башка берни дә юк иде. Ягъни аны гаепләргә бер генә кәгазь дә булмаган. Кайсы илдә, кайчан шундый хәл булганы бар?» (183-184 б.).

Атаклы язучы-чордашлары Галимҗан Ибраһимов, Шамил Госманов, Ләбиб Гыйльми, Кави Нәҗми, Гадел Кутуй, Мирсәй Әмир, Фатих Сәйфи-Казанлы, Ибраһим Сәлахов, Сөббух Рафыйков, шагыйрьләр Миргазиз Укмасый, Хәсән Туфан, Фатих Кәрим, драматурглар Кәрим Тинчурин, Фәтхи Борнаш, Нәкый Исәнбәт, әдәбият галимнәре Галимҗан Нигъмәти, Нигъмәт Хәким, Гали Рәхим, күренекле тарихчылар Газиз Гобәйдуллин, Һади Атласи, Михаил Худяков һ.б.лар НКВД кармагына капканда, күпләрдә Гомәр Бәширов китабында, һич булмаса, берәр генә образың бармы соң синең?» – дигән идем дә, ул аны аңламады. Чудакмы, дуракмы шунда – аңламассың. Аздырганнар ул мескенне. Ул шуның аркасында үзенә үзе ышана башлаган. Хәзер инде аңа: «Синең талантың юк, кәгазь әрәм итмә», – дип беркем дә әйтми, берсенең дә начар буласы килми. Ә ул яза, пычрата. ... Иң начары – аның үзен-үзе талант иясе дип йөрүе. Әгәр ул минем болай язганымны белсә, «Аһа, контр икән ул!» – дип тегендә ябарга кушар иде» (6 б.).

ничек эләкмәдә икән дигән сорау туадыр. 1901 елда дөньяга аваз салган Г.Бәширов Октябрь революциясеннән соң, 1920 елны Эшче-крестьян Кызыл Армиясенә алына, ә 1924 елда демобилизацияләнә. Ул гади солдат буларак, Гражданнар сугышында Михаил Фрунзе җитәкләгән Көньяк фронтта Перекоп-Сиваш операциясендә катнашып, Кырымны интервентлардан азат итү өчен Пётр Врангель һәм Нестор Махно гаскәрләренә каршы сугышкан. 1924 елда Эчке эшләр халык комиссариатының Казандагы берьеллык махсус мәктәбен тәмамлагач, 1925-1929 елларда Арча кантонында эшче-крестьян милициясе органнарында хезмәт иткән. 1929-1932 елларда Балтач, Дөбьяз районнарының юстиция органнарында халык судьясы булган. 1932-1936 елларда «Кызыл Татарстан» өлкә газетасының әдәби хезмәткәре һәм бүлек мөдире булып эшләгән. 1936-1938 һәм 1941-1942 елларда Г.Бәширов – «Совет әдәбияты» журналының җаваплы секретаре. 1938-1941 елларда Татар дәүләт нәшриятының матур әдәбият бүлеге редакторы, ә 1942-1944 елларда Татарстан АССР дәүләт радиокомитетында баш редактор.



Нәтиҗәдә, шактый еллар узгач кына, Г.Бәширов Гражданнар сугышы вакыйгалары хакында «Сиваш» повестен язып, 1937 елда бастыра һәм әдип булып таныла. Бу әсәр тиз арада русчага да тәрҗемә ителеп, бөтен Советлар Союзына тарала. Авторга повестьны укучылардан бик күп хатлар килә. Минемчә, шушы популяр повесте Г.Бәшировның гомерен саклап калган да. Ә бит репрессиягә эләкмәүче татар язучылары чынлыкта бармак белән санарлык кала: Шәриф Камал, Таҗи Гыйззәт, Муса Җәлил, Сибгат Хәким, Әхмәт Ерикәй, Әхмәт Фәйзи, Нур Баян, Абдулла Алиш, Гариф Гобәй, Газиз Иделле, Гамир Насрый.

Г.Бәширов 1938 елның җәендә үлгән артист Ситдыйк Айдарны күмгәннәрен кыскача тасвирлап уза: «Бу артистны чын күңелдән ярата идем һәм якын күрә идем. Ничектер ул башкалардан ачыграк күңелдә сеңеп калган. Аның җыры яхшы, моңлы: ул халык моңын бирә ала иде. ... Бик иртә үлде, мескен. Күмәргә бардык. Яхшы оештырмаганнар иде. Кеше үлгәч, ул зур хезмәт күрсәткән кеше дә булса, аның хезмәте турында бик нык ишетәсе килә».

Сталин премиясе лауреаты

Г.Бәширов «Намус», К.Нәҗми «Язгы җилләр» романнары өчен матур әдәбият өлкәсендә СССРның иң мәртәбәле бүләгенә – Сталин исемендәге премиягә лаек булган. «Халыклар атасы» үзе укыган бу әсәрләрне, премия бирергә дә кушкан. Гомәр ага «Көзге ачы җилләрдә» повесть-истәлегендә (1984) шул хакта яза. Шулай ук халык шагыйре Роберт Миңнуллин да документаль телефильмда аксакал язучыдан әлеге хатирәне сөйләттерә. 1951 елда Иосиф Виссарионович төнге икедә ВКП(б)ның Татар өлкә комитетына шылтыратып, икенче секретарь белән элемтәгә кергән һәм сорауны кабыргасы белән куйган:

«– Иптәш ..., Сез татар язучылары Гомәр Бәшировның «Намус», Кави Нәҗминең «Язгы җилләр» романнарын укыдыгызмы?

Телефон трубкасының теге башыннан:

– Юк, иптәш Сталин, – дигән гаепле сыман тавыш ишетелгән.

– Алайса, укыгыз. Аннары фикерегезне әйтерсез: премиягә лаекмы, юкмы? – дигән генералиссимус.

– Яхшы, иптәш Сталин, – дип җавап биргән икенче секретарь».

Ә көндәлегенә Г.Бәширов 1951 елның 4 июлендә болай язып куйган, биредә Сталинның шалтыратуында сәгать аермасы бар: «Бервакыт, Сталин премиясе комитетының утырышлары үтеп беткәннән соң, безнең өлкә эшчеләреннән берсенең төнлә белән сәгать 12 ләрдә телефоны шалтырый. Москва икән. Бу иптәш җавап бирә. Москва әйтә:

– Бу – Москва. Сезнең белән Иосиф Виссарионович Сталин сөйләшергә тели, – ди.

Бу иптәш, билгеле, каушап кала. Сталин үзе бит!

Шуннан соң сөйләшү башлана. Москвадан Иосиф Виссарионович сорый:

– Сездә матур әдәбияттан нинди яхшы әсәрләр бар?

Бу иптәш әйтә инде:

– Ярыйсы гына әйберләр бар, менә газеталарда ярыйсы гына бәя бирәләр, ди.

– Ә сез үзегез нинди фикердә?

– Минемчә, фәлән әйберләр ничего гына, халык яратып укый.

– Минемчә дә, ничего. Ләкин, шулай булгач, нигә соң сез аларны премиягә тәкъдим итмәдегез?

– Союз тәкъдим иткән иде аларны, Иосиф Виссарионович.

– Союз – үзенә, ә Сез? Нигә Сез үзегез тәкъдим итмисез?

– Без иртәгә үк бөтенесен оформить итәрбез, Иосиф Виссарионович, иртәгә үк!

– Уйлашыгыз!..

Әлеге иптәш тәмам янып-пешеп чыга, маңгаеннан шыбырдап тирләр ага. Сөйләшеп бетергәннән соң торып китә дә кабинет буйлап маңгаен сөртә-сөртә маршировать итә башлый. Анда кемнәрдер бар икән, әйтә:

– Менә, әгәр мин монда эшләмәсәм, Иосиф Виссарионович белән сөйләшмәгән булыр идем. Менә бәхет! Мин Иосиф Виссарионович белән, аның үзе белән сөйләштем. Кем ирешкән бу бәхеткә? Шунда утыручыларга күз сала да сорый:

– Син «Н»ны укыдыңмы? «Язгы җилләр»не укыдыңмы? Ә? Укымадыңмы? Укы! Бүген үк укы!» (108-109 б.).

Моңа охшаш легендалар тагын бар, дигән язучы...

Сталин премиясен алгач, Бәшировтан көнләшүчеләр дә булган. «Премия алуга бәйләнешле тагын бер нәрсә истә калган. Бер кичне, сәгать 11 ләр тирәсендә мине телефонга дәшеп алҗыттылар. Барып трубканы алуга, икенче башта трубканы куялар. Мин, районнан чылтыраталар дип, зур түземлек белән телефон чылтыраган саен барам. Шулай ике арада йөри торгач, бер тупас тавышлы кеше сүгеп ташлады. «Син премия алдым дип масаеп йөрмә, сиңа әллә кайчан бабаңнар янына китәргә вакыт инде, фәлән дә фәсмәтән...», – дип сүгенде дә шалт итеп телефонны куйды» (339 б.).

(Дәвамы киләсе санда).

Илһам ФӘТТАХОВ,
филология фәннәре кандидаты.

Атнаның сәяси мизгелләре

ХӘТӘР МИЗГЕЛЛӘР

Рәсми хәбәрләрне санавыбызны дәвам итик. Әлбәттә, алар күбрәк Украинадагы хәлләргә бәйле. Арада иң фаҗигалесе – 14 мартта Донецк үзәгендә тактик максатлы «Точка-У» ракетасы кулланылуы. Ракета һөҗүме нәтиҗәсендә тыныч халыктан 23 кеше һәлак булган, 18е тән җәрәхәтләре алган. Соңгылары арасында балалар булуы турында да әйтелә. Россия тикшерү комитеты бу факт буенча җинаять эше кузгаткан. Киев әлеге һөҗүмгә үзенең катнашы булмавы турында белдергән. Элегрәк (1 мартта) «Украинага хәрби һөҗүм» факты буенча җинаять эше кузгатуы турында Польша Генераль прокуратурасы да белдергән иде. Анда хәрби һөҗүм корбаннары дип Украина дәүләте һәм Украина халкы игълан ителде.

Ә 13 мартта Россия кораллы көчләре, югары төгәллек коралы кулланып, Украина хәрби өйрәнү үзәкләрендә чит илләрдән килгән 180 «наемник»ны юк иткән иде. Хәрби операция чорында Украина хәрби инфраструктурасының 4 меңгә якын объекты юк ителгән. АКШ Россия чикләренә 12 мең сугышчысын күчереп урнаштырган. Байден НАТО һәм Россия арасында ачык конфликт өченче бөтендөнья сугышына китерәчәге турында искәрткән. АКШ Украинага сугыш кораллары белән алга таба да ярдәм итәчәк. Кытай исә Россия-Украина мөнәсәбәтләрен тыныч юл белән чишү яклы. Ул да Украинага гуманитар ярдәмнең беренче партиясен тапшырган.

АКШ бу атнада Россиягә каршы санкцияләрнең яңа пакетын кертте һәм аның белән сәүдәне бөтенләй дә туктатырга җыена. Кремль АКШ гамәлләрен Россиягә каршы «икътисад сугышы» дип атады. Санкцияләрнең дүртенче пакетын ЕС та кертте. Бу чикләүләр нәтиҗәсендә, бүген Россия үзенең 300 миллиард долларлык алтын-валюта резервына керә алмый. «Мәскәү биржасы»нда кыйммәтле кәгазьләр сәүдәсе 18 мартка кадәр туктатылган. Аналитиклар инфляция дәрәҗәсе дә ел ахырына анда 20 процентка җитәчәк, дип фаразлый. Хәлбуки, Мәскәү үзе дә Көнбатышка каршы җавап санкцияләре әзерләгән. Россия һәм Украина тышкы эшләр министрлары арасында Төркиядә үткән сөйләшүләр уңышсыз тәгәлләнгән. А ПАСЕ 15 март көнне Россияне Европа Шурасыннан чыгару турында карар кабул итте.

Фоат УРАЗАЙ.

Мәдәни җомга
18 март
№10, 2022

Остаз-галим

Бу көннәрдә педагогика фәннәре докторы, академик, атказанган фән эшлеклесе Васил Габдулла улы Гайфуллин 85 яшьлеген бәйрәм итә.

Ул Мөслим районының Югары Табын авылында туа. Авылында – башлангыч, Түбән Табында җидееллык мәктәпне, аннары Минзәлә педагогика училищесын тәмамлый.

Аннары Казан педагогика институтының физика-математика факультетында студент еллары. Бик яхшы укыганга күрә аны институтта калдырырга тырышсалар да, ул үз районына эшкә кайта. Хезмәтен Мөслим мәктәбендә башлый, балаларга физика, математика фәннәре укыта. Бераздан аны уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары итеп билгеләр. Бу эштә дә озак эшләргә туры килми. Район хуҗалары аңа район мәгариф бүлеге мөдире вазифаларын йөкли. 27 яшьлек егет район укытучыларының башлыгы булып китә. Җитмештән артык мәктәпнең эшенә контроль булдыру, инспекторлык тикшерүләре уздыру, алдынгы тәҗрибәләрне өйрәнү, семинарлар уздыру, мәктәпләрне, балалар бакчаларын мөгаллим һәм тәрбиячеләр белән тәэмин итү һ.б. – эш буа буарлык. Күп мәктәпләр җимерелү алдында. Алда яңа биналар төзү проблемасы тора. Район мәгариф бүлеге мөдире җиң сызганып эшкә керешә. Гаять күп төзелеш эшләре башкарыла: Мөслим урта мәктәбендә мастерской, 540 урынлык янкорма, Баек, Октябрь, Әмәкәй, Туйгилде, Мухан, Шуран, Симәк, Баланлы, Чакмак, Түбән Табын, Михайловка, Күбәк, Бәкәбез мәктәпләре төзелә; Ташлыяр, Вәрәтбаш, Шуран, Олы Чакмак, Югары Табын, Үрәзмәт, Тат. Бүләр авылларында балалар бакчалары, укытучылар өчен фатирлар салына. Төзелеш эшләре буенча Мөслим районына Россия Федерациясе буенча 1 нче урын бирелә.

Укыту-остазлык хәрәкәте дә читтә калмый. Укытучыларның читтән торып укуына ярдәм итү өчен районда Казан педагогика институтының консультпункты булдырыла. Мәктәпләрнең тәҗрибә участокларында тәҗрибә эшләре фәнни нигезгә корыла. Мәктәпләрнең производство бригадалары республикада алдынгы урыннарны яулый башлый.

Бу юнәлешләр һәм мәгариф учреждениеләрен яңа уку елына хәзерләү буенча район беренче мәртәбә республика буенча җиңүче була.

Чын җитәкче булып әзерләнеп беткәч кенә В.Гайфуллин хезмәт юлында текә борылыш ясый. Ул А.Герцен исемендәге Ленинград педагогика институтына аспирантурага керә. Фәнни эш өчен ул күптән әзер: пединститутта укыганда фәнни түгәрәкләргә йөри, кызыклы чыгышлар ясый. Мөслим мәктәбендә эшләгәндә ул үзенең методик алымнары турында республика журналларына мәкаләләр җибәрә. Өч ел бирелгән аспирант гомерен ул уңышлы файдалана, срогыннан алда диссертацияне язып, Казан педагогика институтына эшкә кайта.

Күтәп торганнар диярсең, аны кайткан елны ук физика-математика факультетына декан урынбасары итеп куялар. Ул студентлар белән семинарлар, практик занятиеләр уздыра, лекцияләр укый. Монда да ул студентларның, хезмәттәшләренең хөрмәтен казана.

Бераздан аны институт ректоры профессор М.Зәкиев чакырта: "Бездә яңа факультет булачак – мәктәп директорларының белемен күтәрү факультеты. Синнән дә уңышлырак кандидат юк, роно мөдире булып эшләгәнсең, мәктәп директорларының эшен беләсең. Алын син бу эшкә". 100 тыңлаучыга исәпләнгән факультет ел саен 4 агым укытып чыгара. Факультет институтта гына түгел, Союз күләмендә дә күренеклегә әйләнә. Әмма В.Гайфуллинны янә ректор М.Зәкиев чакырта.

– Бу факультетны хәзер башка кеше дә алып бара ала, сине физматка кайтарабыз. Бу зур факультетның (1500 студент, 80нән артык укытучы) хәле катлауланды, анда син кирәк...

В.Гайфуллин физмат факультеты эшенә яңалык кертә: математикадан 2 группа, физикадан 1 группа студентларны татар мәктәпләре өчен махсус әзерли башлыйлар. Башка факультетлар да һәм Төзелеш институты, һәм Авыл хуҗалыгы институты да бу тәҗрибәне күтәреп ала.

В.Гайфуллинга тагын бер тәкъдим ясала. Докторлык диссертациясен яклап, алга таба администраторлык эшләреннән арынып, фән белән ныклап шөгыльләнермен дип торганда, аны мәгариф министры вазифасына кыстый башлыйлар. Ниһаять, ул ризалыгын бирә.

Мәгариф системасы гадәттән тыш катлаулы. Беренче чиратта, Татарстан мәгарифендәге юнәлешләрне билгеләргә кирәк. Демократия башланган заман, татар халкының үз аңы уяна башлаган 90 нчы еллар. Милли мәктәпләр юкка чыккан диярлек. Лениногорск, Бөгелмә, Нурлат, Чистай, Түбән Кама, Яшел Үзән, Буа, Минзәлә шәһәрләрендә бер генә татар мәктәбе дә юк. Чаллыда бер, Казанда ике татар мәктәбе калган, аларында да укулар рус телендә алып барыла.

Министр милли мәгарифкә кагылышлы хөкүмәт карарларын, норматив документларны өйрәнә: татар халкы гомер-гомергә үзенең балаларына аң-белем бирергә тырышкан, хәлләрәк кешеләр исәбенә мәктәп, гимназия, мәдрәсәләр ачкан. Совет властенең беренче елларында милли мәгарифне үстерергә омтылыш зур булган. Язма теле дә булмаган күп кенә халыкларда алфавит булдырылган, милли мәктәпләр ачылган. 1930 елда Россия Федерациясендә 48 төбәктә милли мәктәпләр эшләгән, 80 нән артык педагогика училищесында, 20 дән артык педагогика институтында милли мәктәпләр өчен укытучылар, тәрбиячеләр хәзерләнгән. Ул елларда милли мәктәпләр шактый үсеш алган, Казанда гына да өч дистәдән артык татар мәктәбе эшләгән.

Республика мәгарифендә яңа чор һәм үзгәрешләр башланырга тиеш, дигән нәтиҗәгә килә министр. Беренче эш итеп, иҗади төркем төзелә. Милли мәгариф концепциясе барлыкка килә. Бурычны үтәү өчен һәр район һәм шәһәр буенча милли мәгарифне торгызу программасы, һәр ел өчен конкрет план эшләнә.

Бу чорда Мәгариф министрлыгы революциядән соңгы еллардагы Смольныйны хәтерләтә иде. Министрлыкта милли мәктәпләр эшенә җавап бирүче министр урынбасары штаты булдырыла. Бу урынга мәктәп директоры Г.Садриев тәкъдим ителде. Министрлыкта милли мәктәпләр бүлеге эшли башлады. Аның мөдире итеп мәгариф системасының барлык буыннарында тәҗрибә туплаган Ә. Хуҗиәхмәтов билгеләнә; район һәм шәһәр мәгариф идарәләрендә идарә мөдиренең милли мәгарифне үстерү буенча урынбасар штаты булдырыла. Шәһәр мәктәпләрендә милли мәгариф белән шөгыльләнүче директор ярдәмчесе штаты кертелә. Мәгариф министрлыгы тәкъдиме белән милли мәгарифнең үсеше мәсьәләләрен ел саен бер мәртәбә район һәм шәһәр халык депутатлары сессиясендә тикшерү практикасы булдырыла.

Республикада милли мәгарифкә багышланган берничә конференция уздырыла. 1996 елның март аенда ЮНЕСКО инициативасы белән уздырылган конференциядә Татарстанда милли мәгарифнең үсешенә югары бәя бирелә.

1990-1997 елларда Татарстан мәгариф министры булып В.Гайфуллин эшләгәндә, республика мәгарифе Россия Федерациясендә алдынгылардан санала. Ел саен 70-80 мәктәп, күп санлы мәгариф объектлары, укытучылар өчен фатирлар төзелә. Милли мәгарифне оештыру буенча безнең тәҗрибә ЮНЕСКО тарафыннан хуплана. 1996-1997 уку елында Республикада 986 татар мәктәбе, 176 татар гимназиясе, 94 рус мәктәбендә татар класслары, 224 балалар бакчасы татар телендә эшли. Яңа типтагы уку йортлары булдыру юнәлешендәге экспериментал ь мәктәпләр, фәннәрне, чит телләрне тирәнтен өйрәнү мәктәпләре, укулар 4 телдә алып барыла торган татар-төрек лицейлары (8 лицей) эшли. Белем бирүнең милли төбәк компоненты туып, белемнәрнең дәрәҗәсен күтәрү, отличникларга стипендияләр, аларны хәзерләгән укытучыларга өстенлекләр булдыру тормышка ашырыла. Чит телләрне ана теле нигезендә өйрәнү; чит телләр факультетына мәктәпләрдә чит телләрне тулысынча укымаганнарны кабул итү программалары эшли башлый.

Мәгариф министрлыгыннан киткәч, В.Гайфуллинга татар дәүләт гуманитар институты ректоры вазифасы йөкләнде. Бу институтның һәр адымы аңа яхшы таныш иде, чөнки институтны оештыручыларның берсе булды. Мәгариф министрлыгы ул елларда милли мәктәпне төзү буенча күп эшләде. 1991 елның 1 сентябреннән Татарстанда укучы барлык балаларга да беренче сыйныфтан соңгы сыйныфка кадәр татар теле дәресе кертелде. Руслар да, якутлар, башка милләт балалары да татар телен теләп үзләштерде.

Мәктәпләрнең уку планына яңадан татар халкы тарихы фәне кертелде. Бу яңалыклар укытучыларны күпләп әзерләү бурычын куйды. Бу бурыч гуманитар институтка йөкләнде.

Мәктәпләрдә чит тел өйрәнү дә тар кысаларда калган шикелле. Ләкин аның методикасы, чит телне үзләштермәслек итеп, махсус эшләнгәндер кебек. Безгә чит телне ничек өйрәтергә икәнен төрекләр күрсәтте. Татар-төрек лицейларында укытулар 4 телдә алып барыла. Беренче елны төрек һәм инглиз телләрен өйрәнүгә аеруча нык басым ясала. Ни галәмәт, шул арада икесен дә менә дигән итеп өйрәтеп өлгерәләр. Бу гыйбрәтле мисалны гуманитар институт чит тел укытучылары хәзерләгәндә кулланды.

Чит тел укытучыларын гомер-гомергә педагогика институты әзерләде. Ул факультетта шәһәр балалары гына укыды, чөнки авыл мәктәпләрендә чит тел укытылмады. Авылларга чит телләр факультетыннан укытучы кайтмады, кайтканнары да бер елдан артык эшләмәде. Бу хатаны төзәтүне институт үз өстенә алды. Чит телләр факультетына һәр елны бер төркем студентны чит телдән имтихансыз кабул иттеләр. Махсус методика белән әзерләнгән бу студентлар ике елда чит телне укып килгән студентларны куып җитте.

Кыска гына вакыт эчендә институт тулы канлы булып эшли башлады; аның биналары булдырылды, студентлар өчен тулай торак төзелде, фәннәр буенча көчле укытучылар коллективы тупланды, төрек, гарәп, фарсы, татарлар тарихы, информатика кабинетлары эшли башлады. Институт республикабыз балаларыннан тыш чит республикалардан һәм өлкәләрдән килеп укый башладылар. Институтта хор, драма, музыка, информатика түгәрәкләре эшләде. Анда татар рухы хөкем сөрде. Студентлар фәнни түгәрәкләргә йөрде, ел саен институтны тәмамлаучылардан унлап кеше аспирантурага керде.

2002 елның 26 сентябрендә институтның 10 еллыгы бәйрәмендә аның эшчәнлеген Татарстан җитәкчелеге югары бәяләде. Әмма ни кызганыч, ике ел үтүгә институт эшләүдән туктады, аны ябып куйдылар. Югыйсә, институт киләчәктә ачылырга тиешле татар милли университетына җирлек булып тора ала иде...

В.Гайфуллин – физика методикасы фәне буенча күренекле галим.

Фәнни-тикшеренү эшләрендә В.Гайфуллин төп юнәлеш итеп уку-укыту процессында укучыларның танып-белү активлыгын үстерү проблемасын сайлады. Бу юнәлештә эшчәнлегенең нәтиҗәләре аның кандидатлык диссертациясендә һәм күп сандагы мәкаләләрендә, китапларында чагылыш тапты. Алар күп санлы студентларның, укытучыларның һәм методистларның өстәл китабына әйләнде.

В.Гайфуллинның фәнни хезмәтләре шактый киң. Алар арасында 12 монография, дәреслекләр, мәсьәләләр җыентыклары, методик ярдәмлекләр, әдәби-документаль язмалар, нәшриятларда, газета-журналларда басылып чыккан 300 дән артык мәкалә... В.Гайфуллин җитәкчелегендә 15 аспирант һәм 4 докторант диссертация яклады. Бүген дә ул аспирантларга, докторантларга киңәшләрен бирә, студентлар, коллегалары белән очрашуларга йөри.

Ә.ХУҖИӘХМӘТОВ,
педагогика фәннәре докторы.

Асылташ ул...

Гөлнара Байназарова 1987 елда Яр Чаллы шәһәрендә туып-үсә. Кечкенәдән җырлап үскән кыз балалар бакчасында ук төрле конкурсларда катнашып алдынгы урыннарны ала, әнисе аның бу сәләтен күреп алып, музыка мәктәбенә укырга бирә. Укытучысы Нәфисә Әхмәтшина аңа вокал, җырлау серләрен өйрәтә. Мәктәпне тәмамлагач, ул үз бәхетен Казанда сынап карарга уйлый, туп-туры Казан дәүләт консерваториясенә юл тота. Гадәттә, бу югары уку йортына училищены тәмамлап киләләр. РСФСРның халык артисткасы, профессор Галина Ластовка аны үз классына ала. Шулай итеп, 2004 елда ул Казан дәүләт консерваториясенең әзерлек курсларында укый башлый, ике ел укыгач, консерваториянең төп курсларына күчеп, биш ел дәвамында белем ала. Булачак җырчы бу елларда төрле конкурсларда катнашып лауреат исемнәренә лаек була, Йошкар-Ола шәһәрендә узган «Белая акация», Түбән Камада Салих Сәйдәшев конкурслары – шундыйлардан. Соңгы елларда Әлфия Авзалова, Венера Ганиева исемендәге халыкара конкурсларда катнашып лауреат исемнәрен яулый.

Консерваторияне тәмамлагач, әдәби-музыкаль лекторийның ул вакыттагы сәнгать җитәкчесе, Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисткасы Лидия Әхмәтова чакыруы буенча, ул Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә эшли башлый.

Г.Байназарова шулай ук Казан шәһәре Совет районындагы 6 нчы номерлы сәнгать мәктәбендә ун елга якын вокал укытучы булып эшләргә дә вакыт таба, балалар вокаль ансамблен җитәкли.

Миңа күренекле композитор Сара Садыйкованың кызы Әлфия ханым Айдарскаяның композиторга багышланган концертларын тамаша кылырга туры килде. Гөлнара аларның һәрберсендә чыгыш ясый, ул бу концертларда 2017 елдан бирле җырлый икән, узган елда композиторның юбилее уңаеннан Казанда, Мәскәүдә, Чаллыда зур концертларда катнашкан. Шулай ук ул К.Тинчурин театрында Җ.Фәйзинең «Башмагым» спектаклендә Сәрвәр ролен зур уңыш белән башкара. Биредә яңа гына оешкан проект – «Музыкаль җәүһәрләр» концертларында чыгыш ясый, филармония әдәби-музыкаль лекторий бүлегенең талантлы музыканты, К.Тинчурин театры оркестрына (дирижеры Ильяс Камал) кушылып төрле романслар башкара. Ә филармония әдәби-музыкаль лекторие – аның төп эш урыны. «Рус һәм чит ил композиторларының әсәрләрен күп башкарырга туры килә. Күптән түгел Дж. Россини иҗаты буенча төзелгән концертта Розина ариясен бер ай эчендә өйрәнеп җырладым. Беренче тапкыр сәхнәгә яңа әсәрне алып чыккан чакта һәрчак дулкынланасың. Ай саен яңа тема, классик әсәр булгач, җырның көен, сүзләрен дә җиренә җиткереп өйрәнеп җырларга кирәк», – ди җырчы.

Композитор Рөстәм Яхинның «Яз чәчәген өзмә минем өчен», «Күңелемдә яз», «Син кайда идең» һ.б. әсәрләрен алар Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Георгий Ибушев белән дуэт итеп башкара. Алар сәхнәдә бер-берсен тулыландырып, күз карашлары белән дә җырның эчтәлеген, асылын тамашачыга җиткерәләр ки, бу җыр эчендә хәтта яши башлыйсың, ул сине үз эченә бөтереп алып кереп китә. Гөлнараның сәхнә эшчәнлеге хакында сәхнә остасы Г.Ибушев болай ди: «Гөлнараның филармониягә килүенә ун ел була инде. Шул вакыт эчендә без туганнарга әйләнеп беттек кебек. Ул тиз арада үзенә хөрмәт яулап алды, күңел чисталыгы, ихласлыгы белән. Аның белән бик күп җирләрдә җырларга туры килде. Шулай ук чит илдә – Чехиядә матур чыгыш ясадык. Аның бик яхшы сыйфаты бар, әсәрләрне ул бик тиз өйрәнә. Дуэт җырлавыбызны, классик композиторларның әсәрләрен халык яратып кабул итә. Халык җырларыннан тезмә ясап, «Кәрия-Зәкәрия»ләрне дуэт итеп, мәктәпләрдә җырлап йөрдек. Бик күп төрле спектакльләрдә дә бергә уйныйбыз. Тулысы белән филармония өчен асылташ ул, андый кешеләрнең хезмәтен, талантын күреп бәяли дә белергә кирәк».

Әйе, әле ул яшь, җемелдәп-гөрләп эшли торган чагы.

Алсу ХӘКИМОВА,
Г.Тукай исемендәге
Татар филармониясе
музее мөдире.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

19 март (шимбә). ***Шәгъбән аеның 16 нчы көне. 18 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 19.22 сәгатьтә калка, 6.42 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 12.06 сәгать.***

Алдашу, ялганга бай көн. Бизләр системасы, бил, бөер, тире, сукыр эчәк зәгыйфь. Мунчага бару, массаж ясату, ач тору, төрле дәвалану чараларын куллану файдалы. Кәеф төшәргә мөмкин.

Бавыр авыртканда

Бавыр күзәнәкләрен яңарту өчен, көненә 4-5 тапкыр, ашарга 20 минут кала, 1 әр чәй кашыгы төелгән шайтан таягы (расторопша) орлыгын кабарга кирәк. Дәва курсы 1 айдан кимрәк, 2 айдан артыграк булмаска тиеш. Яисә 1 аш кашыгы сары мәтрүшкә үләнен 1 стакан кайнар суда 15-20 минут төнәтәләр, үлән төпкә төшкәч, сөзәләр, көненә 3 тапкыр, ашаганчы, яртышар стакан эчәләр.

20 март (якшәмбе). ***Шәгъбән аеның 17 нче көне. 19 нчы Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында, 20.51 сәгатьтә калка,6.52 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 12.10 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Күп аралашмаска, күз тиюдән, чит тәэсирләрдән сакланырга кирәк. Бурычка алырга да, бирергә дә ярамый. Нерв системасы, эчәклек, арканың өске өлеше зәгыйфь.

Баллы торма

Кара торманың өске ягын чокып, өчтән бер өлешен алалар да, шунда бал салалар. 3-4 сәгатьтән соң бүленеп чыккан сокны бушатып, яңадан бал өстиләр. Сокны ютәлне басу өчен эчәләр. Балалар өчен исә болай әзерлиләр: кара торманы шакмаклап турап, кәстрүлгә салалар, өстенә шикәр сибәләр һәм газ мичендә 2 сәгать пешерәләр. Шешәгә сөзәләр. Балаларга көненә 3-4 тапкыр, ашар алдыннан, 2 шәр чәй кашыгы бирәләр.

21 март (дүшәмбе). ***Шәгъбән аеның 18 нче көне. 20 нче Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында,22.22 сәгатьтә калка, 7.06 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 12.15 сәгать.***

Үз-үзеңне танып-белү, уйлану, буйсыну, кичерү көне. Өйдә булырга тырышырга, гаиләгә игътибарны арттырырга кирәк. Тәкәбберлек күрсәтергә ярамый. Яңа белем җиңел үзләштерелә. Нерв системасы, сизү әгъзалары, кан тамырлары, ашказаны зәгыйфь. Ит ашауны чикләү хәерле.

Сөт сихәте

Каты ютәлне сөт яхшы дәвалый. Ярты стакан кайнар сөткә шулкадәр үк селтеле минераль су (“Боржоми”) кушып, яисә 1 стакан кайнар сөткә 1 чәй кашыгы бал салып эчәләр. Сабыйларга исә җылы сөткә инҗир салып бирәләр. Яисә 2 суганны вак кына турап, 1 стакан сөттә пешерәләр, 4 сәгать төнәтеп, сөзәләр. Һәр 3 сәгать саен 1 әр аш кашыгы эчәләр. 5 баш суган, ярты баш сарымсакны вак кына турап, ярты литр сөттә йомшарганчы пешерәләр, аннары бал һәм бөтнек төнәтмәсе кушып, һәр сәгать саен 1 әр аш кашыгы кабалар.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга карама

22 март (сишәмбе). ***Шәгъбән аеның 19 нчы көне. 20 нче Ай тәүлегенең дәвамы. Ай Укчы йолдызлыгында,23.56 сәгатьтә калка,7.10 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 12.19 сәгать.***

Үз-үзеңне танып-белү, уйлану, буйсыну, кичерү көне. Өйдә булырга тырышырга, гаиләгә игътибарны арттырырга кирәк. Тәкәбберлек күрсәтергә ярамый. Яңа белем җиңел үзләштерелә. Нерв системасы, сизү әгъзалары, кан тамырлары, ашказаны зәгыйфь. Ит ашауны чикләү хәерле.

23 март (чәршәмбе). ***Шәгъбән аеның 20 нче көне. 21 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 7.25 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 12.25 сәгать.***

Сәяхәткә чыгу, теләсә нинди эш башлау өчен айның иң кулай көне. Кеше хәлиткеч карарлар кабул итәргә сәләтле. Физик эш белән шөгыльләнү, җәяү йөрү, чыныгу файдалы. Саф һавада күбрәк булу, табигать белән хозурлану кәефне күтәрә. Умырткалыкның аскы өлеше, әвернә сөяк, аяк зәгыйфь.

Баланнан желе

Балан җиләкләрен яхшылап юып, агач тукмак белән изәләр, әре иләк аша сытып чыгаралар да, барлыкка килгән 1 стакан сокка 2 стакан шикәр кушып, яхшылап болгаталар, чиста банкаларга бүлеп, суыткычта саклыйлар. Мондый желе салкын тиюдән саклый, кан басымын төшерә, йөрәк авыртуын баса.

24 март (пәнҗешәмбе). ***Шәгъбән аеның 21 нче көне. 22 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 1.28 сәгатьтә калка, 7.54 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 12.30 сәгать.***

Акыл җыю, белем алу, фәннәр өйрәнү көне. Юмарт булырга, ашау-эчүдә үзеңне чикләмәскә кирәк. Күбрәк аралашкан саен, яхшы тәэсирләр дә арта бара. Кан әйләнеше системасы, буыннар, умырткалык зәгыйфь.

Алоэ тирене чистарта

Кими бара торган Айда тирене чистарту уңай нәтиҗә бирә. Алоэ яфракларын юып, иттарткычтан чыгаралар, 1 өлеш яфракка 4 өлеш исәбеннән су кушып, 2-3 минут кайнаталар. Суытып, сөзәләр, яфраклы катнашманы биткә сылап, 15 минут ятып торалар, аннары сөзгәннән соң калган су белән юалар.

25 март (җомга). ***Шәгъбән аеның 22 нче көне. 23 нче Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында,2.49 сәгатьтә калка, 8.40 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 12.34 сәгать.***

Тәвәккәл адымнар ясау хупланмый. Арып-талганчы эшләргә киңәш ителми. Дару үләннәре белән дәвалану уңай нәтиҗә бирә. Иҗат белән шөгыльләнү өчен яхшы вакыт.

Солы кесәле

Ашкайнату начар булганда, эч кипкәндә, күбенгәндә, солы кесәле файдалы. 0,5 кг солы ярмасын 3 литрлы банкага салып, 1,5 л су өстиләр, тастымал каплап, җылы урынга куялар. 3 тәүлектән соң яхшылап болгаталар, иләк аша сөзеп, сыеклыкны көчле утта, болгата-болгата, кайнатып чыгаралар да сүндерәләр. Шикәр дә, тоз да өстәргә кирәкми. Суынган кесәлне бал яки җиләк ширбәте белән ашыйлар.

Уфтану

Чиләбе каласыннан кайгы хәбәре килеп иреште. Ул асыл гомерен, табиблек белемен Златоуст каласына, андагы милләттәшләребезгә багышлаган табиб-офтальмолог Зәкия ханым Байтукалова-Даушева турында иде.

Билгеле, инде 90 ның аръягында булса да, аның бакыйлыкка күчүе табибәне белгән затлар өчен авыр хәбәр. Игътибарлы газета укучыларыбыз тәгаен яхшы хәтерлидер. Без берничә ел язмаларыбызда Байтукалов мирасы турында сүз алып бардык. Златоустка китеп урнашкан һәм үзеннән соң тарихи мирас калдырган дин галиме, журналист Мөхәммәдтаһир Байтукаловка бәйле язмалар шактый укучыларда кызыксыну уятты. Мөхәммәдтаһирның хатыны, чыгышы белән хәзерге Сарман районы Нөркәй авылы кызы Бәхрелхаятка багышлап, “Мәдәни җомга”да “Тәйсуган ханбикәсе” мәкаләсе дә басылып чыккан иде. Ул әлеге иманлы гаиләнең Тәйсуган авылында 1929 елга кадәр яшәгән чорына багышланган иде. “Ханбикә” дип зурлау 1912 елда төшерелгән фотосурәттә Бәхрелхаят гаҗәеп күркәм калфак киеп төшүенә, шул вакытта ук указлы мулла, 250 гә якын шәкерт укыган мәдрәсә җитәкчесе Мөхәммәдтаһирның никадәр алдынгы карашлы зат булуына ишарә иде.

Зәкия ханым Даушева әлеге данлы гаиләнең иң соңгы буыны иде. 1962 елда әтисе Мөхәммәдтаһир вафатыннан соң, Зәкия ханымга янә бер тарихи бурыч йөкләнелә. Ул да булса әтисенең кулъязма мирасын күз карасыдай саклау, аны татар җәмәгатьчелегенә ирештерү. Әле котырган атеизм чоры җилләре исә, дини мирасны рәхимсез рәвештә санга сукмау гадәте көчле сөрә иде. Ире, киң профильле табиб Әхмәд Даушев ярдәмендә милләтне гафләт йокысыннан уяту өчен чая адымнар ясасалар да, сизелерлек нәтиҗәгә ирешмиләр. Соңыннан Әхмәд Даушев татар-башкорт милли хәрәкәтенә нигез салып кына калмый, Златоуст Үзәк китапханәсендә татар китаплары секторы ачуга ирешә, Казаннан йөзләрчә китаплар алып кайта, махсус штат булдыра. Милләтпәрвәр шәхес вафат булгач, әлеге секторга аның исеме бирелә.

Соңгы чорда Зәкия ханым һичнигә карамый әтисенең 1500 биттән торган мирасын халыкка җиткерү юнәлешендә армый-талмый эшләде. Бер өлеш мирас “Мәсаил вәгазь” исемендә басылып, ул аны укып чыгарга өлгерсә дә, яхшы сыйфатлы итеп чыгарылган буклетны, ягъни Байтукаловларның Ризаэтдин Фәхретдин язмаларыннан ук килгән тарихи белешмәләрен туплаган бай мәгълүматлы басманы күреп куанырга җитешә алмады. Иншалла, мирасның калган өлеше дә бу елда басылып чыгар, дини тормышыбыз күгендә нурлы балкыштай эз калдырыр.

Зәкия ханым татарлыгыбызны Урал якларында чагылдырган, якты рух, якты нур белән яшәгән зыялы мөхтәрәм хатын-кызларыбызның берсе иде.

Нарим ИХСАНОВ.
Казан.

Тамаша залларына чакыра

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

18 март – 19.00 – «Бабайлар чуагы» (И.Зәйниев). 20.00 – «Киек каз юлы» (И.Мөхәммәтгалиев).
19 март – 12.00 – «Исәнме, улым» (Б.Абдураззоков). 19.00 – «Сүнгән йолдызлар» (К.Тинчурин).
20 март – 17.00 – Шәрык клубы бинасында – Оркестр музыкантлары концерты. 18.00 – «Җанкисәккәем» (Т.Миңнуллин). 19.00 – «Тамашачы тамашасы».
22 март – «Җәйнең бер көнендә» (Й.Фоссе).
23 март – «Исәнмесез?!» (М.Гыйләҗев).
24 март – «Өйләнәм.tat» (И.Зәйниев).
25 март – «Санаулы кичләр» (А.Володин).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

19, 20 март – «Пер Гюнт» (Э.Григ).
22 март – «Шагыйрь мәхәббәте» (Р.Ахиярова).
24 март – «Шүрәле» (Ф.Яруллин).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

18 март – «Ядәч! Исемдә! Бер гаилә трагикомедиясе» (Й.Миңнуллина, М.Гафурова, А.Бикбулатов, Э.Дусаева).
20 март – «Полиционер» (И.Зәйниев).
22 март – «Карурман» (Л.Янсуар, Р.Гарипова).
23 март – «Утка очкан күбәләктәй» (Н.Гыйматдинова, Т.Хәләф инсценировкасы).
24 март – «Син бит минем бергенәм» (И.Мәхмүтова).
25 март – «Өч аршын җир» (А.Гыйләҗев).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

19 март – 13.00 – «Минем бәхетле көнем» (Е.Гороховская). 18.00 – «Тапшырыл...ган хатлар» (Г.Кутуй).
20 март – «Корт» (Ф.Галиев).
22 март – 13.00, 18.30 – «Камыр батыр».
24 март – «Мио, минем Мио!» (А.Линдгрен).
25 март – «Яратып туялмадым» (А.Әхмәтгалиева).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

18 март – 11.00 – «Принцесса Крапинка» (А.Шмидт). 19.00 – «Әлдермештән Әлмәндәр» (Т.Миңнуллин).
19 март – 11.00, 13.00, 15.00 – «Золушка» (Е.Шварц). 12.00 – «Йолдыз тапкан кыз» (Ф.Яруллин).
20 март – 10.00 – «Приключения пингвиненка Пинка» (А.Галиуллина). 12.00, 14.00 – «Буратино» (А.Толстой). 13.00 – «Сертотмас үрдәк» (А.Алиш).
23 март – 11.00, 13.30 – «Мияубатыр» (Н.Исәнбәт).
24 март – 11.00, 13.00 – «Щелкунчик» (Э.Т.А.Гофман).
25 март – 11.00, 13.00 – «Волшебник Изумрудного города» (А.Волков). 19.00 – «Адәмнәр» (Г.Ибраһимов).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

20 март – 11.00 – Балалар өчен джаз концерты. 17.00 – Җырчы Вил Усманов концерты.
21 март – Игорь Губерман кичәсе.
22 март – «Спящая красавица» балеты.
23 март – Георгий Чаидзе концерты (фортепиано).
24, 25 март – «Лебединое озеро» балеты.

Сәүдәгәр оныгы

Сугыштан соңгы елларда безнең Арча районында бүреләр күбәйде. Урманнарда, болыннарда, кырларда алар төркем-төркем йөриләр иде. Авылга килеп бүреләрнең кәҗә-сарыкларны, хәтта бозауларны да чәлдереп китүе гадәти күренешкә әйләнде. Шулай да мин бүреләрнең кешеләргә һөҗүм итү очракларын хәтерләмим. Бабам Мөхәммәтҗан: «Әгәр үзең кагылмасаң, бүре кешегә тими ул. Бүредән түгел, кешеләрдән куркырга кирәк», – дип әйтә торган иде.

Еллар үткән саен бабамның сүзләре еш хәтергә төшә. Бабам хаклы булган шул. Безнең тормышта гаделсезлек адым саен очрап тора. Хәер, ул бүген генә туган нәрсә түгел. Элек-электән надан, шәфкатьсез зат түрә булып алса, башкаларны җәберләргә керешкән, аларны юк итү юлларын эзләгән һәм тапкан да.

Һәр җитешсезлек өчен бездә системаны гаепләргә яраталар. Әмма система белән конкрет кеше идарә итүен онытырга ярамый. Җитәкчеләр исә законнарны да, Конституцияне дә, тулаем системаны да үзләренә яраклаштырырга тырыша. Шулай да илне кризистан, халыкны хәерчелектән коткара алмыйлар. Росстат мәгълүматларына караганда узган ел ахырында илдә ярлылар саны 19,9 миллион кешегә җиткән.

Сталин чорында «халык дошманы» ярлыгы тагылган затларның балалары гына түгел, оныклары да, тулаем бөтен нәсел-нәсәбе гомерләре буе кимсетелә. Республикада бик күпләргә мәгълүм шәхес, вакытында Татарстан Югары Советы депутаты да булган, эшкуар Морат Сиражин да, очрашкан саен, бабасы Борһанны искә төшерми калмый. Аның турында сөйли башлауга күзләре яшьләнә. Югыйсә ул – физик яктан бик нык, түзем бәндә. Офицер малае буларак язмыш аны һәрдаим бер урыннан икенче урынга күчереп йөртә. Красноярск янындагы урман эчендә урнашкан хәрби шәһәрчектә туган Морат бөтен Союзны айкый.

М.Сиражинның һәр мәсьәләгә карата үз фикере бар иде. Еш кына ул башкаларныкыннан нык аерылып тора, күпләргә сәер тоела. Шулай бервакыт мин Мораттан: «Сез Себердә туып-үскән кеше. Борынгы бабаларыгыз ватанына кайтуыгызга нәрсә сәбәпче булды?» – дип сораган идем. Ул төп сәбәпне әйткәнче башта болай диде: «Татарстанны мин борынгы бабаларымның ватаны дип санамыйм. Бабаларымның ватаны – ул бөтен Россия. Себер, Татар бугазы, Байкал, хәтта Алтай атамалары да татарныкы. Урта гасырлардагы Европа картасын алып карагыз. Ул чакта бөтен Россия территориясе Тартария дип аталган. Географик атамаларның яртысы диярлек төрки телләрдән алынган. Шунлыктан мин ватанымны киңрәк күз алдыма китерәм. Ә Татарстан ватанның бер өлеше генә ул».

Казанга кайтуларының асыл сәбәбен Морат болай аңлатты: «Әти хәрби хезмәттән запаска чыккач, аңа Мәскәү, Ленинград, Киевтән кала теләгән шәһәрен сайларга мөмкинлек биргәннәр. Бер ел эчендә фатир вәгъдә ителгән. Без Казанны сайладык. Чөнки биредә ерак туганнарыбыз яши иде».

М.Сиражин Казан дәүләт төзүче инженерлар институтын тәмамлый. Аннары Биектау районында урнашкан экспериментал күчмә колоннаны җитәкли. 90 нчы елларда Татарстан Югары Советы депутаты итеп сайланды. Ул бик актив депутат иде. Әйтүенә караганда, ул Конституция кабул ителгәндә каршы тавыш биргән. Бу гамәлен Морат Конституциядә каршылыкларның, бүгенге чорда тормышка ашырып булмый торган нигезләмәләрнең кертелгән булуы белән аңлата.

Күрәсең, холкы шундыйдыр, М.Сиражин гаделсезлек белән килешә алмый. Ә аларны шактый күп күрә шул. 1937 елда кулга алынган бабасының трагик язмышын да озак вакытлар ачыклый алмый. Төрле архивларга мөрәҗәгать итә, Дәүләт куркынычсызлык комитеты органнары юлын таптый. Депутат таныклыгын күрсәтеп мөрәҗәгать иткәч кенә, Омск КГБсыннан ул документлар күчермәләрен алуга ирешә. Алар белән мин дә танышып чыктым. Борһанны революциягә каршы милли хәрәкәт оештыруда, чит ил разведкасы белән элемтәдә торуда, аларга хезмәт күрсәтүдә гаеплиләр.

КГБ 22 «җинаятьче»не бер төркемгә туплый. Аларның бер өлеше сәүдәгәрләр, икенче өлеше – дин әһелләре, кунаклар. Араларында урам себерүчеләр, каравылда торучылар да бар. Барысы да татарлар, 1937 елның август-сентябрь айларында кулга алына, «өчлек» тарафыннан 12 октябрьдә гаепләү документлары әзерләү төгәлләнә. Барысы да 25 октябрьдә атып үтерелә.

Егерме елдан соң, төгәлрәк әйткәндә, 1957 елның 15 февралендә, Себер хәрби округы прокуроры, юстиция полковнигы П.Орлов гаепләнүчеләрнең документлары белән җентекләп танышкач, «өчлек» карарын юкка чыгаруны таләп итә. Шушы ук елның 26 февралендә Себер хәрби округы трибунал карарын юкка чыгара. Бу документтагы сүзләр җанны өшетә. «Нами проверено и установлено: По постановлению тройки УНКВД по Омской области от 25.10.37 Сиразин Бурган (отчества нет) – расстрелян. Определением военного трибунала Сиб ВО от 26.02.57 по протесту военного прокурора Сибирского военного округа вышеназванное определение Тройки отменено и уголовное дело прекращено за отсутствием в его действиях состава преступления». Әмма бу кешеләрнең атып үтерүләре, аннары акланулары турында гаиләләренә берникинди хәбәр җибәрелми. Шулай итеп алар үзләре генә түгел, туган-тумачалары да кимсетелә.

Борһан Мифтах улы Сиражин 1891 елда Томск шәһәрендә туа. Сәүдәгәр, мөселман общинасының актив әгъзасы. Кулга алынганда «Союзмука» оешмасында эшләгән. Борһан белән бергә атылучыларның язмышлары туган-тумачаларына мәгълүм булмавы да бар. Шунлыктан аларның берничәсен генә булса да телгә алып узу урынлы булыр.

... Сабитов Абзал Закир улы 1888 елда Татарстанның Апас районы Танаева авылында туа. Элеккеге эре сәүдәгәр. Омскида мануфактура кибете була. Кулга алынганда, Омскиның музыка инструментлары комбинатында каравылчы булган.

... Агишев Мөхәммәтҗан Әлим улы. 1878 елда Кузнецк шәһәрендә туа. Омскида абыйсы белән бергә тукыма фабрикасы ачалар.

... Бекбаев Хайрулла Вәли улы. 1881 елда Башкортстанның Стәрлетамак шәһәрендә туа. Әти-әнисе сәүдәгәрләр. Үзе мулла була. Югары дини училище тәмамлаган.

... Сәетов Нәби Мөхәммәтҗан улы Омски өлкәсенең Большереченск районы Көекүл авылында туган. Элеккеге мулла, кулак. Нарымга сөргенгә җибәрелгән. Аннан качып киткән. Кулга алынганчы, Омскида яшәгән.

... Измайлов Гайнетдин Хөснетдин улы, 1886 елда туган, сәүдәгәр. Омскида лареклары булган.

Морат Сиражин институтка кергәндә дә, депутат булып сайланганда да, «халык дошманы» оныгы булуын искә төшерәләр, төрле киртәләр куярга тырышалар. «Мин сезгә үз биографиямнән бер факт китермәкче булам, - диде Морат бер очрашканда. – СССР халык депутатларын сайлаганда, мине Коркачык төзү материаллары комбинаты кандидат итеп күрсәткән иде. Аның директорын КПСС өлкә комитетының оештыру бүлегенә чакырып кыздыралар. Минем биографиям, нинди милләттән булуым белән кызыксындылар. Биографиямне ачыклагач, үз урынымны белергә тиешлегемне искәрттеләр. Әгәр тагын югарыда утыручыларга каршы барсам, Себергә җибәрү белән янадылар. Себер татарын Себер белән куркытып булмый бит инде».

М.Сиражин шул чорда эшкуарлыкка башы-аягы белән кереп чума. Биектау районының Коркачык авылында буяулар эшләүче предприятие ачып җибәрә. Коймага эре хәрефләр белән: «Сиразин покрасит весь мир!» – дип язып куя. Әмма ул бөтен дөньяны тәэмин итәрлек буяу чыгара алмады. Аны Шелангада ачылган төзелеш комбинатына инженер итеп чакыралар, предприятиесен сатып, Морат шунда китеп бара.

Сөйләвенә караганда, ул биредә дә җиң сызганып эшли. Комбинатның техник мөмкинлекләрен арттыру буенча шактый уңышларга ирешә. Шулай да җитәкчелекнең финансны төрлечә туздыруы белән килешә алмый. Бу хакта ул җитәкчеләр белән ачыктан-ачык сөйләшеп тә карый. Әмма үзара килешүгә килмиләр. Мондый хәлгә ризасызлык белдереп, Сиражин эштән китә. Фермерлык белән шөгыльләнә башлый.

Моратның Шелангадагы фермер хуҗалыгын да карап кайтырга насыйп булды. Аның хуҗалыгы бистә читендә урнашкан, йорты иркен, терлекләр өчен төрле корылмалары да җитәрлек. Янәшәдә буш җирләр, чокыр-чакырлар күп, кечкенә генә күл дә бар. Аллаһы табигать матурлыгын кызганмыйча биргән бу төбәккә.

Шулай да терлекләр, кош-корт саны да әллә ни күп күренмәде. Морат минем гаҗәпләнүне аңлады булса кирәк, үзе үк сөйли башлады:

– Элек минем тавыклар, үрдәкләр, казлар меңнән артык иде. Аларның төгәл санын үзем дә белми идем. Бервакыт кич шулай район хакимияте башлыгы килде. Минем керемнәр белән кызыксынгач: «Синең җан башына алынган табышың район хакимияте хезмәткәрләренекеннән икеләтә артык икән бит», – ди. Шуннан соң мине төрлечә кыса башладылар. Үрдәк-казларны күлдә коендырырга ярамады. Кәҗәләрне, дуңгызларны болынга чыгаруны тыйдылар.

Аннан соң полиция хезмәткәрләре килеп, терлекләрең ишегалдыннан чыкса, аларны атабыз дип кисәткәннәр. Югыйсә хуҗалыгын җәелдерергә теләгән фермерга төрле яклап ярдәм күрсәтергә кирәк иде дә бит.

М.Сиражин алтмышлап кәҗә, ишәкләр тота. Ишәк сөте бик файдалы һәм кыйммәт бәяләнә дип сөйләде ул очрашкан чакта. Утта – янмас, суда батмас Сиражин диләр иде аны. Кызганыч, быелтыр М.Сиражин безне калдырып бакыйлыкка күчте. Хөр фикерле, үзенчәлекле шәхес иде ул.

Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ.

Төгәл фараз

Хәзерге смартфонның нинди буласын Америка эшкуары Марк Салливан моннан җитмеш елга якын элек сурәтләп биргән, аның фаразы язылган мәкалә Tacoma News Tribune газетасында 1953 елның 11 апрелендә басылып чыккан. Сан-Францискодагы Pacific Telephone and Telegraph компаниясе директоры Салливан: "Киләчәк телефонының формасы нинди булачагын фаразласак, әлеге смартфонны кеше бүген без кул сәгатен тагып йөргән кебек һәрвакыт янында йөртәчәк. Аннан файдаланучылар исә, теләсә, сөйләшкәндә бер-берсен күрә дә алачак. Кем белә, бәлки әле ул сөйләшүне бер телдән икенче телгә тәрҗемә дә итеп бирер", – дигән. Әлеге материал басылганда хәтта микроэлектроникага нигез итеп алынган транзистор да уйлап табылмаган булган әле. Бер дистә елдан соң исә язучы-фантаст Айзек Азимов The New York Times газетасына мәкаләсендә, киләчәк телефоны экранында абонентны күреп булачак, ул документлар өйрәнү, фотолар карау, китап уку өчен дә файдаланылачак, дип фаразлый, бу шулай булып чыга да.

("Phone Arena").

Файдасы зур

Галимнәр раславынча, үбешү бик файдалы. Үбешкәндә бүленеп чыга торган ферментлар стресс гормоны глюкокортикоид ясалуга каршы тора, нейропептидлар исә тагын бер шундый гормон – кортизолны юкка чыгара. Үбешкәндә адреналин бүленеп чыгу да көчәя, бу исә психик активлыкны арттыра. Берлин университеты психологлары дәлилләгәнчә, иртәнге егермешәр секундлык өч үбешү көн буена җитәрлек күтәренке кәеф тудыра. Озак итеп үбешү вегетатив-кан тамырлары дистониясе өянәген туктатырга сәләтле (бу очракта да гормональ фон нормальләшә). Үбешү вакытында 34 мускул (шулардан 12 се – ирен янында, 17 се – телдә) хәрәкәткә килә һәм канга бәхет гормоны – эндорфин бүлеп чыгара. Дәртле үбешү йөрәк тибешен минутына 150 тапкырга җиткерергә мөмкин – бу исә баш мие күзәнәкләрен канга һәм кислородка баета, фикерләү сәләтен арттыра. Авыздагы селәгәйдә гаять күп бактерия яши, шулардан 80 проценты – бөтен кешедә бер үк төрле, 20 проценты исә – шәхси. Чит бактерияләр килеп кергәч, безнең иммунитет көрәшкә күтәрелә, антитәнчекләр ясый башлый, ныгый. Чикаго университеты стоматологлары исә тәҗрибә юлы белән тагын бер нәрсәне ачыклаган: үбешкәндә, селәгәй күбрәк бүленеп чыга, ул тешләрне юа, сагыздан да яхшырак чистарта – димәк, даими рәвештә озаклап үбешү кариестан саклый. Очкылык тотканда, аннан үбешеп котылып була. Бер минутлык дәртле үбешү вакытында 12 килокалория яна – бу исә бер чакрым арага йөгерү яисә тирләп-пешеп идән юуга тиң.

("МедНовости.ру").

Мең дә бер аерма

Хатын-кызлар – күкрәк, ир-атлар – корсак белән сулый. Гүзәл зат кулының буш булуын яратмый, шуңа һәрвакыт сумка тотып йөри, ирләргә исә ике кулның да буш булуы мөһим. Киенгәндә, хатын-кыз башта кофта, аннары чалбар кия, ирләр исә – киресенчә. Хатыннар беркайчан да футболканы аркасыннан тотып салмый. Берәрсе дәшсә, хатын-кыз башын гына бора, ир-ат исә бөтен гәүдәсе белән борыла. Нәфис затлар колагын бармак белән, ирләр – уч белән каплый. Кулны күрсәтергә кирәк булганда, ирләр учларын ачып суза, хатын-кызлар исә кул аркасын күрсәтә.

("Der Spiegel").

Ньютон фаразы

Иерусалимдагы борынгы яһүд университетында бөек физик Исаак Ньютон кулъязмасы саклана. Анда ул 2060 елда дөнья бетүен фаразлаган. Классик физика даһие, беренче көзгеле телескоп ясаган Ньютон законнары безгә мәктәптән таныш. 1643-1727 елларда яшәгән галимгә ышанырга була, шуңа да аның юравы кешеләрне куркуга сала. "Ньютон серләре" дигән кулъязмада дөньяның 2060 елда бетәчәге акка кара белән язып куелган. Бөек физик моны, 50 ел вакытын сарыф итеп, Тәүратта язылганнарны укып-аңлап ачыклаган, 4 мең ярым биттә исәпләүләр үткәргән. Әлеге кулъязма Яһүд милли китапханәсе архивында 2002 елда гына табылган.

("Die Welt").

Агы тынычландыра, сарысы чистарта

Бер төстәге ризыкларның үзлекләре охшаш, ди галимнәр. Ак төстәге ашамлыклар (сөт, эремчек, дөге, сарымсак) тынычландыра, ярсуны баса, организмнан агулы матдәләрне чыгара. Карасу-шәмәхә төстәгеләр (йөзем, кара җиләк, кара җимеш, шәмәхә кабыклы бәрәңге, баклажан) биологик актив антоциан матдәсенә бай, шуңа кан тамырлары һәм күз өчен файдалы. Яшел ризыклар (салат, кәбестә, кыяр, борчак) баш миен туендыра, активлыкны арттыра, аруны баса. Алардагы хлорофилл канда эритроцитлар эшләнүне җайга сала, иммун системаны активлаштыра. Кызыл чөгендер, борыч, җиләк, помидор матдәләр алмашын җайга сала, кан әйләнешен яхшырта, эшкә сәләтлелекне арттыра. Кызгылт-сары төстәге өрек, шәфталу, кабак, әфлисун, мандарин, кишер нерв күзәнәкләрен торгызуга булыша, мускул тукымасын яңарта, җенси дәртне көчәйтә, кәефне күтәрә, баш авыртуны баса. Сары лимон, ананас, банан, сыр, кукуруз, йомырка ашкайнатуны җайга сала, аппетитны яхшырта, канны чистарта.

("Batona.net").

Сөт диабеттан саклый

Сөт ризыкларындагы туендырылган майларны "аклау" дәвам итә, сөт үзе исә иң мөһим иртәнге ашлар исемлегенә кертелгән инде. Канаданың Гуэлф университетыннан профессор Дуглас Гофф тикшеренүләре икенче типтагы шикәр чирен кисәтүдә һәм артык симерүне булдырмауда сөтнең файдасын күрсәткән. Ул һәркемгә иртән 250 миллилитр сөт эчәргә куша. Сөттәге аксым, ашкайнату процессын әкренәйтеп, ачлык хисен киметә торган гормоннар барлыкка килүгә булыша икән. Сөт кандагы шикәр микъдарын нормада тоту мөмкинлеген бирә, һәм, әлеге эчемлектә аксым күбрәк булган саен, углеводка бай иртәнге аштан соң шикәр күләме шулкадәр тизрәк кими. Техас университетыннан доктор Марсия Отто да, тикшеренү үткәреп, сөттәге туендырылган майның өлкән яшьтәгеләрдә йөрәк-кан тамырлары авырулары килеп чыгу ихтималын бер дә арттырмавын дәлилләгән. Тагын бер тикшеренү исә сөттәге бер май кислотасының инсульттан һәм йөрәк-кан тамырлары авыруларыннан үлеп китү куркынычын киметүен күрсәткән. Сыр, сөт, йогуртта кан басымын төшерә, ялкынсынуны баса торган май кислоталары шактый. Канада тикшеренүчеләре фикеренчә, майлы сөт, сыр, катык һәм атланмайны даими куллану инсульттан үлү куркынычын 42 процентка киметә.

("Die Welt").



Һава чистарткыч бина

Америкадагы Skidmore, Owings & Merrill архитектура агентлыгы Urban Sequoia ("Шәһәр секвойясы") дип аталган күктерәр йорт проектын эшләгән, ул һаваны углекислый газдан чистартуга тәгаенләнә. Якынча исәпләүләр буенча, бина үзенә елына 1 мең тонна углерод сеңдерәчәк, бу исә 48500 агач йоткан кадәр күләмдәге углекислый газ дигән сүз. Футуристик дизайндагы, пыяла һәм яшеллек күп булган йорт агач һәм биобетон кебек экологик чиста материалдан салыначак, бу төзелештән килгән зыянны яртылаш киметәчәк. Моннан тыш, 60 ел эчендә күктерәр бина төзелеш вакытында һавага чыгарылганнан 400 процентка артыграк CO_2 йотачак. Җыелган газны сәнәгатьтә төрле максатларда файдаланып булачак, бу углерод циклын тәгәлләү һәм һавадан углекислый газны аерып алуга нигезләнгән яңа икътисади система төзү мөмкинлеген бирәчәк.

("РБК").

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

21 март
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». 12+
10.00, 23.00 «ЛЮБОВЬ ПО ПРИКАЗУ». 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Семь дней». 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ». 12+
15.15 «Уймак» һәм «Сәйлән».
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Мин». 12+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Каравай». 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.20 «Шаян хәлләр». 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЛАНЦЕТ». 12+
10.30 «ДВОЙНАЯ ЖИЗНЬ». 12+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «МУШКЕТЕРЫ. НЕИЗВЕСТНАЯ МИССИЯ». 16+
14.35 «Люди РФ». 12+
15.00 «Это лечится». 12+
15.30 «Мечтатели». 12+
16.20 «Фиксики».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
21.00 «УЛЫБКА ПЕРЕСМЕШНИКА». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.25, 12.15, 15.15, 18.20 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
22.00 «ЯНЫЧАР». 16+
22.55 «Большая игра». 16+
23.55 Документальное расследование «Большая игра». 18+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.50 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Августин Бетанкур.
7.35, 18.35 «Солнце - ад на небесах».
8.35, 18.20 Открытое письмо. «Первые открытки в России».
8.55, 16.35 «ВАРЬКИНА ЗЕМЛЯ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Нина Сазонова... Судьбы моей простое полотно...»
12.20 «Кинескоп». Международный кинофестиваль в Гётеборге.
13.05 «Владикавказ. Дом для Сонечки».
13.35 Линия жизни. Аристарх Ливанов.
14.30 «Школа будущего».
15.05 Новости. Подробно. АРТ.
15.20 «Агора».
16.20 Цвет времени. Эдуард Мане. «Бар в Фоли-Бержер».
17.35 К 95-летию со дня рождения Мстислава Ростроповича. Лоренц Настурика-Гершовичи и Камерный оркестр Мюнхенской филармонии.
19.45 Главная роль.
20.05 «Семинар». Роман Бузунов. «Как побороть бессонницу ограничением сна?»
20.50 «Женщина, которая строила города». Людмила Кусакова».
21.40 «Сати. Нескучная классика...»
22.25 «БЕРЕЗКА».
23.20 «Дом архитектора». «Дом архитектурных ценностей».

«НТВ»

5.35 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня.
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ПОРТ». 16+
23.40 «ПЁС». 16+

Сишәмбе

22 март
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». 12+
10.00, 23.00 «ЛЮБОВЬ ПО ПРИКАЗУ». 12+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
11.15 «Память сердца». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Родная земля». 12+
13.30 «Юлчы». 6+
14.00 «Путь». 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ». 12+
15.15 «Уймак» һәм «Сәйлән».
16.00 «Ватандашлар». 12+
18.00 «Казаннан - казанга». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».
21.00, 0.15 «Соотечественники». 12+
23.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40 «Туган җир». 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
15.30 «Тамчы-шоу». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЛАНЦЕТ». 12+
10.30, 21.00 «УЛЫБКА ПЕРЕСМЕШНИКА». 12+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «А ВОТ И ОНА». 16+
14.35 «Люди РФ». 12+
15.00 «Инвиво». 12+
15.30 «Погоня за вкусом». 16+
16.20 «Фиксики».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.25, 12.15, 15.15, 18.20 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
22.00 «ЯНЫЧАР». 16+
22.55 «Большая игра». 16+
23.55 Документальное расследование «Большая игра». 18+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.50 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35, 18.35 «Гибель Венеры».
8.35, 17.20 Открытое письмо. «Спорт на открытках XX века».
8.55, 16.30 «ВАРЬКИНА ЗЕМЛЯ».
9.45 «Либретто». Л.Делиб «Коппелия».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Композитор Родион Щедрин».
12.05 Дороги старых мастеров. «Лоскутный театр».
12.15, 22.25 «БЕРЕЗКА».
13.05 «Шри-Ланка. Маунт Лавиния».
13.35 «Женщина, которая строила города». Людмила Кусакова».
14.30 «Школа будущего».
15.05 Новости. Подробно. Книги.
15.20 «Рассекреченная история».
15.50 «Сати. Нескучная классика...»
17.35 К 95-летию со дня рождения Мстислава Ростроповича. Парад виолончелистов.
19.45 Главная роль.
20.05 «Семинар». Виктор Солкин. «Каким был бы XXI век, если бы не было Древнего Египта».
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 Искусственный отбор.
21.40 «Белая студия».
23.20 «Дом архитектора». «Дом наследников авангарда».

«НТВ»

4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня.
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ПОРТ». 16+
23.40 «ПЁС». 16+

Чәршәмбе

23 март
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». 12+
10.00, 23.00 «БЕСЦЕННАЯ ЛЮБОВЬ». 12+
11.00, 0.15 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00, 0.40 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия». 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ». 12+
15.15 «Шома бас» һәм «Сәйлән».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».
21.00, 23.50 «Соотечественники». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
9.40 «Йөрәктән-йөрәккә». Мөнир Якупов турында телеочерк. 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
15.30 «Яшьләр тукталышы». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.30 «Юлчы». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЛАНЦЕТ». 12+
10.30, 21.00 «УЛЫБКА ПЕРЕСМЕШНИКА». 12+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ИМУЩЕСТВО С ХВОСТОМ». 12+
14.35 «Люди РФ». 12+
15.00 «Без химии». 12+
15.30 «Инстаграмщицы». 16+
16.30 «Фиксики».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.25, 12.15, 15.15, 18.20 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
22.00 «ЯНЫЧАР». 16+
22.55 «Большая игра». 16+
23.55 Документальное расследование «Большая игра». 18+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.50 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35, 18.35 «Жизнь, пришедшая из космоса».
8.35, 18.20 Открытое письмо. «Театр и кино на открытках Серебряного века».
8.55, 16.35 «ВАРЬКИНА ЗЕМЛЯ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Жили-были. Рассказывает Виктор Шкловский». 1977 г.
12.15, 22.25 «БЕРЕЗКА».
13.05 Искусственный отбор.
13.45 «Алексей Попов. Трагедия в трех актах с прологом и эпилогом».
14.30 «Школа будущего».
15.05 Новости. Подробно. Кино.
15.20 «Библейский сюжет».
15.50 «Белая студия».
17.35 К 95-летию со дня рождения Мстислава Ростроповича. Максим Венгеров и Ваг Папян.
19.45 Главная роль.
20.05 «Семинар». Егор Москвитин. «Зрители на карантине. Постковидный синдром».
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 Абсолютный слух.
21.40 Власть факта. «Древнеегипетская цивилизация: секреты устойчивости».
23.20 «Дом архитектора». «Дом любителей модернизма».

«НТВ»

4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня.
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ПОРТ». 16+
23.40 «ПЁС». 16+

Пәнҗешәмбе

24 март
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». 12+
10.00, 0.00 «БЕСЦЕННАЯ ЛЮБОВЬ». 12+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ». 12+
15.15 «Бергәләп өйрәник» һәм «Сәйлән».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
18.00 «Юлчы». 6+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».
21.00 «Ватандашлар». 12+
22.10 «Безнең Республика - безнең гамәл». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Венера йолдызлыгында». Венера Ганиева турында телеочерк. 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
15.30 «Халкым минем». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.10 «Ватандашлар». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.30 «Калеб». 6+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЛАНЦЕТ». 12+
10.30, 21.00 «УЛЫБКА ПЕРЕСМЕШНИКА». 12+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «РОМОВЫЙ ДНЕВНИК». 16+
15.00 «Еда. Правильное питание». 12+
15.30 «Верю не верю». 16+
16.20 «Фиксики».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.25, 12.15, 15.15, 18.20 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
22.00 «ЯНЫЧАР». 16+
22.55 «Большая игра». 16+
23.55 Документальное расследование «Большая игра». 18+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.50 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35, 18.35 «Жизнь, пришедшая из космоса».
8.35, 18.20 Открытое письмо. «Портрет эпохи. Истории, рассказанные фотооткрыткой».
8.55, 16.35 «ВАРЬКИНА ЗЕМЛЯ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Творческий вечер Николая Доризо в Колонном зале Дома Союзов».
12.15, 22.25 «БЕРЕЗКА».
13.10 Абсолютный слух.
13.50 Острова. Лидия Чуковская.
14.30 «Школа будущего».
15.05 Новости. Подробно. Театр.
15.20 Пряничный домик. «Северная роспись».
15.45 «2 Верник 2».
17.35 К 95-летию со дня рождения Мстислава Ростроповича. Алиса Вайлерштайн, Пааво Ярви и Оркестр де Пари.
19.45 Главная роль.
20.05 Открытая книга.
20.30 Цвет времени. Павел Федотов.
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 «Калина красная». Слишком русское кино».
21.40 «Энигма. И-Пинь Янг».
23.20 «Дом архитектора». «Дом нового в старом».

«НТВ»
4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня.
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ». 16+
11.00 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СУДЬБЫ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ПОРТ». 16+
23.40 «ЧП. Расследование». 16+

Җомга

25 март
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». 12+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30, 16.30, 21.00 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.15 «Рыцари вечности». 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ». 12+
15.15 «Төймә» һәм «Сәйлән».
16.00 «Мин». 12+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «КВН РТ-2022». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 15.30 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.10 «Туган җир». 12+
20.00 «Әниемнең җылы кочагы». 6+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «ЛАНЦЕТ». 12+
10.30, 21.00 «УЛЫБКА ПЕРЕСМЕШНИКА». 12+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.50 «ПРЕДАННЫЙ САДОВНИК». 16+
15.10 «Инвиво». 12+
15.40 «Еда, я люблю тебя». 16+
16.35 «Фиксики».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+
20.00 «ТАНКИ ГРЯЗИ НЕ БОЯТСЯ». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.25, 12.15, 15.15, 18.20 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
22.00 «Голос. Дети».
23.35 «Горячий лед». Кубок Первого канала по фигурному катанию.

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.20, 10.00, 15.00, 19.30, 23.10 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Да, скифы - мы!»
8.25 Открытое письмо. «Православная открытка Российской империи».
8.45 «ПОЖИВЕМ-УВИДИМ».
10.20 «ПЕСНЬ О СЧАСТЬИ».
11.55 «Либретто». К.-М.фон Вебер «Видение розы».
12.15 «БЕРЕЗКА».
13.05 Открытая книга.
13.35 Юбилей Елены Козельковой. Эпизоды.
14.15 Власть факта. «Древнеегипетская цивилизация: секреты устойчивости».
15.05 Письма из провинции. Казань.
15.35 «Энигма. И-Пинь Янг».
16.20 «Картины жизни Игоря Грабаря».
17.05 «Плавск. Дворец для любимой».
17.35 К 95-летию со дня рождения Мстислава Ростроповича. Юрий Темирканов и Заслуженный коллектив России Академический симфонический оркестр Санкт-Петербургской филармонии им. Д.Д. Шостаковича.
19.00 «Смехоностальгия».
19.45 Линия жизни. Нина Мозер.
20.45 «КРЕПОСТНАЯ АКТРИСА».
22.20 «2 Верник 2».
23.30 «ХАВА, МАРИАМ, АИША».

«НТВ»
4.50 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня.
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
11.00 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СУДЬБЫ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «Следствие вели...» 16+
21.00 «Страна талантов». 12+
23.40 «Своя правда». 16+

Шимбә

26 март
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Мин». 12+
11.30 «Казаннан - казанга». 12+
12.00, 0.30 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
13.30 «Созвездие - Йолдызлык-2022». 6+
14.30 Н.Җиһанов исемендәге «Мирас» VII татар музыкасы фестивале. 6+
16.00 «Әйдә, шаяРТ!» 12+
17.00 «СТЕНДАПханә». 16+
17.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Tatarstan today. Открытый миру». 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБиТ- шоу». 12+
23.00 «И СНОВА ГОРЬКО!» 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». Марсель Әхмәтҗанов турында телеочерк. 6+
7.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 «Әниемнең җылы кочагы». 6+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Гомер чишмәм». Рәсим Низамов концерты. 6+
23.00 «БИЧАРАКАЙ». 12+

«ЭФИР»
5.00 «Еда. Правильное питание». 12+
5.30 «Люди РФ». 12+
6.30 «Опыты дилетанта». 12+
7.00 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь».
7.30 «Лекс и Плу: Космические таксисты».
8.00 «Прокуроры». 16+
8.45 «ПЕРЧАТКА АВРОРЫ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «РОЖДЕСТВО КОТА БОБА». 12+
14.50 «Все, кроме обычного». 16+
16.00 «УЛЕТНЫЙ ЭКИПАЖ». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ЛЮБОВЬ СЛУЧАЕТСЯ». 12+
22.50 «Человек - невидимка». 16+
23.45 «ПУНКТ НАЗНАЧЕНИЯ: СМАЙЛ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00 Новости.
10.15, 0.45 Информационный канал. 16+
12.15 Чемпионат России по лыжным гонкам.
13.30 «МОСГАЗ». 16+
17.45 «Горячий лед». Кубок Первого канала по фигурному катанию.
21.00 «Время».
22.00 «ЭКИПАЖ». 12+

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00, 21.05 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
12.00, 15.00 «УТОМЛЁННЫЕ СОЛНЦЕМ-2. ПРЕДСТОЯНИЕ». 16+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.20 «НЕСЧАСТНЫЙ СЛУЧАЙ». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
8.15 «КРЕПОСТНАЯ АКТРИСА».
9.50 Острова. Евгений Леонов.
10.30 Неизвестные маршруты России. «Дагестан. От Дербента до Шалбуздага».
11.10 «СТАНЦИОННЫЙ СМОТРИТЕЛЬ».
12.15 «Узбекистан. Место под солнцем».
12.45 «Брачные игры».
13.40 «Рассказы из русской истории. XVIII век». Владимир Мединский.
14.35 «ОПАСНЫЙ ВОЗРАСТ».
16.05 «Объяснение в любви».
16.45 «Песня не прощается... 1976-1977».
18.10 «Калина красная». Слишком русское кино».
18.50 «Энциклопедия загадок».
19.20 «ЧИСТО АНГЛИЙСКОЕ УБИЙСТВО».
22.00 «Агора».
23.00 «ЛИЛИ МАРЛЕН».

«НТВ»
5.05 «ЧП. Расследование». 16+
5.30 «ДАЛЬНОБОЙЩИК». 16+
7.20 Смотр.
8.00, 10.00, 16.00 Сегодня.
8.20 «Готовим с Алексеем Зиминым».
8.50 «Поедем, поедим!»
9.25 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда с Сергеем Малозёмовым». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.05 «Однажды...» 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 Ты не поверишь!. 16+
21.20 «Секрет на миллион». 16+
23.25 «Международная пилорама». 16+

Якшәмбе

27 март
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Яратам». Гөлнара Габидуллина концерты. 6+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
8.00, 13.00 «Адымнар». 12+
8.30 «Хайкю». 12+
9.00 «Эти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.00 «Гомер - татлы мизгел». Раяз Фасихов концерты. 6+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 12+
13.30 «Созвездие - Йолдызлык-2022». 6+
14.30 Н.Җиһанов исемендәге «Мирас» VII татар музыкасы фестивале. 6+
15.30 «Юлчы». 6+
16.00 «Ком сәгате». 12+
17.00 «Видеоспорт». 12+
17.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 12+
20.00 «Профсоюз - союз сильных». 12+
20.15 «Батырлар». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
23.00 «12». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30, 13.35 «Нәсыйхәт». 6+
6.00, 13.00, 0.40 «Татарлар». 12+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
7.00, 16.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
8.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
9.00 «Дала буйлап җил исә». Рабит Батулла турында телеочерк. 6+
10.00 «Юлчы». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05 «Яшьләр тукталышы». 12+
14.05 «Кайда сез, яшьлек еллары». Зөһрә Шәрифуллина концерты. 6+
15.35 «Шаян хәлләр». 12+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Семь дней». 12+
21.10 «СТЕНДАПханә». 16+
21.40 Спектакль «Хәят». 12+

«ЭФИР»
5.00 «Инвиво». 12+
5.30 «Люди РФ». 12+
6.30 «Опыты дилетанта». 12+
7.00 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь».
7.30 «Лекс и Плу: Космические таксисты».
8.00 «Прокуроры». 16+
8.45 «История образования». 12+
9.00 «УЛЕТНЫЙ ЭКИПАЖ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ЛЮБОВЬ СЛУЧАЕТСЯ». 12+
15.00 «Кавказский пленник». 12+
15.45 «ПЕРЧАТКА АВРОРЫ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «РОЖДЕСТВО КОТА БОБА». 12+
22.45 «Человек - невидимка». 16+
23.40 «ВСПОМНИ ВСЕ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.35, 6.10 «ХИРОМАНТ». 16+
6.00, 10.00, 12.00 Новости.
7.35 «Играй, гармонь любимая!» 12+
8.20 «Часовой». 12+
8.50 «Здоровье». 16+
10.15, 0.55 Информационный канал. 16+
11.10, 12.15 Чемпионат России по лыжным гонкам.
13.45 «МОСГАЗ». 16+
17.15 «Горячий лед». Кубок Первого канала по фигурному катанию.
21.00 «Время».
22.35 «72 МЕТРА». 12+

«РОССИЯ»
5.20 «АЛИБИ НАДЕЖДА, АЛИБИ ЛЮБОВЬ». 16+
7.15 «Устами младенца».
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 14.00, 17.00 Вести.
12.00 «УТОМЛЁННЫЕ СОЛНЦЕМ-2. ПРЕДСТОЯНИЕ». 16+
14.50 «БЕЛЫЙ ТИГР». 16+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 Мультфильмы.
7.50 «ОПАСНЫЙ ВОЗРАСТ».
9.20 «Обыкновенный концерт с Эдуардом Эфировым».
9.50 «Мы - грамотеи!»
10.30 «НЕВЕРОЯТНОЕ ПАРИ, ИЛИ ИСТИННОЕ ПРОИСШЕСТВИЕ, БЛАГОПОЛУЧНО ЗАВЕРШИВШЕЕСЯ СТО ЛЕТ НАЗАД».
11.50 Диалоги о животных.
12.30 Невский ковчег. Теория невозможного. Александра Коллонтай.
13.00 «Игра в бисер» «Корней Чуковский. Стихотворения для детей».
13.40 «Рассказы из русской истории. XVIII век». Владимир Мединский.
14.30 Спектакль «Солисты Москвы».
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.15 «Пешком...»
17.45 «Хроники Скобелевского комитета».
18.35 «Романтика романса».
19.30 Новости культуры.
20.10 95 лет со дня рождения Мстислава Ростроповича. Документальный фильм.
20.50 «СТАНЦИОННЫЙ СМОТРИТЕЛЬ».
21.55 Спектакль «МЁРТВЫЕ ДУШИ».

«НТВ»
4.45 «ЭКСПЕРТ». 16+
6.35 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 Сегодня.
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
12.00 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.40 «Маска». 12+
23.40 «Звезды сошлись». 16+

Сукбай мәхшәре

Узган елга йомгак ясап, республикада җинаятьчелекнең берникадәр кимүе билгеләп үтелде. Шул ук вакытта кайбер төбәкләрдә, мәсәлән, Актаныш районында хәвефле саннар арткан, бигрәк тә, авыр җинаятьләр фаҗигаләр күбәйгән. Өстәвенә, быелгы елның беренче көннәрендә үк Иске Байсарда тагын кеше үтерү очрагы теркәлде.

Ошбу авылдагы урамда бер төркем эшлексезләр яши торган йорт бар. 1966 елгы Индус Юнысов өендә шулай ук алтмыш ягындагы Васил Галиев белән Илфар Гафуров та тора. Ул гына да түгел, алар белән бер түбә астында күрше Башкортстан якларыннан килгән 1963 елгы Равия Арсланова гомер итә. Әлбәттә, иң әүвәл хәмергә хирыслыклары аркасында ялгыз калган катлаулы язмыш кешеләре сыенып урын тапкан монда. Элегрәк хөкемнәргә дә тартылып, юньсез тормыш рәвеше алып барсалар да, әлеге затларны теләсә кайчан хәвеф-хәтәр китереп чыгарырга сәләтле куркыныч кешеләр дип булмастыр.

Хәтәр бәндә узган ел көзгә таба пәйда була анда. Равия Арслановаңың яңа төрмәдән чыккан 1984 елгы улы Марсель Закиров та шунда оялый, үзе генә түгел, Башкортстанның Бакалы районыннан тугыз яшькә өлкәнрәк “юлдашы” Резедә Йосыпованы алып кайта. Шул рәвешле кышка каршы бер авыл өендә алты кешелек эчкечеләр төркеме җыела.

М.Закиров төрмә юлын 19 яшеннән таптый башлый. 2004 елда Минзәләдә бер кешене үтерүгә омтылыш ясауда гаепләнеп, 6 елга утыртыла. Аннан кайткач, шартлы хөкемнәр алгаласа да, 4 ел чамасы иректә йөри, ә 2014-2021 елларда тоташтан диярлек лаеш шулпасын чөмерә. Чөнки йөремсәк карак Актаныш, Башкортстанның Илеш, Шаран, Чакмагыш районы судлары тарафыннан дүрт мәртәбә хөкем ителә. Кыскасы, Иске Байсарда 36 яшендә 11 ел чамасы төрмә стажы җыйган хәтәр егет яши башлый.

Аның холык-фигылен, берочтан сәрхушләр оясындагы тормыш агышларын күрсәтү йөзеннән гадәти көннәрнең берсе булган 24 ноябрь вакыйгаларына кыскача тукталып үтик. Иртәнге сәгать 10 тулгач, ягъни исерткеч эчемлекләр сатыла башлагач, Марсель белән Резедә парлашып кибеткә барырга карар кылалар һәм ике шешә аракы алып кайталар. Әлбәттә, алты кешегә бүлгәч, чәп итәргә дә җитми бу. Шул сәбәпле, ирле-хатынлылар кибеткә ике мәртәбә сәфәр кылып, тагын дүрт шешәне өстәлгә куя. Бу инде һәр борынга бер ярты дигәнне белдерә һәм өлкәнрәк яшьтәге дүрт сәрхушнең түр якка кереп йокларга түнүенә китерә.

Әлеге мәҗлес М.Закиров хисабына оештырыла, ягъни аракы өчен ул түли. Димәк, яңа ирекә чыккан ир-атта аз-маз сәмән бар һәм гүзәл зат та аңа тикмәгә генә гашыйк булмаган. Кухняда икесе генә калгач та, сөйгәненнән бер яртылык акча сорый ул. Хатын-кызның ошбу әрсезлеге ир-атның котырынып китүенә сәбәп тудыра, нәтиҗәдә, ул буш шешәләрнең берсен Резедә башына орып челпәрәмә китерә. Гаҗәп, ләкин хатын бер кечкенә шеш кенә чыкты, канамады дип сөйли. Яла яга дип фаразларга урын юк, чөнки моны Марсель үзе дә раслап тора. Әлеге вакыйга ул чакта полициягә җиткерелми, бары тик айдан артык вакыт узгач кына калкып чыга һәм яңа ел башында үтерү белән янау дигән маддә буенча эш кузгатыла.

Шешәдәш гашыйклар дус вә тату яшәми инде ул. Резедәнең дә өйдән чыгып качкан чаклары була. Берсендә 60 яшьлек бер ялгыз ир-ат өенә барып керә. Бер-ике көннән хатынның кайда куныуын белә Марсель һәм 1 гыйнварда, әлбәттә ки, исерек килеш абзый йортына “разборка”га барып керә. Хуҗа колач җәеп каршы алмый аны, кесәсеннән алып стаканга салган аракысын эчүдән баш тарта, дәгъвалы сорауларына да шактый кискен җавап бирә һәм исерек явызны чыгырдан чыгара. Котырынып киткән сәрхуш ике тапкыр агайның борын тирәсенә кундыра, үтерәм дип акыра, хәтта кулына пычак ала. Авыз-борыннан киткән канны юарга дигән сылтау табып читкәрәк киткән өлкән кеше оекчан килеш өеннән чыгып йөгерә һәм ике йорт аша яшәүче авылдашы йортына атылып керә. Полициягә хәбәр иткәннән соң ирләр теге явыз калган йортка керәләр, ләкин аннан җилләр искән, ягъни ул пычакны да алып качып киткән була инде. М.Закировның ошбу галәмәте дә үтерү белән янау дип табыла. Болар чагыштырмача җиңел җинаять санала, билгеле.

Аның яңа елның беренче көнендә котырынып йөрүенә этәргән тагын бер сәбәп була. Хикмәт шунда, иртә белән бик яман әрләшкәннән соң, хатын-кыз дуамал ирне акылга утырту ниятеннән, шул районндагы Чуракай авылында яшәүче дус хатыны янына китә. Анда даими яши алмаячагын белә һәм Марсель артыннан килер, ялынып-ялварып кире алып китәр дип өметләнә. Шулай килеп чыга да. Чуракайда икене кунганнан соң, ягъни 3 гыйнварда, сукбай хатын Бакалы районы юнәлешендәге юлга чыгып баса, әйтүенчә, туган якларына китмәкче була, ләкин өлгерә алмый, чөнки янында Иске Байсар ягыннан килгән “Лада Калина” туктый, аннан Равия ханым белән Марсель чыга. Ир-ат гафу үтенә, аннан башка яши алмавын да белдерә һәм Иске Байсарга кайтырга өнди. Беркайда да зарыгып көтеп торучылары булмаган мескен хатынны кышкы юллар чатында озак үгетләргә туры килми, әлбәттә.

Өметләр баглардай килешү булмый бу. Чөнки хәмер дигән залим бер кая да китми. Резедә шунда ук кибеттән ике шешә аракы алып чыга, хак булса, үзе эчми, ә аналы-уллы ике кеше 375 граммлы бер савытны урамда ук бушата. Р.Арсланова узгынчы «КамАЗ»га утырып китә. Ир белән хатын караңгы төшкәч, икенче машинада кайта. Исерекләр төркеме тулысынча җыела, димәк.

Кичке сәгать 9 лар тирәсендә күрше йорт тәрәзәсен шакыйлар. Хуҗабикә Айзирәк сукбайлар өендә яшәүче Резедәгә ишекне ача, аның оекчан һәм курткасыз икәнен күреп өенә кертә, ярасыннан аккан канны туктату өчен кулына тастымал тоттыра һәм полициягә, коткару хезмәтенә шалтырата. Тетрәнгән хатын-кыз Марсельнең аңа һәм анасына пычак белән кадавын әйтә, билгеле. Хәвефле урынга иң алдан авыл башлыгы Р.Кадыйров килеп җитә. Айзирәк аңа икенче яралы һәм пычаклы явызның күрше йортта икәнен җиткерә. Дүрт-биш ир кеше, шул исәптән, Марсель Закиров булган өйгә авылдагы амбулатория табибе белән икәүләп керәләр. А.Сафиуллин күрсәтмәләренә караганда, кәнәфидә яткан исерек хатын-кыз юньләп тикшерергә бирми, йокым килә дип борчымаска куша, гаҗәп, ләкин хәл эчендәге ханымның кан басымы да яхшы була. Соңрак килеп җиткән ашыгыч ярдәм табибләренә ошбу авыруның хәле “тотрыклы” икәнен, димәк, ярдәмгә мохтаҗ булмавын, тикшеренергә теләмәвен җиткерә ул. Алары, шуны гына көткәндәй, кире борылып күрше йортка керәләр, андагы Р.Йосыпованы карагач тиешле чаралар күрәләр дә, аны сырхауханәгә алып китәләр.

Ә менә чынлыкта бер сәгать чамасы гомере калган Р.Арсланова урынында ята. Аның хәле начарлану турындагы хәбәр Р.Йосыпованы район сырхауханәсенә тапшырган чакта ук килеп ирешә. Ләкин Иске Байсарга яңадан барып җитеп аңа кислород битлеге кидерү һәм башка коткару чаралары күрүнең файдасы тими инде. 58 яшьлек хатын-кыз төнге сәгать 12 тулганда ашыгыч ярдәм машинасында җан бирә.

Әлеге мәхшәрнең М.Закировның исерек ахмаклыгы нәтиҗәсе икәне бәхәссез. 3 гыйнвар кичендә алты сәрхуш янына Мәрвән атлы тагын берәү кушыла. Эчә торгач, Р.Йосыпова әйтмешли, “алҗыйлар” һәм җәелгән ике диван, ике кәнәфигә сузылып ятып йоклыйлар. Ике хатын-кыз алданрак уяна. Р.Арслановаңың күптән түгел генә Марсельдән кечерәк улы вафат була. Резедә мәрхүмнең 40 көнен уздыру турында сөйләшә идек, Марсель уянып әнисен калган аракыны урлап эчүдә гаепләргә, җикеренергә керешә, төбендә 100-150 г чамасы аракы булган шешәгә төртеп күрсәтеп, кагылучы булмавын әйтсәк тә, котырына бирде, кәнәфидә яткан әнисенә пычак кадады, ди. Аңкы-миңкә Марсель тынычланырга җыенмый, алдан хатыннарның икесенең берсен үтерәм дип, аннан соң, Резедәгә сине дә дөмектерәм дип кычкыра, ул гына да түгел, кайнанасы янына утырып, арага кергән һәм шул көнне генә үгетләп алып кайткан хатынының да корсагына чәнчеп ала.

Сәрхушләр өендә чыр-чу куба, билгеле. Әлеге тавышка уянган И.Гафуров белән В.Галиев торып утыралар. Ләкин алар арага керергә куркалар, чөнки теге явыз үтерәм дип янап тора. Бераздан Резедәгә канга буялган киемнәрен салырга әмер бирелә. Хатын-кыз кул астына эләккән ирләр киемен киеп куя, И.Гафуров канга манчылган киемнәрне икенче урамдагы көрткә илтеп ташлый һәм хәтәр йортка полиция килеп җиткәнче керергә шикләнеп йөри.

Шул мәлдә олы малай әнисен коткару чараларын күрә башлый, ягъни үзе дә яралы хатынны Р.Арсланова корсагындагы җәрәхәтне тегәргә мәҗбүр итә. “Операция” башланганчы теге аракыны әнисенең авызына да коя, җәрәхәтенә, энә белән җепкә сала, теккән чакта шок хәлендәге кешенең башыннан үзе, ә аякларыннан аның кушуы буенча В.Галиев тотып тора. Шушы ыгы-зыгы вакытында хуҗа белән Мәрвән кунак йоклап ята. Резедә бәдрәфкә дигән булып чыгып качкач һәм өйдә чит кешеләр йөри башлагач кына уяна алар.

М.Закиров шул көнне үк тоткарлана, чөнки аны аңлы рәвештә кеше, төгәлрәге, әнисен үтерү шик уятмый. Моны ул үзе дә таный. Тикшерү комитетының Минзәлә районара бүлегеннән Руслан Зәйдуллин аңа берьюлы ике кешене үтерергә омтылыш ясау дигән тагын да кырысрак гаепләү дә белдерә әле. Р.Йосыповага ясалган яра нәтиҗәсендә эчке әгъзалар зарарланмаган, шуңа күрә аның сәламәтлегенә җиңел дәрәҗәдәге зыян китерелгән дип табыла. Ләкин гаепләү ягы Р.Йосыпова качып кына котылган, Закиров үзенә бәйле булмаган сәбәпләр аркасында гына үтерү ниятенә ирешә алмаган дип, гадәттәгечә, кырысрак җәза каралган җинаятьтә гаепли. М.Закиров җинаятьләрен таный, бары тик сөйгәнен үтерергә теләвен генә кире кага.

Ошбу мәсьәләгә судья ачыклык кертәчәк. Җинаять эшендә югарыда телгә алынган Р.Йосыпова, Р.Шәеховка үтерү белән янау дигән эпизодлар да бар бит әле. Боларга Р.Гафуров белән В.Галиевка янау хакындагы тагын бер җинаять өстәлә. Димәк, 1984 елгы М.Закировка барлыгы биш җинаятьчел гамәл буенча җавап тотарга туры киләчәк.

Наил ВАХИТОВ.

Үткәннәр сагындыра

Иң авыры – рәссамнарыбыз мирасын популярлаштыру, мөгаен. Шагыйрь, язучыларның китапларын үзләре үлгәннән соң да кабат-кабат бастырып, әдәбият сөючеләргә җиткерергә мөмкин. Композиторларыбызның җырларын теге яки бу җырчы репертуарына кертеп җибәрүе ихтимал. Зур күләмле музыкаль әсәрләр – опера, балет, симфонияләрне киләчәк буыннарга тапшыру эше генә авыррак тора.



Актер, режиссер иҗатын саклау да бик четерекле мәсьәлә булса да, бу өлкәдә боз кузгала башлады – «Шәрык» клубында театр музее ачылды. Рәссам мирасы исә чынлап торып борчуга сала. Музей фондларының караңгы почмакларында яткан картиналарны рәссамнарның юбилейлары уңаеннан биш елдан биш елга гына тамашачы игътибарына тәкъдим итәләр. Күргәзмә мәйданнары бик чикле булу сәбәпле, ул экспозицияләр дә бик аз вакыт дәвам итә.

«Хәзинә» милли сәнгать галереясында Татарстанның халык рәссамы, Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Тукай, Б.Урманче исемендәге премияләр иясе, Россия сәнгать академиясенең мөхбир-әгъзасы Абрек Абзгильдинның 85 еллыгы уңаеннан оештырылган экспозициядә күңелне әнә шундый борчулы уйлар биләде. Моннан ун ел элек нәкъ шушы залда Абрек аганың 75 яшен күргәзмә белән гөрләтеп билгеләп үткән идек. Шыгрым тулы залда түрәләр, республиканың иң зур рәссамнары юбилярга котлауларын җиткерде. А.Абзгильдин киң колачлы иҗат иясе, эш сөючән үрнәк шәхес иде – картиналар иҗат итеп кенә калмады, ун еллап Рәссамнар берлеген җитәкләде, училищеда укытты. В.Суриков институтында монументаль сәнгатькә өйрәнгән рәссамның иҗатында да үзәктә һәрвакыт зур темалар, фәлсәфи гомумиләштерүләр булды. Юбилей күргәзмәсеннән соң рәссам бер ел да яшәмәде, бакыйлыкка күчте. Иҗатын сөючеләр бүген беренче тапкыр үзеннән башка гына җыелды. Бу барлы-юклы ун ел эчендә дөнья никадәр үзгәргән! Ике дистәләп тамашачы галереяның киң иркен залларында кырмыска сыман бик кечкенә күренә. Экспозицияне ачу тантанасын тиз генә тәмамлап куйдылар. Түрәләр исән иҗат ияләренең гомер бәйрәмнәрендә дә күренми, үлгәннәрне искә алу турында әйткән дә юк. Нибары ике-өч рәссамны күреп, җан елады. Хәер, экспозициянең корылышына тел-теш тидерерлек түгел. Музей хезмәткәрләре рәссамның тирән, фәлсәфи иҗатының колачын күрсәтүгә ирешкән, урын да кызганмаганнар. Ләкин Казанда гына да сәнгать училищесы, мәдәният һәм сәнгать институты, һөнәрчелек техникумы, тагын ике-өч югары уку йортында дизайн бүлекләре, дистәләгән сәнгать мәктәпләре эшләп торып, ни өчен шундый зур рәссамнарга багышланган чаралар да бик тыйнак кына, шау-шусыз гына уза икән? Бу кылкаләм остасының тормышы – үзе гыйбрәт ләбаса.

А.Абзгильдин Башкортстанның Баймак районында туып-үсә. Әтисе актер Бөек Ватан сугышы кырында вафат була, шуңа күрә рәссам кечкенәдән эшкә өйрәнә. Тау-металлургия техникумын тәмамлаганнан соң, шахталарда эшли, армия сафларында хезмәт итә. Шуннан соң 24 яшендә генә Казан сәнгать училищесына укырга килә. «Абрек без, 14 яшьлек яшүсмерләрне, бер йодрыкка туплый, тәртипкә сала, аның җитәкче буласын шул елларда ук чамалап була иде», - дип график Григорий Эйдинов курсташын сагынып искә алды. Мәскәүдә Суриков институтын тәмамлап кайткач та, А.Абзгильдин җиңел юллар эзләми – Казан, Уфа, Бөгелмә, Салават, Түбән Кама, Чаллы шәһәрләрендә биналар бизи. Бер төр сәнгатьтә генә кысан була башлагач, ул картиналар иҗат итүгә күчә. Бу күчеш илебезнең үзгәреш кичереп, монументаль сәнгать кирәксез булып калган вакытта аеруча көчле тоемлана. Аның «Сабан туе», «Тукай дөньясы», «Хатын-кызлар һәм чәчкәләр», «Кентаврлар» картиналар шәлкемнәре сәнгать сөючеләрнең күңеленә аеруча хуш килә. Белгечләр рәссамның бу әсәрләрендә, бигрәк тә «Сабан туе» шәлкемендә Көнбатыш һәм Шәрык сәнгате, монументаль фреска һәм төрки миниатюра бергә кушылуын билгеләп үтә.

А.Абзгильдинның иҗатында портретлар да зур урын алып тора. Композиторлар С.Сәйдәшев, Н.Җиһанов, С.Гобәйдуллина, язучылар Дәрдемәнд, Ф.Бурнаш, М.Кәрим, рәссам Б.Урманче портретларын автор төрле детальләр белән баеткан, йөз сызыкларын сурәтләп кенә калмыйча, гүя алар бергә иҗатларының асылына төшенергә теләгән.

Киләчәктә рәссамнарның картиналар күргәзмәләре, исәннәренеке генә түгел, үлгәннәренеке дә иҗат халкының – язучы, шагыйрь, композитор, музыкантларның очрашып, дөнья хәлләре турында фикер алышу, үткәннәрне бер сагынып искә алу урынына әверелер дип ышанасы килә. Март буе «Хәзинә» милли сәнгать галереясына бушлай кертүләрен дә искәртәбез. Шул рәвешле галерея хезмәткәрләре үзләренең тынычлык яклы булуын күрсәтергә тели, сәнгать сөючеләрне дә матурлык хакына тынычлык сакларга чакыра. Галереяда Бакый Урманче, Абрек Абзгильдин, Софья Кузьминых һәм Уфа рәссамы Вәкил Шәйхетдиновның иҗат әсәрләрен күрергә мөмкин.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кулъязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк,
г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 18.03.2022

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2750 данә

Заказ 2744

16+